Мәрҗани Казанда мөдәррис булыб торган заманларында Казандан читдә булган төрле татар авылларына йөреб, кулъязмаларны, кабер ташларын һәм документларны тикшергән, җыйган. Ул бик күб авылларда булган[1]. «Мөстәфад әл-әхбар»да Мәрҗани үзенең төрле авылларга йөреб тикшергәндән кулга төшергән кулъязма һәм документларга таяныб бик күб нәрсәләр яза. Мисал өчен кайберләрен күчереб языб китик. Мәрҗани «Мөстәфад әл-әхбар» I [җильд] 22 битдә Казан сәүдәгәре Исмәгыйль Апанай угълы дигән кешедән калган бер документның гыйбарәсен күчерә. Анда языла: «Тарих мең дә йите йөз дә сиксән сигезенче елда январьнең сигезенче көнендә Казанның Иске Бистәнең йомышлы кеше мин Йосыф Динмөхәммәд угълы сатдым үземнең хассемә[2] тигән колымны Казанның Иске Бистәнең Исмәгыйль Апанай хафиз угълына йөз сум хак берлә ошбу мәзкүр колларым Алат юлында Арча округында Күшәр илендә йорт берлә торгучыдыр мәзкүр колларым ул Бикбау Сидки угълы хатыны Нәсыйхә бер кызы сабый берлә угълы Бикчәнтәй Бикбау угълыны икенче колымның угълы Мортаза Мөэмин угълыны вә дәхи шул Күшәр илендә биләй торган йирләрем һәм печәнлегем көллүсе[3] Исмәгыйль агайгадыр».

«Мөстәфад әл-әхбар», шул ук җильд, 70 битдә Мамадыш кантоны Тәнеки авылында, мондан ике йөз еллар алда Әмкә мулла ди-

[1] Миңа быел җәй көнне Спас кантоны Иске Рәҗәб авылында мондан алтмыш еллар алда Мәрҗанинең Рәҗәбдә булганлыгы, анда кабер ташлары һәм кулъязмаларны тикшереб языб йөргәнлеген, авыл картлары белән төрле мөсахәбәләр ясаганлыгын сөйләделәр. Мәрҗанинең Казан, Мамадыш, Лаеш, Зөя һәм Тәтеш өязләрендә булганы да мәгълум (С. Вахиди искәрмәсе).

[2] Хасс – бер нәрсәгә билгеләнгән.

[3] Көллүсе – барчасы.

гән кеше тарафындан язылган кулъязма китабдан материалар күчерә, «Мөстәфад әл-әхбар» шул ук җильд 78–89 битләрдә Идел буе Болгар галимләре вә аларның әсәрләре турында язганда XII, XIII, XIV йөзләрдә булган кулъязма әсәрләрнең баш һәм ахыр якларыннан гыйбарәләр күчереб, алар турында изахәләр[1] яза[2] һәм үзенең сүзләренә бу кулъязмалардан алыб дәлилләр китерә.

«Мөстәфад әл-әхбар» II җильд, 8 битдә Спас өязе Иске Рәҗәб авылы имамларындан мулла Зәйнелгабидин Габделкәрим угълы дигән кешенең тәрҗемәи хәленә теркәлгән документның тәрҗемәсендән түбәндәге урынны күчерә. Бу документ Рәҗәб халкының игенлек, печәнлек һәм умарталарның чикләрендән башка авылларның чикләрендән аерыр өчен, хөкүмәт мөһере белән ныгытылган рәсми документ булган. Документына языла: «Тарих йите мең дә ике йөз өченче декабрь аеның унөченче көне илән указ олугъ газыйм падишаһ хәзрәте олуг кенәз Петр Алекчиеч барча олугъ вә кечек ак падишаһ Русия йортыны үзе тотгучы үзе биләкүче указ кувәте илән Казан өязенең Рәҗәб авылының татарлар юкарыда язылган йирләр сукалатмак өчен һәм печәнен чапмак өчен укадилар илән биләргә олугъ падишаһ хәзрәтенең бердән ясак илән тармакга ягъни түләмәккә бер замандагы аңлатуны Казанга түләргә яздым».

«Мөстәфад әл-әхбар» II җильд, 9 битдә Олы Кавал имамы Сәлимҗан Дусмөхәммәд угълы дигән кешенең кулъязма бер китабындан менә мондый тарихи бер парчаны күчерә: «Бихисабе рус[3] йите мең дә ике йөз дә сикез улган иде бактилар Гайсәнең тарихыны һәм мең дә йите йөз дә булмыш ул Адәм галәйһиссәлам тарихыны ташладылар ошбу мең дә йите йөздән алдылар имди Гайсәнең тарихыны мең дә йите йөз дә бер диб санай башладылар. Мең дә йите йөз дә сикез улды печин[4] елында биш мең дә биш

---

[1] Изахәләр – аңлатмалар.

[2] Бу кулъязмаларның күбесе Мәрҗани көтебханәсендә булган (С. Вахиди искәрмәсе).

[3] Монда ике йөз егерме тугыз ел алда, әле урыслар һаман иске гасыр тарихы белән хисаб алыб баралар иде. Олы Каувәл авылының Сәлимҗан Дусмөхәммәд угълының кулъязмасы язылган ел урыслар хисабынча 7208 булган. Бу ел милади белән 1700 ел булыб, шундан иске гасыр тарихының 5508 елы ташлана да 1701 диб санаб кителә. Бу вакыйга заманында зур үзгәрешләрдән хисабланган (С. Вахиди искәрмәсе).

[4] Печин (бечин) – маймыл.

йөздә сикез елы тәмам ташланды дәхи белгел әй, сахибе тәмиз[1], сале шәмсиянең[2] өч төрле хисабы вардыр беренә фарсия хисабы дирләр аның берлә әһле Болгар гамәл тотмышдыр. Вә беренә румия хисабы дирләр әһле насара[3] гамәл тотмышдыр бәс мәгълүм вә мәшругъ[4] булды хәмәл хисабын җәмигъ мөэмин вә мөселманларга белмәк ляземдер... вә дәхи мәгълүм ула ки ул фарсия нәүрүзе улыр ун көндән соң румия нәүрүзе улыр андан ун көндән соң хәмәл[5] нәүрүзе булыр нитәкем шәһре Болгар голямасы ишарәт кылдылар биләнәүрүз карт нәүрүз вәссөлек нәүрүз дию вә һәрбер нәүрүз берәр гаҗүз[6] хисабыдыр».

«Мөстәфад әл-әхбар» II җильд, 127 битдә Ташкичү авылында мондан бер йөз туксан ике ел алда язылган бер китабның Ташкичү урманында яшеренеб язылуы турындагы мәгълүматлары шулай ук «Мөстәфад әл-әхбар»нең Идел буе болгарлары турында язылган бәетләрендә шәһәре Болгардагы олы манараның егылуы турында, Спас өязе Олы Чаллы авылының крестьяны Фазлулла Бохарай угълы тарафыннан язылган «Мәҗмәга»сендән күчереб, әлеге манараның, 1136 нче һичри елның җәендә сәламәт булучылыгы вә ул манара турында байтак тәфсыйлатләрне язуы – боларның барысы да Мәрҗанинең документ һәм кулъязмаларны эзләгәнлеген, җыйганлыгын, алардан файдаланганлыгын күрсәтәдер.

Мәрҗани бу мәсьәлә турында байтак кешеләргә хатлар да язган. Безнең өчен гыйльми вә тарихи әһәмиятле булган бер хатындан кайбер урынларын күчерәбез. Мәрҗани мондан алтмыш дүрт еллар алда, үзенең шәкерте Хөсәен Фәезхановның вафатына тәэссеф итеб (Фәезханов Петербург (Ленинград) дарелфөнүненең[7] шәрыкъ телләре бүлегендә лектор булыб торганда 1866 ел 30 июлenendә вафат) Газизулла һәм Кәлимулла дигән кешеләргә һиҗри 1283 ндә язган хатында болай яза: «Мескенем мулла Хөсәен... Вафат булган икән ләбаса, ни кылмак кирәк... Күб-күб хезмәтләр кыйлыб, биниһая файдалар тигергән иде..., һәйбәт кеше

---

[1] Сахибе тәмиз – чисталык, пакълек иясе.

[2] Сале шәмсия – кояш календаре.

[3] Әһле насара – христианлылар.

[4] Мәшругъ – шәригатькә ярашлы.

[5] Хәмәл – Кучкар йолдызлыгы; ел исәбенең 22 марттан 22 апрельгә кадәрге вакыт аралыгы.

[6] Гаҗүз – карт кеше.

[7] Дарелфөнүненең – университетының.

иде... Аның һәртөрле мәҗмугалары вә китаблары булса кирәк иде. Безгә кул китаблары булганда сатмакны ихтыяр кылсалар, без бәлки, алыр ирдек. Аның мәдрәсә хосусында тәхрир[1] кылган бер рисалә мөсавәрәсе[2] бар иде. Аны бәяз кылыб[3] кылыб басдырмак ирадәсендә[4] иде бичара. Бәязга форсаты булмагандыр, шул рисалә җуялмаса икән мин үзем аны бәязга чыкарыб басдырмак садрында[5] булыр идем тәгаддәдә нәсхи (нөсхәләрен артдыру) булырлык биш-алты нөсхә яздырыр ирдем. Бичараның сәгый вә иҗтиһады заигъ булмаса икән[6] ул бик яхшы бик мөфид[7] нәрсә иде... Хасыйле кәлам[8], мөмкин булса, тизлек илән мәрхүмдән калган китабларны исемләрне языб алыб, тәфсыйлән фиһрис ясаб, мөмкин булса баягы рисаләсе, шуңар мөтәгалликъ[9] җөзье кәгазьләрдә булган тәхрирләрне һәм безгә йибарәсез. Мөкаддәмдәрәк[10] үзенең җәмегъ кылган бер мәҗмәгы булса кирәк иде. Янә татар телендә вазыйг[11] кылган нәхүе, сарфы булса кирәк иде. Болгар вә Казан хакында мәкаләсе булса кирәк иде. Безнең хатымызның һәм мәзмунны[12] хат белән җәмәгатенә ифадә[13] итәсез».

Мәрҗани «Галәләт әз-заман фи тарихе Болгар вә Казан» исемле әсәрендә бу китабны һәртөрле мәҗмәгъ[14] вә мәҗмугадән шулай ук бу йирнең халкы тарафындан язылган төрле язмалардан җыйнап тәэлиф[15] иткәнлеген яза.

Югарыда язылган материаллардан ачык күренә ки, Мәрҗани һәртөрле иске кульязмалар, документлар, мәҗмугаләр вә башка

---

[1] Тәхрир – әсәр язу.

[2] Мөсавәрә –

[3] Бәяз кылыб – акламага күчереб.

[4] Ирадәсендә – теләгендә.

[5] Садрында – эшнең алдында, башында.

[6] Сәгый вә иҗтиһады заигъ булмаса икән – бирелеп эшләве һәм тырышуы әрәм булмасын иде.

[7] Мөфид – файдалы.

[8] Хасыйле кәлам – кыскача әйткәндә.

[9] Мөтәгалликъ – караган, бәйле.

[10] Мөкаддәмдәрәк – алдарак, элегрәк.

[11] Вазыйг – төзү.

[12] Мәзмун – әйтергә теләгән фикерләр.

[13] Ифадә – аңлату.

[14] Мәҗмәгъ – җыелма, тупланма.

[15] Тәэлиф – җыйнау, төзү.

тарихи әсәрләрне тикшерергә, җыярга, алардан истифадә итәргә шул дәрәҗәдә әһәмият биргән. Боларның өстенә Мәрҗанинең үз гомерендә утыз бишдән артык мөһим әсәрләр язганлыгын игътибарга алсак, үзе язган әсәрләренең мәтбугъ[1] булганларының үзендә калган кулъязмалары, мәтбугъ булмаган әсәрләренең оригиналлары һәм читдән йибәрелгән төрле кешеләр тарафындан язылган шәһәр вә авыллар турындагы тарихларның кулъязмалары, менә болар үзләре генә дә Мәрҗани көтебханәсенә галимләрнең дикъкатьләрен җәлеб итүдә зур гамил[2] була алалар. Шуларга таяныб без әйтәбез, Мәрҗани көтебханәсе чаклы хәзерендә бөтенләй табылмый торган кулъязма төб нөсхәләр, документлар, шәҗәрәләр, юридический памятниклар, авыллардан җыелган яки алардан күчереб алынган нөсхәләр бик күб булганлар. Мәсәлән: Бохарада укыган чакларында Мәрҗани Ибне Фөзланның Болгарга килгән вакытында язган сәяхәтнамәсенең бер нөсхәсен интихаб[3] белән күчереб алган булган. Мәрҗанинең «Мөстәфад әл-әхбар»дә язуына караганда, Мәрҗани күргән Ибне Фөзлан әсәренең нөсхәсендә Якут әл-Хәмәви һәм башкалар күчергән сүзләрдән артык сүзләр анда бик күб булган.

«Мөстәфад әл-әхбар»дә язылуына караганда, Мәрҗани көтебханәсендә Идел буе Болгар галиме Ибраһим бине Хәзәр әл-Болгариның 751 һиҗридә язылган «Китабе ысул әл-Хисами» исемле әсәренең төб нөсхәсе һәм икенче бер болгар галиме Сәдр бине Галәэтдин әл-Болгариның шәкерте Ибраһим бине Мөхәммәдхуҗа Карәтмәни[4] дигән галимнең шул «Имам Фәхрелислам» исемле һиҗрәтдән 765 нче елда язылган әсәренең һәм бер нөсхәсе аның кулында булган. Шулай ук «Мөстәфад әл-әхбар»дә язылуына караганда Ибн әл-Әсирнең «Мәгърифәт әс-сахабә» исемле әсәренең бик иске нөсхәсе Мәрҗани көтебханәсендә булган. Бу нөсхәне Мәрҗани Ибн әл-Әсирнең үз гасырына бик якын заманда булучылыгын яза. Боларга башка Мәрҗани көтебханәсендә аның хакында тикшерену дәвам итә торган «Нәһҗел-фәрадис» нөсхәсенең бик иске вә бик мөһим кулъязмасы булганлыгы һәм Хөсәен Фәезхановның байтак әсәрләре, бигрәк дә, мәдрәсәләрне

[1] Мәтбугъ – басылган.

[2] Гамил – фактор, көч.

[3] Интихаб – сайлап алу.

[4] Карәтмән авылы бу көндә дә Казандан ерак түгел бер татар авылы.

ислах турындагы әсәренең әле 15 нче елга кадәр Мәрҗани көтебханәсендә сакланган булучылыгы, менә боларның барысы да Мәрҗани көтебханәсенең гыйлем ияләре өчен ничаклы әһәмиятле бер көтебханә икәнлеген күрсәтүдә көчле дәлил була алганлыкларын тәкрар итәбез.

Мәрҗани үзе сәламәт вакытда үзенең милкендә булган китабларның кадерен белгән һәм аларның югалмау, таралмаулары турында тәдбирдә[1] калган. Хәтта ул үзе үлгәннең соңында да көтебханәсендәге китабларның таралмыйча саклану чараларын күрергә тырышкан. Без моны Мәрҗанинең үз кулы белән языб, үзенең һәм шаһидләрнең имзалары вә үзенең мөһере белән расланган васыятьнамәсендән аңлыйбыз. Мәрҗани 1297 һижри шәгъбән аенда язган васыятнамәсендә бу турыда менә болай яза: «Вә дәхи кәнде[2] милкем улгучы җәмигъ китабларымны үз әүладе[3] мәүкыйф итдем. Карнән бәгъде карн[4] бер дә сатылмас. Истигъмәл кылыб файдаланудан башка урында истигъмәл кылынмас. Файдалана торган ышанычлы кешегә дөрест вәсика[5] берлә аз заманга гарият[6] биреб торырлар. Мәгаз Аллаһ[7], кәнде әүладем киселсә, туганларыма вә әүладларына шул тарика[8] вакыф улыр. Бу китабларның һәр каюсына исемемлә мөнәккаш[9] «вакфе әүлад»[10] дию яздырган. Мөһерем басылыр вә тәфсыйль дәфтәрдә исемләрелә язылыб рәкымләр[11] берлә мәркум[12] кылыныр»[13].

Васыятьнамәдән аңлашылуына караганда, Мәрҗани көтебханәсе гасырлар буе таратылмыйча сакланырга тиеш булган. Көтебханәдәге әсәрләр белән вакытлы файдаланырга теләгән ышанычлы кешеләргә кулларындан кәгазь алыб, бераз заманга

---

[1] Тәдбир – тиешле чара.

[2] Кәнде – үземнең.

[3] Әүлад – балалар.

[4] Карнән бәгъде карн – гасыр артыннан гасыр.

[5] Вәсика – ышанычлы документ, дәлил.

[6] Гарият – вакытлыча файдалануга алып тору.

[7] Мәгаз Аллаһ – Аллаһ сакласын.

[8] Тарика – юлга.

[9] Исемемлә мөнәккаш – исемем белән бизәлгән.

[10] Вакфе әүлад – балалар вакыфы.

[11] Рәкымләр – саннар.

[12] Мәркум – номерланган.

[13] Мәрҗани мәҗмугасы. 136–135 битләрдә (С. Вахиди искәрмәсе).

биреб торырга рөхсәт ителгән. Ләкин көтебханәдәге китапларның һәр каюсында «Балаларга вакыф» диеб язылган мөһер булырга тиеш булган.

Мәрҗани көтебханәсенә хәзерге вакытда баш хуҗа аның угълы Борһан хәзрәтнең хатыны Маһисәрвәр абыстай Мәрҗания һәм аның балалары. Алар әле дә шул ук Мәрҗани торган өйдә торалар, Мәрҗанинең көтебханәсе дә алар белән бергә шул ук йортда саклана. Мәрҗанинең васыяте варислар тарафындан эшкә ашырылгандырмы яки юкдырмы, ул мәсьәлә, әлбәттә, безгә караңгы, аны тикшерү безнең эшебез дә түгел.

Мондан берничә еллар алда ук мин Мәрҗани көтебханәсенә кереб, андагы әсәрләр белән танышырга, алардан файдаланырга теләгән идем. Мәрҗанинең васыяте буенча, көтебханәгә кертерләр диб уйлаган идем. Ләкин эш мин уйлаганның киресенчә булды, Мәрҗани көтебханәсендән файдаланыр өчен аның соңгы хуҗаларындан рөхсәт алу мөмкин булмады. Мәрҗанинең варислары, бигрәк дә, Борһан хәзрәтнең хатыны Маһисәрвәр абыстай көтебханәнең иң әһәмиятле өлешен сандыкларга тутырыб кладовойда асрау, мөмкин кадәр андый әсәрләрне үзенә якын торган берничә кешеләрдән башкаларга күрсәтмәү юлы белән саклау тактикасын алыб барган. Мәрҗани мәҗмугасында язылуына караганда Мәрҗанинең тууына йөз ел тулу мөнәсәбәте белән мәзкүр мәҗмуганы язучы һәйәте тәхририя әгъзаларына көтебханәнең бөтен өлеше белән файдаланырга рөхсәт ителмәгән. Аларга да Борһан хәзрәтдән калган шкафларда булган китабларны каратудан ерак җибәрелмәгән.

Хәзерге вакытда Мәрҗани көтебханәсенең баш хуҗасы булган Борһан хәзрәт хатыны Маһисәрвәр абыстай, анардан шул турыда мәгълүмат алырга җибәргән минем кешемә түбәндә язылачак сүзләрне сөйләгән, аның сүзләрен үзендән ишеткәнчә үзгәртмичә без монда языб китәбез. Ул әйтә: «1917 нче елны безгә хәбәр бирәләр, Мәрҗани хәзрәтнең көтебханәсен университетка алалар икән. Бу көн мәсҗид очырмасындагы китабларны карыйлар, иртәгә сезгә керәләр, диб. Шуны ишеткәч мәрхүм улым Габделхәмит хәзрәт «Әни, без бу китабларны бераз яшереберәк куик» диде дә, шул көнне очырмага биш сандык китаб ташыб куйдык. Ул китаблар очырмада шулай тордылар. Ике-өч ел үткәч, бездә пожар булыб, очырмабыз янды, шунда бу китаблар да яндылар. Яныб бетми калган кисәкләрен, урталарын яндырсак гөнаһ булмас микән диб, Галия абыстайга (Мәрҗани кызы, Сафый мулла хатыны)

киңәш итдем дә, ауналыб йөргәнче диб яктык. Кайбер калганлары, кырыйлары көйгәнләре әле дә очырмада ике кабчык ята. Миндән «Нәһҗел-фәрадис» китабы сораб абтыраталар, бик кыйммәт бәһага алабыз диб әйтәләр; хөкүмәт кешеләре дә сорадылар, ләкин ул китаб хәзер бездә юк, каядыр, кая киткәнен дә белмибез, хәзер инде хәзрәтнең (Мәрҗани) күб китаблары бетде. Без инде аларны яхшы саклый белмәдек шул», ди абыстай.

Мәрҗани варисларының кайберләре белән мин үзем бу турыда мөсахабәләр[1] ясадым. Аларның Мәрҗани көтебханәсе турында сөйләгән сүзләре менә шундан гыйбарәт: «Көтебханәгә моңа кадәр байтак кешеләр кереб-чыгыб йөрделәр. Үткән ел бер мулла көтебханәне тикшереб караб чыкды. Андан соң Әфтах мулла Тәрҗемани көтебханәдәге барлык китабларның исемлеген язды. Ул исемлек әле дә Әфтах мулла кулында, Яңа Бистәдә ди». Дәвамында «Безнең китаблар әкренләб югалдылар шул инде. Вакытлы файдаланырга алган кешеләр китабларны яңадан кайтармадылар. 1920 нче елда булган ут казасындан очырмага куйган биш сандык китаблар яныб юкка чыкдылар» диләр.

Әгәр дә аларның Мәрҗани көтебханәсе турында сөйләгән сүзләре барсы да дөрес булса, Татарстан җөмһүриятенең мәркәзе булган Казан шәһәрендә бик зур гыйльми дәүләт юкка чыккан була. Шөбһәсез, моңар бик тирән аяныч вә тәәссеф белән карарга туры килә.

Мәрҗани көтебханәсенең соңгы кызганыч тәкъдире белән XIV йөзнең соңгы яртысында борынгы татар әдәби теленең ничек булганлыгын күрсәтә торган, бердәнбер кульязма «Нәһҗел-фәрадис» нөсхәсенең тәкъдире дә, шул ук варисларның сөйләвенә караганда, һичбер кыйммәтле булмаган бер рисалә шикелле юкка чыгарылган була.

Мәрҗани көтебханәсе, аның башлаб төзелеше, анда булган һәртөрле әсәрләр, ниһаять, көтебханәнең бу көндә гомумхалык өчен файдаланырга мөмкин булыб яки булмавы мәсьәләләре, менә болар шөбһәсез әһәмиятле булган хәзерге вакытда чишелергә тиешле мәсьәләләрдән булганга күрә, без, гәрчә бу хезмәтебезне рус телендә чыга торган гыйльми журналларның берендә басдырырга хәзерләб куйган булсак да, менә боларны мөляхәзә[2]

[1] Мөсахәбәләр – сөйләшүләр, әңгәмәләр.

[2] Мөляхәзә – игътибар белән уйлау.

итеб, татарча да нәшер итәргә уйладык. Шуны да әйтеб китәргә тиеш ки, безнең бу тикшеренүләребез бәлки тулы тикшеренү вазифасын үти дә алмас. Һәрхәлдә, киләчәкдә бу мәүзугъда[1] казынучы егетләргә безнең бу хезмәтебез материал була алса, без вазифабызны үтәгән булабыз.

Мәрҗани көтебханәсенең әүвәлдә каталогы яки инвентарь журналы булганмы, юкмы, яки алар көтебханәдән югалтылган бик күб әсәрләр шикелле соңындан югалганлармы, без әлегә ул турыда һичбер төрле мәгълүмат ала алмадык.

Мәрҗани көтебханәсендән бик күб әсәрләр югалган һәм яныб юкка чыккан булсалар да, шөбһәсез, әле анда сәламәт сакланыб калганлары да байтак булырга тиеш. Һәрхәлдә көтебханәгә кереб җитди тикшерүләр ясаганда әһәмиятле кулъязма, аерым кәгазь һәм документларның табылачагына мин ышаныб карыймын.

*Мәрҗани. БЕЗНЕН-ЮЛ. № 6–7. 1929 г. С. 14–17*

*Текстны гамәлдәге язуга күчереп, басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге җитәкчесе Илһам Гомәров әзерләде*

## С. Вахиди тарафыннан төзелгән анкета

Иптәш!

Сезгә Татарстан Үзәк музее шәрык кулъязмалары бүлеге мөдире С. Вахиди иптәш тарафындан төзелгән «Анкета»ны җибәрү белән бергә, шул анкетада тәкъдим ителгән барлык сорауларга да мөмкин булган кадәр тизрәк җавап бирүегезне һәм түбәндәге адрес белән безгә җибәрүегез үтенелә.

Шул ук вакыт музей, анкетаны тутыргандан соң, аны тутыру һәм безгә җибәрү максады белән үзегезнең ибдәшләрегезгә дә бирүегезне үтенә.

Татарстан үзәк музее директоры: Н. Воровьев.
Үзәк музейның шәрык кулъязмалар бүлеге мөдире С. Вахиди.
Гыйльми советның секретаре Иванов.
Казань, Чернышевская 2. Центральный музей Татреспублики.

[1] Мәүзугъ – тема, мәсьәлә.

Татарстан Җөмһүрияте Үзәк музее янында инде берничә еллардан бирле «Шәрык телләрендә язган кулъязма һәм документлар бүлеге» дәвам итеп килә. Әлеге бүллектә инде байтак тарихи хатирәләр җыеп, читтән килгән галимләр һәм Татарстан җөмһүриятенең яшь гыйльми көчләре файдаланырлык уңай хәлгә китерелеп барыла. Тиздән, мәзкүр кулъязма һәм документлардан тулы файдаланырга теләүче гыйлем ияләре өчен, мәзкүр бүлектә махсус уку залы хәзерләнәчәк. Бу турыда гыйльми үзәк зур план белән гамәли хәзерлек алып бара.

1929 нчы елның июлендә, Минзәлә кантонын гыйльми тикшергән «Тарих һәм этнография гыйльми экспедициясе»нең[1] «Тарих һәм лингвистика» бүлеге һәртөрле кулъязма вә документлардан гыйбарәт булган, авыллардан җыелган унбер пот авырлыгындагы кыйммәтле тарихи материалларны алып кайтып, музей янындагы мәзкүр «Көнчыгыш кулъязма һәм документлар бүлеге»нә тапшырды. Мондан соң кантон һәм авыллардан һәртөрле тарихи хатирәләрне мәркәзгә җыю елдан-ел көчәйтеләчәк.

Авыллардан табылган яки хуҗалары тарафыннан гыйлем юлына хезмәт өчен «Көнчыгыш кулъязма һәм документлар бүлеге»нә бүләк ителгән бөтен материалларның кайдан, кем тарафыннан вә кайчан табылганлыгы яки бүләк ителгәнлеге бөтен тәфсыйләте белән махсус каталогка язылып куела барыла, бүләк итүчеләргә махсус рәсми тәшәккер кәгазьләре җибәрелә. Димәк, әгәр дә урынлардагы көчләр, безгә бу турыда ярдәм итсәләр, мәзкүр «Көнчыгыш кулъязма һәм документлар бүлеге»ндә һәр авылның тарихы турында еарым бер «папка» хәзерләп, шул турыдагы бөтен материалларны аерым җыеп барырга мөмкин булачак. Инде бу турыда безнең кулыбызда байтак материаллар да бар һәм шул эшкә керешелде дә. Менә болай булганда һәрбер авыл кешесе музейга килеп, мәзкүр «Көнчыгыш кулъязма һәм документлар бүлеге»ндән

[1] 1929 нчы елның июль аенда Минзәлә кантонындагы гыйльми тикшерү һәм өйрәнү эшләрен алып барган «Тарих һәм этнография гыйльми экспедициясе»нең эшләре белән танышу өчен, «Кызыл Татарстан» газетының 1929 нчы ел, сентябрь 14 ендә (2687) 217 нче номерында «В» имзасы белән басылган «Татарстан кантонларын тарихи якдан өйрәнү» мәүзугысындагы мәкалә укылсын. Шулай ук Минзәләдә чыккан «Игенче» газетының июль 27, 1929 ел, номер 466, «Гыйльми экспедиция эшен бетереп кайтып китде» мәкаләсе һәм шул ук «Игенче» кантоны октябрь 10 ында, 1929 ел, пәнҗешәмбе, номер 475 дә «Минзәлә кантонын тарихи якдан өйрәнү» мәкаләләре карласын. (*Вахиди иск.)*

үз авылының «папка»сын сорап, шул турыда теләгәнчә гыйльми файдаланырга да мөмкин булачак. Шул юл белән авыллар тарихы турындагы һәртөрле тарихи материалларны да ут казасы кебек афәтләрдән саклап калырга да мөмкин булачак.

Югарыда язылганларның барын да күз алдында тотып, Үзәк музей бу турыда җитдирәк адымлар атларга карар кылды. Шуның өчен җөмһүриятебезнең төрле кантонларындагы кантон һәм түбән башкарма рәисләренә, шулай ук кирәк табылган хосуси кешеләргә рәсми мөрәҗәгать итеп, авылларның мөәссәсәләрендә һәм хосуси кулларда саклана торган бөтен кулъязма, документ, шәҗәрә һәм борынгы хатлар турында мәгълүматлар җыеп, аларны тикшерү-өйрәнү вә мәркәзгә җыю турында чаралар күрергә тиеш күрде. Кантон һәм төбәк башкарма рәисләре һәм башка шул турыда безгә ярдәм күрсәтерлек укытучы, комсомол һәм партия әгъзалары шикелле җәмәгать, мәгариф хезмәтчеләре безгә ярдәм итәрләр дип ышанабыз. Бу эшкә беренче гамәли адым итеп, түбәндә язылган анкета сөальләренә җавап язуыгызны (яки яздыруыгызны) үтенәбез.

**Анкета.**

1. Өлкәне өйрәнү яки тарихи хатирәләрне өйрәнү һәм җыю эше белән кызыксынучы аерым кешеләр яки җәмгыятьләрнең эшләгән эшләре турында (аларның тулы адресларын күрсәтеп), безгә язып белдерсәңез иде.

2. Кайсы авылларда вә кемләр кулында язма китаплар, урыс яки татар телендә язылган документлар яки шәҗәрәләр һәм иске хатлар, шулай ук кемләр кулында борынгы архивлар бар. Адреслары ничек?

3. Борынгы сугыш урынлары, искедән калган язулы кабер ташлары, тау тишекләре яки иске акчалар, кылыч, сөңге кебек кораллар табыла торган нинди урынлар бар, алардан табылып килгән әйберләр кайда, кемдә саклаланалар, саклаучыларының адресларын күрсәтә алмыйсызмы?

4. Авылларның башлап корылулары, авылларның тарихларындан кечекдән төрле зурырак вакыйгалар турында нинди хикәяләр, риваятьләр сөйләнгән. Авыллар тарихы турындагы тел мәгълүматларын карт вә карчыклар авызындан ишетеп язып алып, безгә җибәрә алмыйсызмы?

5. Авыллардагы төрле ут казаларында, хосуси коралларда күпме кулъязмалар, документлар, шәҗәрәләр вә башка шундый

тарихи хатирәләр янып юкка чыкканлар. Юкка чыккан әсәрләр арасында, риваятьләргә караганда нинди зурлыкда, нинди кәгазьгә, нинди рәсме хатт белән язылган әсәрләр булганлар, кемдә алар, кайда, кайчан янып юкка чыкканлар, адреслары ничек? Бу турыда тулы мәгълүматны кемдән алырга мөмкин?

6. Элекдә һәм хәзердә китап язу, тарихи әсәрләрне күчереп язу эше белән сезнең тирәдә кемләр, кайда, кайчан шөгыльләнгәнләр, язган әйберләре бармы, кайда, кемдә саклананалар?

7. Борынгы чакларда татарларның ирләр киемләре, хатынлар киемләре ничек эшләнгәнләр, ничек итеп тегелгәнләр, алар нинди формада булганлар, шул турыда карт вә карчыклардан сорашып, язып алып, безгә җибәрә алмыйсызмы, шундый борынгы киемләр кайда булса да калмаганлармы? Ничек дә борынгы бер татарны башыннан аягына чаклы милли киемендә, шулай ук бер татар хатынын да үз милли киемендә киендереп куярлык тулы материалларыны җыеп, язып алырга кирәк иде яки авылдагы егетләрдән шуны рәсем итеп, төрле буяу белән ясап җибәрә алучы булмасмы, һич булмаса, чама белән эшләүчеләр табылмыймы? Без аны ясаучының исемен язып, музейга куяр идек.

8. Борынгы гадәтләр, җолалар, им-том, ырым вә багу итүләр турында тулы мәгълүматлар алып язып җибәрә алмыйсызмы? Яки шул турыда кемгә мөрәҗәгать итәргә? Адреслары ничек?

9. Татар туйлары вә анда булып тора торган һәртөрле җолалар, гадәтләр, тамашалар, туй итү, кияү җуллыгы мәҗлесләре. Кияү булыб керү, килен булыб килү, килен булып кайната кулында хезмәт итү, кияү һәм киленннең борынгы чаклардагы киемләре, хәзерге чаклардагы кием үзгәрешләре, революциянең татар тормышына йогынты ясавы турында, кыскасы элекке һәм хәзерге татар туйлары яки татар туйларының тарихы турында тәфсилле мәгълүматларны халык авызыннан ишетеп язып алып, безгә җибәрә алмыйсызмы, яки бу турыда тулы мәгълүматларны кемләрдән алырга мөмкин, адреслары ничек?

10. Сабан туйларының, җыен атналарының ничек үткәрелүләре вә аларның тарихи килеп чыгулары турында нинди кулъязма һәм тел мәгълүматлары, риваять, хикәя, хәбәр һәм әсатыйрләр сөйләнә, шуларны язып алып, безгә хәбәр итә алмыйсызмы? Яки шул турыда кемгә мөрәҗәгать итәргә, адресы ничек?

11. 1905–1917–1918 нче елларның революция тарихын өйрәнүдә нинди риваятьләр һәм докуменилар бар, бу турыдагы тулы

мәгълүматларны кемдән, кайдан алырга, адреслары ничек? Революция тарихын өйрәнү белән шөгыльләнүче «түгәрәкләр-җәмгыятьләр» яки хосуси кешеләр бармы, аларның адреслары ничек?

12. Югарыда соралган әйберләрдән башка тагын нинди әйберләр турында авыл күпчелегендән сорарга-тикшерергә кирәк дип уйлыйсыз? Шул турыданиләр яза аласыз?

*Искәрмә*: югарыда соралган маддәләрне һәрберсен аерым бер мәүзугъ итеп, һәр берәм-берәме өстендә бер кеше эшләп, мөмкин чаклы төплерәк итеп язып, безгә хәбәр итсәләр, яхшы булыр иде.

Без монда шуны да күздә тотдык, авылларда мондый гыйльми эшләр белән кызыксынучы укытучылар, яшьләр байтак күп күренәләр. Ләкин аларның кулларында «кулланма» булып хезмәт итә торган бер нәрсә дә юк. Менә бу сөальләр аларның күңелләрендә тарихи әсәр, кульязма һәм документларны, шулай ук татарның борынгы һәм хәзерге этнографиясенә караган бөтен материалларны җыюның һәм революция тарихын өйрәнүнең кирәклеген аларның күңелләрендә бер якдан уята торган булса, икенче якдан шул ук вакытда бу эшне бер билгеле системада алып бару өчен кулланма хезмәтендә вакытлы рәвешдә үти алачак. Безнең өчен тарих, этнография һәм революцияләр тарихына караган материалларны тикшерергә, өйрәнергә һәм җыярга кызыксынучыларның күбәюләре кирәк.

Шуның өчен без укытучы, комсомол, партия әгъзасы кебек мәдәни хезмәт ияләренең мондый эшләргә әһәмият бирүләрен теләү белән бергә, алар аркылы киләчәкдә зур эшләр эшләүне өмид итәбез.

Монда шуны да әйтеп китәргә тиеш була ки, һәрбер кантонның үзәк каласында кечкенә генә булса да, тарих һәм этнография бүлекләрендән генә гыйбарәт, ягъни әүвәле бер-ике бүлекдән генә торган кечкенә музаханә булса да нигезләргә, авылларда табылып килгән тарих вә этнография материаллары шунда җыелырга тиеш иде.

Мондый музейлар гыйльми экспедицияләр барганда, шул кантонның тарихи әйберләре җыелган бер базасы урынын тотарлар иде. Гыйльми тикшерү эшләре, табигый уларак, елдан-ел көчәя барырга тиешләр. Революциядән соңгы мәдәни үсешебез бездән шуны сорый, безгә зур киңлекләр биргән революциянең кызу дәвамындагы тирәнәю һәм көчәюдә татардан зур гыйльми багажлы күп егетләрнең өлгереп җитүләрен теләп кала.

*Искәрмә:* сезнең тирәдә булган җавап язарлык ипдәшләргә бу анкетаны биреп, күбрәк авыллардан җавап яздырту турында безгә булышлык итүегезне үтенәбез.

Адрес: Казань, Чернышевская улица Центральный Музей А.Т.С.С.Р. отдел Восточных Рукописей.

Казан, 1929 нчы ел, 23 сентябр.

## Сәед Габделманнан углы Вахидинең хатирә дәфтәрендән бер кисәк

1928 нче ел, июнь аеның беренче яртысында Ыспас кантонында тарихи әсәр, кульъязма һәм кабер ташларын тикшерү вә җыю өчен ясалган йөрешнең – поездка[1] (хатирә дәфтәре) хисабы.

Йөрешнең – поездка, программасы:

1 – таратылган анкета белән җыелган мәгълүматлар буенча миңа мәгълүм булган авылларга барып, иң әүвәле шушы мәгълүматларны дөресләп тикшереп чыгылыр, мондан соң, шушы авылның кара тарихка оста булган иң карт кешеләрендән, мәсәлән, җитмеш-сиксән яшендәге карт вә карчыкларындан, белергә тиеш күрелгән тарихи мәгълүматлар турында сөальләр бирелеп, мосахабә (утырыш – беседа[2])лар ясалыр. Ишетелгән әһәмиятле тарихи мәгълүматлар утырыш вакытында язылып, сөйләүчегә соңындан укып чыгып, анардан дөресләтер.

2 – кабер ташлары, каберстанлар вә аларның тарихи әһәмиятләре. Шушы авылның халкына, авылына булган мөнәсәбәтләре, ул ташларның моңар кадәр гыйлем ияләре тарафыннан укылып-укылмаулары, аларның тәләф булган[3] нөсхәләре турында тулы, шифаһи[4] мәгълүматлар җыелыр. Әгәрдә моңа кадәр кем тарафыннан булса да ул кабер ташлары укылган булса, аның укылу вакыты әгәрдә табылса, ул укучының гыйбарәсе кулга төшерелер. Бу турыдагы мәгълүматларда риваять итеп сөйләүчеләренә укылып, алардан дөреслеге тасдыйк итдерерләр[5].

3 – кульъязма тарихи әсәрләрне, документларны тикшерү, кирәк табылганларын сатып, яки китап белән алышдырып алу,

---

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[3] Тәләф булган – һәлак ителгән.

[4] Шифаһи – телдән.

[5] Тасдык итдерерләр – расларлар.

әгәрдә кульязмаларны тикшерү вакытында карап үтелгән кульязмаларның хашияләрендә[1] әһәмиятле мәгълүматлар бирелсә, аларны шундук үз имлясы белән язып күчереп алыныр.

Искәрмә:

1 – каберташларының зурлыгы, ташның сыйфаты, рәсме хатты[2], калкытып, яки казылып язылу шикелле хосусиятләре, имлясындагы аерым яклар, михрабындагы бадиян билгеләре, ачык итеп, тулы рәвешдә язылып алыныр. Шулай ук ташның бөтен язуы эстампажга, мөмкин булса фотография аппараты белән рәсемгә алыныр.

2 – кульязмаларның зурлыклары, кәгазьләре, язылу тарихлары, кайсы фәндән икәнлекләре, мөхәррир[3] һәм соңгы күчерүчесе кем вә кайчан күчергәнлеге ачык итеп язылып алыныр.

3 – Карт вә карчыклар белән мосахәбәнең[4] планын, соралырга тиешле сөальләрне, алардан ишетелергә, хәтерләрендән саклап килә торган бөтен тарихи мәгълүматларны алардан сөйләтеп бетерү турында эшләнергә тиеш булган бөтен хәзерлекләрне алдан күрелергә тиешле. Шуның өчен картлар мосахәбәләр уздыру планы, аларга бирерлергә тиешле бөтен сөальләр, алардан алынырга тиешле мәгълүматларның ни кыяфәттә икәнлекләре хакында булган махсус план алдан хәзерләнеп барылыр.

**Ыспас кантонындагы йөрешнең эш планы:**

Минем Ыспас кантонына булган йөрешемнең эш планын икегә аерырга мөмкин.

1 – авылларның эчендә тарихи тикшеренү, тарих материалларны җыю эшен алып бару.

2 – авылларның тышында, мәсәлән, калалар өстендә, шәһәр хәрабәләрендә, курганларда, каберстанларда гыйльми тикшеренүләр ясау.

Әмма авылларның эчендә кульязмалар һәр төрле документларны тикшерү эшен алып бару, бу хосусый кешеләрнең көтепханәләрендәге кульязмаларны мәчет очырмаларындагы[5] ташландык кәгазь төргәкләрен, андагы һәртөрле таркау кәгазьләрне актарып, тикшереп чыгу юлы белән үткәзелер. Шулай итеп эш планы:

[1] Хашияләрендә – китап читенә язылган язмаларында.

[2] Хатты – язу стиле.

[3] Мөхәррир – автор.

[4] Мосахәбәнең – сөйләшеп утыруның.

[5] Очырмаларындагы – чормаларындагы.

1 – авылларның эчендә.

2 – авылларның тышында, икегә бүленеп эшкә ашырылу юлы белән, минем тарафдан кабул ителде.

Мәзкүр[1] йөреш өчен минем тарафдан кабул ителгән маршрут:

1 – Казан
2 – Ыспаский затон
3 – Ыспас шәһәре
4 – Коллар авылы (Коралау)
5 – Ташбилге
6 – Иске Баллы Күл
7 – Урта Салман
8 – Янбакты
9 – Такталы
10 – Йорткүл
11 – Сувар
12 – Чәчәчкле (Яңа Рәҗәб)
13 – Иске Рәҗәб
14 – Төгәлбәй
15 – Иске Салман
16 – Көек
17 – Коры Көрнәле
18 – Әҗмәр.

Әҗмәрдән Коллар, Ыспас һәм затон аркылы Казанга кайтылды. Бу йөрешдә тарихи якдан әһәмиятле материал җыю өчен кирәкле табылган авылларны гына маршрутка кертелде. Бер авылны үзәк итеп алып, ул авылдан барып кайту юлы белән тикшерелгән, шәһәр хәрабәләре, кала өсләре, курганлар, каберстанлар, хәндәкләр[2] бу маршрутка кертелмәделәр. Алар турысында гомуми изах[3] язганда, сүз арасында гына язылып үтелде.

1928 нче ел, июньнең унында, Татарстанның Үзәк музәханәсендән алган командировка буенча, төшдән соң сәгать бишдә, Әстерханга бара торган зур пароход белән Ыспаска китдем. Минем белән бергә этием дә Ташбилгегә кадәр юлдаш булып кайтды.

11 нче июнь, иртә белән сәгать өчдә Ыспас затонына җитдек. Андан ат белән Ыспас шәһәренә кайтдык. Ыспас шәһәренең

---

[1] Мәзкүр – алда әйтеп үтелгән.

[2] Хәндаклар – траншеялар.

[3] Изах – аңлату.

урамлары гаять пычрак, икмәк төяп килгән авыл кешеләрнең арбалары көпчәк бүлкәнендән бата торган, изелеп суга катышкан сыек балчык, кулы белән тулган хәлдә ята иде. Базары бик ярлы, гәрчә бүген дүшәнбе көн, базар көне булмаса да, анда берничә чирек сөт, бер-ике олау күмер, биш-алты олау такта, агач, егерме бишутыз арба авыл мужиклары базарга төяп килгән икмәкдән (арыш, солыдан) башка әйбер анда минем күземә чалынмады. Ыспасда бер дворга туктап ике сәгать ял иткәч, Ыспасдан Ташбилгегә кадәр Иске Чаллы авылының Закир Мөхәммәтша улы дигән бер мөслеманны, өч сум илле тиенгә яллап, Ташбилгегә чыгып китдек. Мин бу кешенең атын башдан күрмәгән идем. Ул миңа атының яхшылыгын сөйләгәч, мин аңар ышанган идем. Арбасына утырыб чыккач, бу кешенең аты бик җаман, хуҗасы кыйнаса да, көчкә генә бара торган начар ат булып чыкды. Безнең бара торган юл өстендә туктап ял итеп, ат ашатып чыга торган авыл Янбакты авылы Ыспасдан егерме ике чакрым ераклыкда иде. Әнә шул егерме ике чакрым мәсафәне[1] без бик озак бардык. Иртә белән сәгать җидедә чыгып, төшдән соң сәгать икенче яртыда гына без Янбактыга барып җитдек. Янбакты авылында мин Закир Мөхәммәтша улына сөйләшкән акчасының тиешле микдарын биреп аны үземнең авылына кайтарып җибәрдем. Әмма үзем төшдән соң сәгать дүртдә Янбакты Хафиз Гәлиевнең атын, тарантасын алып, үзем кучер булып, Ташбилгегә чыгып китдем. Шул ук көнне кояш баер алдындан Ташбилгегә килеп җитдек.

I Ташбилгедә

Июньнең унбере, дүшәнбе көн кич Ташбилгедә үзебезнең өебездә кич үткәздек. Ул көнне вакыт бик соң булганга күрә, бер нәрсә дә эшли алмадык. Июньнең уникесе, сишәнбе көн Ташбилге авылында булган мосахабәләр:

<u>1 – үземнең җитмеш сигез яшендәге әтием белән булган мосахабә.</u> Ташбилге авылының тарихы турында мосахабә вакытында, әти миңа түбәндәге мәгълүматларны бирде. Ташбилге бик иске, тарихи авыл. Ташбилегенең иң әүвәле, башлап корылуы, шәһре Болгарның[2] Аксак Тимер тарафыннан һәлак ителүендән соң, шәһре Болгардан күчеб килгән Мөслим баба белән башланган дип, безгә

---

[1] Мәсафәне – араны.

[2] Чыганакта «шәһре Болгар», «шәһәре Болгар» вариантлары икесе дә очрый. Текстта «шәһре Болгар» вариантын гына калдырдык.

сөйлиләр иде. Әти: «Мөслим бабаның янында үзенең иярченләре дә булган икән, алар да шунда, аның белән бергә килеп утырганлар. Мөсли баба бик галим, бик изге кеше булган, шәһре Болгарда вакытда Болгарның олылары аны олылыйлар икән, хәтта Болгар ханы үзе дә аны зурлап сараена, үз катына кертеп хөрмәт кыла икән дип, сөйли торганлар иде», – ди. Әти үзенең сүзендә дәвам итеп әйтә: «Мөслим бабаның уллары, улларының уллары да галим кеше булганлар дип, сөйли торганлар иде. Мөслим бабаның нәселендән, бәлки аның улының улындан булгандыр, мондан берничә йөз еллар алда Шәрәфетдин Мөслими дигән бер укымышлы галим кеше булган. Аның улы Хисаметдин хәзрәт булган, бу Хисаметдин хәзрәт Мөслими бик күп җирләрне йөргән, күп галимләр белән утырышкан, галим һәм дөнья күргән кеше булган. Хисаметдин Мөслими ул безнең ерак бабабыз була. Аның язып калдырган бик күп китаплары булган, алар инде каядыр таралып беткәнләр. Ихтимал тулы ут казалары вакытында юкка чыкканлардыр. Әле бездә Хисаметдин хәзрәт Мөслими язган «Тәварихе Болгария» исемле тарих китабы бар иде. Анда байтак иске тарихи хәлләр сөйләнә иде. Мин аны һаман укый торган идем, инде ул хәзер синең кулыңда булырга кирәк», – ди (Х. Мөслиминең әти кулында булган нөсхәсе хәзер минем көтепханәмнең кульязмалар бүлегендә саклана) – Хисаметдин хәзрәт Мөслиминең зиярәте, – ди әти. – Ташбилгенең изгеләр басуы дигән кырында, Озын Алан тавы башында. Хәзерендә дә каберенең иңеп төшкән чокыры мәгълүм, элгәре заманда язулы ташы да булган, хәзер инде юк. Әнә шунда аның һәм шул тирәдә Мөслим бабаның үзенең кабере дә булган дип сөйли торганлар иде, – ди. – Без кечкенә вакытларда кара тарих сөйләргә оста булган озын буйлы борынгы картлар, карчыклар бар иде, алар Мөслим бабаның кабере өстендә зур, матур итеп язылган язулы каберташы булганлыгын сөйли торганлар иде», – ди.

Ташбилгедәге халыкларның нәселләре турында сорашкач, әти әйтә: «Ташбилгенең төп халкы әнә шул Мөслим баба нәселендән килгән зур бер нәсел кешеләр дип, элеке элекдән атадан балага сөйләнеп, күчерелеп килә. Ташбилгедә Ишем җәвере[1], яки Ишемнекеләр дип йөртелә торган икенче бер нәсел халык бар. Менә бу Ишем җәвере Тәтеш өязендә ниндидер бер җинаять белән гаепләнеп, андан качып, Ташбилгегә килеп урнашканлар дип әйтәләр.

[1] Җәвере – монда: нәселе.

Дөресрәге, Тәтеш өязе Ишем авылыннан сөргенә йибәрелгән кешеләр диләр. Авылдагы җыртлач, усал куштанлар әнә шул Ишем җәверләрендән чыгып килгән, югыйсә, Ташбилгенең үз халкы юаш, мәрхәмәтле, кешегә ярдәмле халыклар. Билгеле, Ташбилгенең башыннан да, Мөслим баба заманыннан бирле инде бик күп хәлләр кичкән, бик куркынычлы вакыйгалар булып үткән. Без кечкенә чагында сөйли торганлар иде, авылга урыс солдатлары килеп талап китү вакыйгалары булганын. Әнә шул чакда да халык урманга качып, айлар буенча авылга кайтмыйча, урманның ерак аулак почмакларында яшеренеп яталар икән. Кешесез калган авылга кереп, урыс солдатлары авылны талыйлар, андагы малларны үзләре белән алып китәләр, авылда мал аз чыкса, авылга ут төртеп, яндырып китә торганлар иде, – ди. – Пугач[1] җавы заманнарында, Ыстинка Разин[2] кузгалышларында да халык бик авыр көнләр үткәргәнен, без кечкенә чагында картлар сөйли торганлар иде. Имеш, Пугачев үзенең чирүе белән килеп авылларда балаларны сөңге башларына күтәртдереп йөрткән, кешеләрне үтертдергән, өйләрне яндырган, дип сөйли торганлар иде. Әнә шундый хәлләрдән соң инде, әлбәттә, авылда байтак үзгәрешләр булгандыр. Хисаметдин хәзрәт Мөслиминең язган китаплары да, бәлки, шундый вакытларда әрәм булгандыр», – ди. Шуннан соң әти Ташбилгенең үзе яшь вакытындагы кайбер якларын болай тасвир итә. Ул әйтә: «Кечкенә вакытта, димәк, моннан җитмеш еллар элек, Ташбилге бөтенләй урман эчендә тора иде, иген басулары урман араларындагы зур-зур аланнардан (ачык мәйданнардан) гыйбарәт иде. Авыл янында һәрбер басуда «киләкләр»[3] бар иде. Ул заманда урманда чикләвек бик күп була торган иде. Көз көне чикләвекне олаулап җыялар, аны киптереп саталар да, үзләренең авыл хуҗалыгы кирәк-яракларына да тотар өчен, яхшы гына акча хәзерли торганлар иде. Чикләвекне әүвәле киләкләрдән җыя башлый торганлар иде. Ул чакларда халык тормыш өчен артык ватылмый, җирләр яңа, иген – тару бик уңа, халыкда умарта күп, агач нәрсәсенә бик муллык, хайванны бик күп асрый торганлар иде. Ат кебек эре хайваннар кыш көне дә байтак вакытлар урман эчендә тибенеп, җәйдән калган печәнне ашап йөриләр, байтак вакытка кадәр сыер һәм сарыклар да, кышның әүвәлге айларында урманнарда йөртелеп утлатылалар – бу

[1] Пугач – Пугачёв Емельян Иванович (1742–1775).

[2] Ыстинка Разин – Степан Тимофеевич Разин (1630–1671).

[3] Киләкләр – умарталык өчен бүлеп алынган урыннар.

эшләрнең дә, барысы да халыкка тормыш өчен бик зур җиңеллек китерә иде. Ул заманларда өйләрне калын бүрәнәләрдән салалар, өй түбәсендәге такталар, балта белән ярылып ясалган тупас калын такталар тезелеп ябыла торганлар иде. Ул чакларда авылның урамлары бик тар, каршы килгәндә ике ат көчкә үтәрлек, өйләр урамдан эчкә кертелеп салынганлар, ишек алларының капка вә коймалары урам ягыннан өйне каплап тора торган иде, эшләткән була торган иде. Ул заманда халык бик кызык, җәй көннәрендә күбесенчә урамда, чирәм өстендә түгәрәкләнеп утырып, сөйләшеп көн үткәзәләр, авыррак эшләрне өмә белән эшләтәләр, өмәгә чакырылган кешеләр ул заманда баручан, өмәдән кайткач тары боткасы ашаталар, андан соң җырлашып сыра эчә торганлар иде. Кыш көне зур өмә булса, ишек алдына ут ягып, шунда өмә мәҗлесе үткәзәләр, шунда җырлашалар, биешәләр иде.

Яз көнендә, бәйрәм көннәрендә егетләр, кызлар урманга «киләкләргә» бара торганлар иде. Алар анда җырлашалар, биешәләр, таган асалар, «таган астына бару» дип, дан тоткан яшьләр тамашаларын үткәзә торганлар иде. Ул заманда авылның бәрәнге бакчалары артында бик куе зирәклек, таллык булып анда качкыннар ята, дип сөйли торганлар иде. Ул заманда урманнарда җылан бик күп була иде. Язның бер вакытында «печән өеме» шикелле өелеп, башларын тышка чыгарып, койрыклары белән бер-берсенә уралып яткан җылан өемнәрен урманга барган кешеләр җыш очратканлыкларын сөйлиләр иде. Ул вакытларда безнең бу як урманнарында да аюлар күп булган. Хәзер безнең Изгеләр басуы дип йөртелә торган кырда «Аю аланы» дип йөртелә торган урын, безнең урманнарда аюлар яшәгән вакытда бирелеп калган бер исем. Ул чагында халыкның тормышы менә болай иде: ирләр һәм хатыннар күк киндер күлмәк кияләр, аякларында тула оек белән чабата, ирләрнең башында кәләпүш, яки ак эшләпә, хатыннарның башында зур француз яулык була торган иде. Ирләрнең күк киндер күлмәкләренең якалары бик киң, иңбашына кайтарылып төшә. Изү баулары озын булып, бәйләгәч салынып йөри, култык астында дүрт почмаклы кызыл француз материядән кештәк була иде.

Яшь киленләрдә «тел яшерү» дигән бер гадәт булып, кайнаталары алдында кычкырып бер сүз дә эндәшмиләр, тик усал киленнәр генә кайнатасына хәкарәт[1] сүзләр әйтергә теләгәндә, ачыкдан

---

[1] Хәкарәт – хурлык, кимсетү.

ачык тел озатып[1] сөйләшәләр, соңыннан: кайнатасына тел ачкан бит, дип, халык арасында мондый киленләрнең начар исеме чыга. Кара! Оятсыз икән, кайнатасына тел ачкан, дип сөйлиләр иде. Ул чакларда яшь киленләр кайнаталары алдында, «калым»га бирелгән мехлы камзолларын, кисмәгән куш яулыкларын (ике зур яулыкны) бер дә башларыннан салмыйча йөри торганлар иде. Бер вакытда бер килен кечкенә генә бер өйдә, кайнатасы алдында, мич кашында коймак пешергән. Өстендә мехлы камзол, башында куш яулык булган, мич эссесендә пешеп үлер чиккә җиткәндә, кайнатасы аның хәлен күреп, ачу белән: ник салмыйсың ул камзолыңны, дип кычкырган да, шуның соңында гына яшь килен камзолын салып, бераз сулыш алган, дип сөйли торганлар иде. Әле минем хәтеремдә, ул вакытда әче эчмиләр, тәмәке тарту гадәте бөтенләй халык арасында юк. Көненә өч тапкыр аш пешереп ашыйлар, эш өсләрендә салкын суга катыкдан әйрән язып эчәләр, хәллерәк кешеләр чүлмәк утырталар. Болай, гадәттә, һәркем тарафыннан чәй урнына су эчелә торган иде. Ул чакларда халык ире һәм таза бәдәнле, олы сымак, эчеп-исереп йөрү гадәте бөтенләй юк, фәхеш халык арасында һичбер беленми, зина кылуда гаепләнгән ир вә хатын урамга чыгарылып, йөзләренә корым сөртелеп йөртелгән. Кызларда шундый хәл булса, капкалары карага буяла, үзе халык күзеннән төшә иде. Андый кызга бәет чыгарып, урамларда җырлап йөриләр иде. Ул чакларда халык ата-бабасыннан килгән гореф-гадәтләрен зур хөрмәт белән олугълап, аңар баш ияләр, аңар каршы килү – кешелек кануннарына каршы килү итеп игътикад кылынганга[2], халык бу эшләрнең барысына да бер сүзсез баш ия торганлар иде», – ди. Шуннан соң эти Ташбилге авылындагы «Изгеләр өсте» дип йөртелә торган иске каберлекләрне болгарлар заманыннан калганлыгын, ул каберлекләрне Ташбиге кешеләре генә түгел, бәлки шул тирәдә дә булган бөтен татар авылының кешеләре ихтирам итеп, анда килеп зиярәт кылуларын, андагы изгеләр рухына һәртөрле нәзерләр – ниязлар әйтүләрен сөйли.

Ташбилге авылындагы кульязма китаплар турында эти түбәндәге мәгълүматларны бирде. Ул болай сөйли: «Безнең Ташбилге авылында безгә мәгълүм булмаган иске заманнарда ук укымышлы кешеләр күп булып килгәнләр. Безнең авылда борын-борыннан ук

[1] Дөресе: озайтып.

[2] Игътикад кылынганга – ышанганга.

укый-яза белмәгән кеше бездә бик аз булган. Һәркем язу-сызу эшен үзе алып барырлык, төркичә укый да алган. Базарда алган мәгънәле китапны укый белә торган кешеләр дә һаман безнең авылда байтак булып килә. Безнең авылдан китеп [..][1] Сибириядә берничә кеше мәншүрле[2] имам булып тордылар. Бездә мәдрәсә дә бик иске заманларда ук булып, анда бик күп шәкертләр укып килгәнләр. Шуның өчен һәрбер өйдә берничә язган китап, язган Һәфтияк, Коръән кебек кулъязмалар күп булырга тиеш иде. Ләкин шул авылда зур-зур янгынлар булып үткән, шул чакларда инде алар янып беткән булырлар. Әүвәле бит, – ди эти, – бөтен дәрес китаплары фәкать язылып кына укыла иде. Әле без кечкенә вакытда авылларда басkан китаплар юк дәрәҗәсендә азайды, һәркем дип әйтерлек, баласын языргa өйрәтү өчен дә, күбрәк китап яздырырга тырыша иде. Язуга бик оста кешеләр, башкаларга сатар өчен дә китап язалар иде, хәтта кайбер галимләр китап язып, шуны сатып көн иткәнләр, мондый кешеләр ул заманда аз булмаганлар», – ди. Андан соң эти Ташбилге авылының мәшһүр хәзрәте Сафа хәзрәт Габбасовның көтепханәсе хакында сөйли, ул әйтә: «Безнең Ыспас кантонында иң бай көтепханә Сафа хәзрәт Габбасовның көтепханәсе иде. Аның көтепханәсендә әллә ничә мең җилд[3] китап бар иде. Алар Ташбилге авылына нәселдән нәселгә мулла булып килгән кешеләр булганлыгыннан, шөбһәсез, аларда язган китаплар да күп булгандыр. Ләкин Дөнья сугышы башланудан берничә еллар алда, аның йорты, бөтен каралтылары янып юкка чыкды. Шул янгында аның бер китабы да чыгарыла алмадылар. Әнә шул вакытда янып юкка чыкдылар», ди[4].

---

[1] [...] укылмый калды.

[2] Мәншүрле – указлы.

[3] Җилд – данә.

[4] Этинең сөйләвенә караганда, ул кечкенә вакытда безнең ерак бабаларыбыздан килгән, әбинең сандыгында бик кадерләп сакланып килә торган документлар булган. Бу документлар җир, су биләү турындагы рәсми кәгазьләр, хөкүмәт тарафыннан бирелгән ыльгота кәгазьләре булган. Эти кечкенә вакытда аңар әби: «Бу кәгазьләр белән безнең борын заманда Күгәрченледә булган җир-суларыбызны да кайтарып алырга була – дип, – бабагыз сөйли», – дип әйтә булган. Бу документлар да әле кечкенә вакытдагы бер янгында янып харап булганлар. Болар тарханлык грамоталары (тарханлык ярлыгы) булган булырга кирәк. Этинең сүзендән шулай аңлашыладыр. (С. Вахиди искәрмәсе)

2 – Ташбилгедә Хәлилулла Хәмидулла угълы белән мосахабә. Ташбилгенең шәрык ягы күршесендә Биктимер исемле татар белән урыс катыш бер авыл бар. Менә бу авыл борын заманда саф бер татар авылы булган. Шушы авылдан Ташбилгегә Хәлиулла Хәмидулла угълы дигән бер кеше күчеп килеп утырган. Бу кеше аңлы гына, күп кенә җирләрне гизгән, яхшы ук белеме бар, тарихдан хәбәрдар бер кеше. Мин шуның белән мосахабә итдем. Ул минем белән булган мосахабәсендә миңа түбәндәге мәгълүматларны сөйләде. Хәлиулла Хәмидулла угълы әйтә: «Мин үзем нәсел-нәселдән яшәп килгән Биктимер авылының бер кешесе, соңгы заманларда Биктимердә мөслеман тәмам азайды, хәзер анда барлыгы өч йорт мөселман гына калган. Әүвәлдә Биктимер зур бер мөслеман авылы булган. Әле мондан кырык еллар алда гына Биктимер авылында илле йортлап мөслеман бар иде. Мондан йөз еллар алда булырга кирәк, Биктимер авылының кешеләрен налог түли алмауны сылтау итеп, үзләренең ихтыярларындан башка православный динендәге кешеләр ысписккасына[1] язганлар. Халык һаман ата-бабадан бирле килгән ислам динендә калырга теләгән. Патшалар хөкүмәте безнең бабаларны ныклап урыс итәргә керешкән, гәрчә, алар үзләре теләмәсә дә, бабайларны көчләп чиркәүгә алып барганлар, поплар авылларга килеп яшь балаларны көчләп чукындырганлар, үлекләрен поп белән күмүне бабайларга мәҗбүри канун иткәнләр. Бу юллар белән дә көчләп бабайларны урыс итеп бетерә алмагач, аларны берәр-икешәр семья итеп, кап-кара урыс авылларына таратканлар. Бик күбләре, урыс авылына баргач да, үз динләрен тотарга азапланып, попларның кушуы буенча, урыслар тарафындан кыйналып үтерелгәнләр. Без кечкенә вакытда менә шундый вакыйга сөйлиләр иде: безнең Биктимер авылындан бер йорт мөселманны, бер кара урыс авылына илтеп алактырганлар. Аларны кечкенә генә бер өйгә куйганлар. Поп килеп бик үгетләгән, урыс булырга кушкан, болар тыңламаганлар, шундан соң ир белән хатынның кул-аякларын бәйләп алып китеп, куенына аз гына икмәк белән су биреп, ун көн бер кара мунчага ябып тотканлар. Алай да болар урыс динен кабул итмәгәч, мунча миченә чи кара бодай саламы ягып, төтенгә асып азаплаганлар. Ул бичаралар шунда куе, әче төтенгә буылып үлгәннәр. Үзләрендән соң балаларын чукындырып урыс иткәнләр. Менә мондый хәлләр безнең бабайларның башын-

[1] Дөресе: списогына.

дан бик күп кичкәнләр. Менә шул тарика[1] җәбер, золым астында, безнең бабайлар туган үскән илләрендән көчләп таратылып, урыс авылларында бик күбесе юк ителгәнләр. Алар урнына безнең Биктимергә урыс китереп урнашдыра барганлар. Шундан Биктимер авылы бара-бара урыс авылына әйләнеп киткән. Соңга таба кайбере көчләп чукындырылган, ләкин чын-чында һаман ислам динен тота торган нык игътикадлы[2] мөселманлар, Биктимер авылын ташлап, Кавказ ягына, мөслеман көчле булган йирләргә күчеп киткәнләр. Әле без яшь чакда да алардан һаман хәбәр килеп торганын сөйли торганлар иде». Хәлилулла агай Биктимер авылының искерәк тарихы турында түбәндәге сүзләрне сөйли, ул әйтә: «Без яшь чакларда авылда сиксән, туксан яшьлек картлар бар иде, алар аулак өйләргә җыелып, урысларның аларга күрсәткән җәбер-золымларын, көчләп чукындыруларын, үзләренең һаман да ата-баба дине булган ислам динен яшертен рәвештә тотып килүләрен, яшь буынларга да, гәрчә алар поп килгән чакларда урысча кылансалар да, эчдән үз динләрен, ислам динен тотып яшәргә тиешлек турында үгет вә нәсыйхәт итешкәнлекләрен күз яшьләрен агызып сөйләгән чакларында: «Әй, балалар, без бит бик иске-искедән мөселман булып килгән кешеләрнең балалары, безнең бит, бу авылыбызда бик иске заманлардук бабаларыбыз мөселман булып яшәгәнләр, безнең Биктимер баба башта шәһре Болгардан күчеп килгән, безнең авыл шуның нәселендән таралган», – дип сөйләгәнләре әле дә минем хәтеремдә. Тагы мин шуны хәтерлим, шундый җыелышып үзара вәгазь, нәсыйхәтләр итешеп, моның зарларын сөйләшеп утырганда, алар ниндидер бер язган китап укый торганлар иде. Ул китапта шәһре Болгар турында, борынгы сугышлар турында, шәһре Болгардан халыкның таралуы турында төрле вакыйгалар укыганлыклары әле дә минем исемдә. Ул язган китапны Биктимер халкы бер-берсенә биреп, укып йөртәләр иде. Соңгы вакытда инде ул китап кая киткәндер, мин белмим. 1905 нче елдан соң ислам диненә рәсми рәвешдә чыкгандан соң, үз арабыз ул китапны эзләп тә карадык, ләкин табылмады. Кайбер кешеләрнең әйтүенә караганда, ул китапны Кавказ ягына киткән кардәшләребез алып киткәнләр икән». Шул ук Хәлилулла Хәмидулла угълының әйтүенә караганда, Чистай кантоны Урман Асты Шынталысы авылында аларның

[1] Тарика – юл, ысул.

[2] Игътикалды – ышанучы.

кардәшләре бар икән. Бу кеше шуларга зиярәт барганда, мәзкүр Шынталы авылының мулласы аңар бер язган китап күрсәткән, бу кулъязма китапның Шынталы тарихы турында язылган икәнлеген сөйләгән. Шул ук кешенең риваятенә караганда, Мәләкәскә бара торган Самар юлы өстендә тирән чокыр итеп казылган орлар, хәндаклар[1], шәһәр урынлары бар икән, ул бер урынларны Мәләкәскә бодай онлары алырга барганда күргән икән.

<u>3 – төрле кешеләр белән мосахабәләрнең якүне[2].</u>

Ташбилге авылында югарыда язылган тәфсилле мосахабәләрдән башка, тиешле күрелгән берничә кешеләр белән дәхи[3] кыска-кыска мосахабәләр ясалды. Ул мосахабәләрнең аерым-аерым хисапларын язып тормыйча, бәлки аларның барысындан җыйналган гомуми мәгълүматларның якүнен генә бу урында язып китәбез.

Безнең белән мосахабәдә булган кешеләрнең барысы да, түбәндә язылачак, әсаси тарихи мәгълүматларны барысы да бер төсле үк дип, әйтерлек сөйлиләр:

*Ә* – Ташбилге авылы, шәһре Болгардан күчеп килгән Мөслим баба вә аның угыллары (иярченләре) тарафындан бонда, берничә йөз еллар алда корылган бер авыл.

*Б* – Мөслим баба галим һәм изге кеше булган. Аның игътибары шәһри Болгарның олугълары арасында, хәтта Болгар ханы каршында да, зур булган.

*Т* – Ташбилге мондан берничә йөз еллар алда, Мөслим баба нәселендән, Хисаметдин Шәрәфетдин угълы (кайберәүләрнең әйтүенә караганда Хисаметдин хәзрәт) яшәгән. Ул бик зур галим һәм бик күп җирләр күргән олугъ кеше булган. Хисаметдин Шәрәфетдин угълы күп китап язу белән шөгыльләнгән. Аның «Тәварихы Болгария» исемле китабы һәркем тарафындан әлегә чаклы бик яратылып, укылып килгән китаплардан.

*Җ* – Хисаметдин хәзрәт Мөслиминең, шулай ук Мөслим бабаның үзенең дә, каберләре Ташбилге авылының Изгеләр өсте басуы дип йөртелә торган кырның Озын алан тау башында, авылдан китеп Озын алан чокырына таба төшкәндән соң уң якда (шәрык ягында) борын заманларда кабер ташлары да булган, хәзерендә бары иңеп төшкән чокырлары гына калган.

---

[1] Хәндаклар – траншеялар.

[2] Якүне – йомгагы.

[3] Кешеләр белән дәхи – кешеләр белән дә.

*Х* – Ташбилге авылының инеше булган Актачы суының ике ягында булган (шәрек һәм гареб ягында) Изгеләр өсте, яки Якшылар[1] өсте, дип йөртелә торган каберстанларга күмелгән кешеләр, Ташбилге халкының борынгы бабалары, алар барысы да ислам динендә булып дөньядан үткәнләр. Шуның өчен Ташбилге халкы бу каберстанларны бик олугълый, анда барып зиярәт кылалар, нәзерниязлар әйтәләр, ул каберстандагы үскән печәнне чапмыйлар. Анда үскән җиләкне ашамыйлар, ул каберстанлар янына хаҗәт үтәргә утырмыйлар, әгәрдә урыс-чуашдан берәү каберстанлар янында тышка чыкса, аны Ташбилге кешесендән берәү күрсә, бу эшне бабайларны тәхкыйрь итү[2] дип карап, шул урынны пакьлатмыйча торып, теге урыс, яки чуашны тышка чыккан урыныннан йибәрмичә тотып торалар. Бу турыда бик күп булып үткән вакыйгаларны риваять кылып сөйлиләр. Бер вакытда, Матак базарындан кайтышлый, бер Кората чуашы Тау ягы Изгеләр өстенең тирәсенә казылган чокырның шәрык ягы өлешенә төшеп тизәкләгәнен күргәч, берничә Ташбилге кешесе җыелып килеп, башындагы картусына салдырып, үзе белән йибәргәнләрен бик зур вакыйга итеп сөйлиләр. Татарлар кашында бик мөкаддәс ителеп танылганлыгын төшенгәнгә күрә, Ташбилге авылының үзендә яшәүче урыс һәм чуашлар да, бу каберстандан үткәндә бик саклык белән, аларга һичбер төрле хөрмәтсезлек күрсәтмичә узып йөриләр икән. Әмма татарлар уракга, сукага, яки урманга, яки көлтәгә барсалар да, бу изгеләр өстендән узып киткәндә кайберләре кычкырып, кайберләре эчдән генә Коръән укып узалар икән.

*Д* – Ташбилге кешеләре шәһре Болгарга, Бүләргә зиярәткә йөрергә изге эш дип карыйлар. Алар каршында шәһре Болгар, Сувар, Бүләр бөтенләй үзләренең борынгы изге бабаларының шәһәрләре. Аларның риваятьләренә караганда шәһре Болгарны әүвәле Аксак Тимер харап иткән, андан соң әле Болгар мәмләкәте тагы яшәгән, иң соңында шәһре Болгарны, Бүләрне, Суварны вә башка бөтен Болгар илен урыслар талап, шәһәр вә авылларын яндырып, малларын талап, халкының ирләрен үтереп, хатын вә балаларын тоткын иткәнләр. Менә шундан соң инде шәһре Болгар да, Сувар да, Бүләр дә яңадан рәтләнә алмаслык булып җимерелгәнләр. Болгар иле урысларның һөҗүме белән һәлак ителгән.

---

[1] Дөресе: яхшылар.

[2] Тәхкыйрь итү – хурлау.

*Р* – шәһре Болгарда мондан йөз сиксән еллар алда байтак гыймарәтләр[1] исән булган һәм кабер ташлары урман шикелле булып тезелеп, бик зур мәйданны алып тутырып тора булганлар. Шулай ук шәһре Болгарның хәрабәсенең Иделгә таба ягында, берничә дүрткул[2] дисәтинә зурлыгындагы мәйданга таратылган бик күп кеше сөякләре булган. Менә бу гыймарәтләрнең барысы да Болгар хәрабәсенә килеп, авыл булып утырган урыслар үзләренең йорт кирәк-яракларына ташып, үзләрендән артканларын күрше авыллардагы урыс авылларының мужикларына сатып, харап итеп бетергәнләр. Кабер ташларын да чиркәү нигезләренә, чиркәү баскычларына һәм үзләренең йортдагы хуҗалык кирәк- яракларына тотар өчен урынларындан кубарылып алып, кисеп, хәраб итеп бетерелгәнләр. Шәһре Болгарның хәрабәсендәге адәм сөякләрен, сөяк заводына ташып, аларны яндырып, нәрсәдер эшләгәнләр.

*З* – Ташбилге халкы Казанны урыслар Вятка ягындан килеп алганлар дип сөйлиләр. Казан турындагы мәгълүматлары шәһре Болгар турындагы мәгълүматларындан азрак күренә. Алар шәһре Болгар, Бүләр, Сувар шәһәрләре турында бик күп нәрсәне беләләр дә, ул турыда сөйләргә дә бик яраталар. Казан турында бары урыслар Казанны алгач, шәһәрне җимергәнләр, мәсҗедләрен ватканлар, халкын үтереп бетергәнләр, авыл халкын көчләп чукындырганлар. Керәшен дип йөртелә торган татарлар әнә шушы Казан алынган чакларда, диндән көчләп чыгарылган безнең мөселман кардәшләребез дип сөйлиләр[3].

*С* – Ташбилге халкы үзләренең борынгы бабаларының шан вә шәрәфләрен, көч вә куәтләрен, дошманга һәрвакытда өстен булып, дан тотып яшәгәнлекләрен бик яхшы хәтерлиләр.

*Ш* – Ташбилге халкы үзләрендә элек-элекдән укымышлы кешеләр күп булып килгәнлеген, анда мәктәп, мәдрәсә бик иске замандан бирле дәвам итеп килгәнлеген сөйлиләр. Минем белән мосахабәдә булган Ташбилге кешеләре тагын бер кызык нәрсә турысында сөйләделәр. Алар әйтәләр: «Ташбилгенең Изгеләр өсте басуында, авылдан ерак түгел Урта Киләк дип йөртелә торган

[1] Гыймарәтләр – биналар.

[2] Дүрткул – дурткел – дүрт почмак шәкелендә.

[3] Казан шәһәре, Кабан күле, Кабан бәк турында сөйләнгән хикәяләрне, мин Талиб бабай белән Маһи әбидән ишетеп язып алып, инде басдырып таратканга күрә, бу урында халыкдан ишетелгән ул турдагы хикәяләрне монда язуны артык дип белеп, язмадым. (С. Вахиди искәрмәсе)

җирдә, таш бер урыннан чишмә чыгып, Актачы суына (шәрыкка карап) таба иң әгъла[1], көмеш шикелле саф сулы бер елга ага булган. Бу чишмәне башда Мөслим баба килеп табып, башлап шуннан беренче тапкыр ул чишмәдән суны ул эчкән, ул шуннан тәһарәт алган, – ди. – Әнә шушы чишмәнең суы, шәһре Болгарны урыс харап иткәч беткән, – ди. – Әмма Мөслим баба заманыннан калган көмеш чүмеч (дустаган), көмеш чиләк, әле дә шул урында кумелеп ята, – ди. – Ахырзаман җиткәч бу нәрсәләрнең барысы да дөньяга чыгачаклар икән», – ди. Бу әкиятне моннан егерме биш еллар мөкаддәм вафат иткән туксан яшьлек Мифтахетдин исемле мөәзин озын итеп сөйли булган. Хәзер инде халык: «аныңча без сөйли белмибез, кыскасын гына сөйлибез», – дип, әнә, югарыда язылганча гына сөйләделәр.

*Г* – Ташбилге халкы, шәһре Болгарга, Бүләргә зиярәткә баруны, безнең мондагы кеше өчен Хаҗга бару шикелле олы эш дип карыйлар, мондый зиярәтләрне шәһре Болгар заманында, ханлар заманында ук калган, ташламыйча алып баруы бик тиеш булган изге гадәттән хисап кылалар.

**Ташбилгедә табылып килгән иске әсәрләр**

Ташбилгенең «Атау» дип йөртелә торган өлешендә борын борыннан бәрәнге бакчаларын сукалаганда, искедән калган акчалар, зәркәнләр, төймәләр, беләзек вә йөзекләр, иске йозаклар, сука тимерләре, иске ураклар табылып килгән. Ташбилгенең шималь ягында, чуаш урамының бәрәнге бакчаларының артыннан, моннан унсигез еллар алда чүлмәк эчендә татарча язулы берничә йөз санда акчалар табылган. Бу акчаларның берничә данәсен Ташбилге Сафа хәзрәтнең кияве Шәһәр Шәрәфкә дә, мәзкүр авылга кунаклы кайткан чагында, биргән булганлар. Ш. Шәрәф кулындагылары югалган, табучы – авыл кешесе кулындагылары төрле кешеләр кулына бирелеп, таралып беткән.

Дөнья сугышы алдыннан авыл кешеләренә ярдәм итеп, хөкүмәт тарафыннан бирелгән акча белән күлләр казыту, тауларны төзүтү шикелле эшләр эшләтелгәндә, Ташбилгедә Урыс Күле дип йөртелә торган күлне тирәнәйтер өчен казылганда, шуннан зур гына бер бакыр казан табылган. Ул казанны Сибгатулла Гыйззәтулла улы дигән кеше Казанга китереп, иске әйберләр белән

---

[1] Әгъла – бик яхшы.

сату итүче Исмәгыйль Габдерәшитовка саткан. Болардан башка Ташбилгенең урамларында Изгеләр өсте басуы дип йөртелә торган кырның, Озын алан тавының гарби җәнүбигә таба сузайган тау битләрендә, гомумән, Озын алан чокырындан авылга таба булган берничә дүрткел дисәтинә зурлыгында булган мәйданда бик күп чүлмәк ташлары, элгәре тәнкәләр вә башка шундый иске әсәрләр, элеке-элекдән табылып килгән. Ташбилге халкы бу Ташбилге авылын, шәһре Болгар заманында кечерәк бер шәһәр булган, Озын алан авылының төрле якларында таралыб ята торган чүлмәк ташлары – әнә шул шәһәр чагындан калган дип уйлыйлар. Гүяки ул тирәләрдә элгәрерәк заманларда чирәм булып, анда өй урынлары да әле билгеле булган икән. Инде ул урынлар сукаланып, ашлык басуы ителгәч, андый нигез урыны билгеләре күмелеп беткән диләр. Мондан башка Ташбилге авылының Тау ягы басуы дип йөртелә торган кырның Китәнче авылы чигенә таба бер урынында, ниндидер агачдан ясалган бер машның[1] булганлыгын, бу машны урыс патшаларындан берсе сугыш булган тәкъдирдә дошман гаскәрен күзәтеп торыр өчен эшләтгәнлеген, ахырында бу маш үз-үзендән череп ауганлыгын сөйлиләр. Хәзерендә дә бу машның исеме халык телендә: фәләннең тае маш янында, фәләннең сыеры маш тирәсендә, минем [...] богдаем маш янында иде дип сөйләнә.

## II. Иске Баллы Күл авылында

Иске Баллы күл авылына килеп керү белән миңа озын гына буйлы, таза гәүдәле, чәч-сакалы агара башлаган, сөлек сатып йөрүче бер карт бабай очрады. Бу бабайдан мин Самад мулланың йортын сорадым. Ул миңа Самад мулланың йортын күрсәтеп, үзе дә шул якка таба килгәнгә күрә, минем белән Самад мулланың йортына бергәләп килде, Самад мулланың капкасын ачып кертде һәм Самад муллага: «Кунак килде», – дип хәбәр итде. Самад мулла белән күрешкәч мин әлеге мөселман агайдан: «Сез ничә яшьдә?», – дип сорадым. Ул: «Җитмеш алтыда», – диде. Шундан соң мин, үземнең тарихи тикшеренү, тарихи мәгълүматларны җыю уе белән йөргәнлегемне сөйләдем дә, сораша башладым. Мин аның, үзенең, атасының исемен сорашып яздым. Ул кеше Әхмәдсафа Гомәр улы икән, авылдан авылга сөлек сатып йөри торган бер кеше. Үзе Салман

[1] Маш – каланча.

авылыныкы икән. Ул миңа түбәндәге сүзләрне сөйләде: «Мин сезгә үземнең Иске Салман авылы турында бераз сөйлим», – диде. «Ярый-ярый белгәнеңне, абзый кеше, сөйлә», – дидем. «Менә безнең Иске Салман авылында Сөләйман Хуҗа булган. Сөләйман Хуҗа сәхабәләр заманасында Мәккәи Мөкарәмәдән шәһре Болгарга килеп, шәһре Болгар ханы аны бу тирәдәге мөслеманларга мөдәррис итеп, дин, шәригать хөкемләрен өйрәтеп, мулла-мөәзинләр укытып чыгара торган зур мәдрәсәгә йибәргән. Сөләйман Хуҗа бик галим булган. Ул әллә ничә төрле телләрне белгән. Анардан бик күп муллалар укып чыгып, төрле якка таралганлар. Аны шәһре Болгар ханы да яраткан. Аны халык да бик олылаган. Ул үзе дә бу якны яратып, кире Мәккәгә китмәгән, монда калган. Ул әйтә икән: «Шәһре Болгар җире бик бәрәкатьле җир, ул җиргә ислам дине кылыч куәте белән кермәгән, мондагы халык ислам динен үзләре теләп кабул иткәнләр, шуның өчен җомга намазында хотбәләр таяк тотып кына укыла», – дип сөйли икән. – Шуның өчен мин бу җирне дә, халкын да яратам», – дип, сөйли дип, мин кечкенә вакытда картлар сөйлиләр иде. Инде ул картлар, андый борынгы хәлләрне белүче карчыклар үлеп бетделәр. Без аларга караганда бик надан, менә шушы алардан ишетелгән сүзләрне генә сөйлим, мин гыйлем кеше түгел, мин укый-яза белмим, гыйлем булсам, бәлки тагы да күпне белер идем, – ди. – Сөләйман Хуҗаның кабере Иске Салманда диләр. Аның элгәре заманда кабер ташы да булган дип, туксан яшьлек безнең бер әби сөйли иде. Ул карчык бик яхшы карчык, ялган сөйләми, биш вакыт намазын бер дә калдырмый, нәфел рузалары тота иде. Менә шул сөйли иде, мин үзем ул кабер ташын күрмәдем, без белгәндә инде ул юк иде», – ди бабай.

Мин: «Шәһре Болгар турында нәрсә беләсең?», – дидем. Әхмәдсафа абзый: «Мин ни беләм, мин бит надан кеше, аны белсә, белер муллар», – ди. Мин: «Менә шул наданлар авызыннан чыккан кара тарихны белер өчен йөрим, син үзеңнең картлардан, карчыклардан ишеткәнеңне сөйлә әле, гыйлем кешеләрнең китапка язганын без аны һәрурында үзләре үлгәч дә укыйбыз. Әмма синең кебек надан кешеләрнең сүзләрен исән вакытында ишетә алсак да, үлгәч укый алмыйбыз, инде безгә сезнең кебек картларның белгәнләрен ишетеп, язып алыр калырга кирәк. Әнә теге, сез кечкенә вакытда туксан ничә яшендә булган әбидән ишетеп язып калучы булса, бүген инде яхшы булыр иде», – дидем. «Кайда алар, – ди Сафа абзый, – алар сөйләгәннең без йөздән берен дә белмибез.

Менә ул әби сөйли торган иде, шәһре Болгарда бер бик гыйлем остабикә абыстай булган икән, аның исеме Туйбикә булган. Туйбикә абыстайның шәһре Болгарда зур кызлар мәдрәсәсе булган. Анда төрле якдан бик күп кызлар җыелып, зур гыйлем бирелгәнче укый торган булганлар. Туйбикә дип ул абыстайны шуның өчен атаганлар икән, – ди Әхмәдсафа абзый, – ул абыстай туйларда була торган үпкә-сапкаларны бетерә, егет белән кыз арасын килешдерү, һәркемне үгет нәсихәт белән димләп дуслаштыра икән. Бездә бит, туй үпкәсез булмый диләр. Туйларның сүтелеп китеп, кыз белән егетнең арасы бозылып, хатын-кыз өчен төрле гайбәт, күңелсезлек чыгулар да була, әле хәзердә дә, борын заманда да, күрәсең, шундый хәлләр булган. Мен бу Туйбикә абыстай шундыйларны бетергән дип сөйлиләр иде. Шәһре Болгардагы «Алтмыш алты абыстайның мәдрәсәсе» дип йөртелә торган кызлар мәдрәсәсе әнә шушы Туйбикә абыстайның мәдрәсәсе булган. Безгә шулай сөйли торганлар иде. Алтмыш алты абыстай дип шуның өчен аталган, бу абыстайлар Биләр шәһәрендән шәһре Болгарга сабак укырга йөргәнләр. Бу алтмыш алты абыстай изге хатынлар булганлар. Болар иртә намазының сөннәтен Биләрдә, фарызын шәһре Болгарда укыйлар икән. Шунысына чаклы сөйлиләр иде без яшь чаклардагы картлар. Бу алтмыш алты абыстай Биләрдән шәһре Болгарга көненә ике тапкыр баралар икән. Бу алтмыш алты абыстайларны сәхабәләрнең шәкертләре булган, ди торганлар иде. Бу абыстайларның кулларында тимер таяклары булган, әйтә торганлар иде, Биләрдән шәһре Болгарга сабак укып йөри-йөри таяклары ашалып, кыскарып беткән икән дип. Шул чаклысына кадәр әйтәләр иде, бу алтмыш алты абыстай Биләрдән чыгып Янбактыга киләләр икән, андан Ширбәтлегә, андан шәһре Болгарга бара булганлар. Янбакты ул заманда кечерәк кенә бер шәһәр булган, ди торганлар иде».

Әхмәдсафа абзый андан соң түбәндәге мәгълүматларны сөйли: «Шәһре Болгарда бит әледә зур мәчетнең – ханлар мәчетенең дүрт нукшы (почмагы) бусагасы, тәрәзә урынлары бар. Көтепханәсе дә бар икән. Шәһре Болгарда анда көтепханәләр дә, мәчетләр дә, мәдрәсәләр дә күп булганлар. Ул дөньяның иң зур шәһәре булган, анда дөньяның бөтен ягындан байлар сату эше белән килгәнләр. Андан соң шәһре Болгарны урыслар харап иткәнләр. Алай да, күп заманга чаклы, утыз-кырык йорт сәламәт торганлыгы, без малай чагында Габдесаттар Габдулгафур угълы (без аны Әбсаттар бабай дип йөртә идек) ул инде бик карт кеше. Туксандан узган кеше иде

бугай. Шул сөйли торган иде. Ул йортларны инде урыслар ташып алып бетергәнләр. Хәзерендә инде: бер манара, бер мәчет нигезе, тагы Кара пулат дип йөртелә торган калын манара, Җеназа манарасы. Шулар гына сәламәт. Зур манара мондан байтак еллар алда җимерелгән. Ул җимерелгәндә зил-зилә кебек җир селкенү булган, бик еракка ишетелгән. Ул ауганда һичбер нәрсәгә зарар тидермәгән. Аның ташын алган урысларның кайсының кулы сынып, череп, кайсының яңагы шешеп череп үлгән. Кайсын бөкре игән. Изге манараның ташын алу да ярамаган, шуңар күрә шулай булган инде ул.

Хәзерге көндә сәламәт Җеназа манарасы. Аның янында өч сәхабәнең кабере бар. Боларның уртасында кыз сәхабәнең дә кабере бар. Шунда җеназаханәсе дә борын заманда булган. Шунда бер кое да булган. Бу коены мәнгелек коесы дип йөртә булганлар. Шул урындан ерак түгел өч тау бар. Бу тау өч шәкерт тупракка әйләнгәндән соң хасил булган таулар икән.

Мондан берничә еллар алда, инде аңар кырык еллар булыр шул, мин ишеткән идем, шәһре Болгар урынына килеп утырган урыс авылының бер мужигы подвал казыганда җир астындан зур кургашын савыт тапкан икән. Ул савытның авырлыгы гына унбиш пот чамасы булган диләр. Шул савыт эчендә бик күп мөселманча язулы печатьләр, мөслеманча язулы китаплар булган. Ул урыс: «Мөселманлар моны белсәләр, яңадан бу җиргә килеп утырырга теләрләр», дип, ул әйберләрне күрсәтмәгән, язуларын яккан, яндырган, диләр. Менә без шуларны ишетеп беләбез инде». Шундан соң Әхмәдсафа абзый болай сөйли: «Менә монда Морзалар Салманы дип йөртәләр, бер мөселман авылы бар. Ул Морзалар Салманы Иске Салмандан аерылыб чыккан», – ди. – Иске Салмандан аерылыб чыкканда болар: өч агай-эне булганлар. Ул Морзалар Салманы шундан соң авыл булып киткән», – ди. Мондан соң ул, шәһре Болгарга Себер, Әстерхан, Кавказ якларындан мөселманларның зиярәткә килгәнлекләрен, безнең каршыбызда шәһре Болгарны, Биләрне зиярәт, Хаҗга бару шикелле зур эш булганлыгын сөйли..

«Сез үзегез шәһре Болгарга, Биләргә зиярәткә барасызмы?», дигән сөальгә, Әхмәдсафа абзый болай җавап бирә: «Шәһре Болгарга, Биләргә сугышдан алда халык бик бара иде. Ул чагында халыкда дәүләт дә бар иде. Тынычлык да зур иде. Һәрбер авылдан кырыгар-иллешәр олау булып, сарык-тәкәләр алып барып, анда нәзер корбанлары чалалар иде. Анда итен фәкыйрьләргә ашаталар, яки шул авылның мулласы барса, аңар бирәләр, зур бәйрәм үткәзгән кебек

хозур була торган иде. Хатыны-кызы, бар да бара иде. Инде тормышлар да кысылып китде, мал-туар да азайды, халык артык [...] да китде. Беләсең бит, әле сугыш, әле ачлык, әле икмәкне алу белән бик харап итәләр, эшләр бик начар бит, энем. Бәлки шәһәрдә алай түгелдер. Безнең монда хәерчесен дә талыйлар бит», – ди.

«Соң ни өчен шәһре Болгарга халык болай йөри булган икән, син, бабай, аның сәбәбе нәрсә икәнен элгәре замандагы әбибабайлардан ишеткәнең юк идеме?», – дидем. Әхмәдсафа абзый миңа: «Мин бу турыда инде күп нәрсә белмим, шулай да, безнең әтиемезнең бер бик укымышлы тутасы бар иде, ул гел гыйбадәт өстендә генә утыра иде. Ул сөйләгәне хәтеремдә, ул әйтә торган иде: шәһре Болгарда иң әүвәле ислам динен кабул иткән ханымыз шулай кушкан, шәһре Болгарга зиярәткә бару шундан калган», – дип җавап бирде.

Безнең Әхмәдсафа абзый белән мосахабә шуның белән тәмам булды. Мин Самад мулланың ишегалдында агач бүкәнгә утырып, Әхмәдсафа Гомәр угълыннан югарыдагы тел мәгълүматларын, халыкча әйткәндә кара тарихны, анардан ишеткәнемчә яза бардым. Шундан соң Самад мулла мине өенә чакырып, чәй эчәргә алып керде. Ул мине Әхмәдсафа абзый белән булган мосахабә вакытында да: «Өйгә кереңез», – дип бик чакырган иде. Мин: «Монда да яхшы багча һавасы», – дип кермәгән идем.

Самад мулланың өенә кергәч, мин анардан сөальләр белән тикшеренергә башладым, ләкин ул үзендән артык яңа бер мәгълүмат миңа бирә алмады.

Андан соң, авылындагы кара тәварихка[1] оста картлардан берничә кешесен өенә чакыртуын үтендем. Минем сүземне кабул итеп, ул үзенең мәхәлләсенең Хәбибрахман Хөснетдин улы дигән бер бабайны чакыртып китерде. Аңар әүвәле мине тәгъриф итде[2]. «Бу кешедән бер дә курыкма, Хәбибрахман агай, бу бик ышанычлы кеше, белгәнеңне бер дә яшермә», – дип, бабайга минем турыда яхшы мәгълүмат бирде. Әүвәле мин: «Бабай, син Иске Баллы Күл авылы турында белгәнеңне сөйлә әле», – дидем. Хәбибрахман бабай шулай сөйли башлады: «Безнең Иске Баллы Күл авылы урынында әүвәле шәһре Болгарның бер авылы, яки кечкенә бер шәһәре булган дип, бездән алдагы картлар сөйли тор-

---

[1] Тәварихка – тарихларга.

[2] Тәгъриф итде – таныштырды.

ганлар иде. Әнә авыл янындагы иске кабер ташлары шундан калган. Бу ташларның астында безнең ерак бабаларыбызның сөякләре ята дип, картлар сөйли торганлар иде. Бу Баллы Күлдә хан булган, аның торган шәһәре менә безнең Иске Баллы Күл авылында булган дип әйтәләр иде. Әнә шушы Болгардан килгән нәселгә, Тәтеш өязе Күккүз авылындан күчеп килеп, тагы берничә нәсел утырганлар. Шундан соң теге, шәһре Болгар заманындан калган нәсел белән Тәтеш өязендән килгән нәселләр катышып, хәзерге Иске Баллы Күл авылы хасил булган. Менә безнең авылыбызның хәзерге кешеләре – борынгы Болгар нәселе белән Тәтеш өязендән килеп утырган бабайлардан үрчегән халыклар инде», – диде. Мин: «Ни өчен Тәтеш өязендән күчеп килеп утырганлар, шуның сәбәбен сөйләмиләр идеме?», – дидем. Хәбибрахман баба җавабында әйтә: «Беләсез бит, – ди, – элгәре урыс патшалары мөселманларны дингә бик каты кысканлар, авылы-авылы белән көчләп чукындарганлар. Чукынмаган мөселманларны авылларындан сөреп, икенче җирләргә таратканлар. Шулай итеп, бик күп мөселман авыллары әрәм булып беткәнләр. Менә монда авыр заманлар, безнең әби бабайлар өчен карангы вә кайгы чоры булып, озак еллар шулай дәвам иткәнләр. Менә шундый дингә кыстау чакларында безнең бабайлар Тәтеш өязендән күчеп килеп, Ыспас өязенең кап-кара куе урман белән чорналган бер почмагына, шәһре Болгар заманасындан бирле дине исламны тотып килә торган бер авылга, әлеге Баллы Күл авылына килеп утырганлар. Бабайларның сөйләвенә караганда, безнең Баллы Күл авылы тирәсендәме, яки шуның үзендәме шәһре Болгар ханлыгына буйсынган Гәрәй ханның шәһәре булган диләр[1]. Безнең авылдагы иске кабер ташлары – әнә шул Болгар нәселендән килгән Баллы Күлдәге иске нәселнең бабалары булган дип сөйләшәләр. Безнең бабайлар күчеп килгәндә әле, бу шәһри Болгар заманасындан бирле килә торган Баллы Күл авылының мөселманлары, әле урысның

[1] Янбакты авылының туксан ике яшьлек Гали мулланың сөйләвенә караганда Гәрәй хан Иске Баллы Күлдән өч чакрым шәрыкда, хәзердә тирән чокыр һәм ор белән әйләндереп алган һәм хәзердә дә бик күп алма агачлары сәләмәт булып тора-торган шәһәр хәрабәсе, Болгар ханына табигъ (буйсынучы) Гәрәй ханның шәһәре булган икән. Бу турыда Янбакты авылындагы мосахабәдә мәгълүмат бар, шунда каралсын (С. Вахиди искәрмәсе).

законларына бөтеннәй[1] баш имиләр, солдат бирмиләр, үзләре шәригать буенча хөкем итеп яшиләр икән, дип картлар сөйләшә торганлар иде. Тәтеш өязендән килгән соңгы нәселнең кайбер бабалары болай сөйли торганлар иде. Ул бабаларның берсе, Бәйкә баба, икенчесе Боерган баба, өченчесен инде мин хәтерләмим. Шуларны сөйләшә торганлар иде. Хәбибрахман бабаның әйтүенә караганда, Баллы Күл авылының ике төрле дәвере бу көнгә кадәр кара тарихка мәгълүм: 1 нче дәвере Тәтеш өязендән соңгы нәсел халык күчеп килгәнгә чаклы булган, шәһре Болгардан аерылыб чыкган борынгы авыл булып яшәгән дәвер, ул дәвер, кара тарихка караганда, рус законларына буйсынмаган, патшалар хөкүмәтенә солдат бирми торган, элеке-элекедән бирле үзләренең каршында мәкъбүл булып[2] варәсәт тарикы[3] белән күчеп килгән шәригать хөкеме белән яши торган дәвер. Икенче дәвер, руслар Казан ханлыгын бетереп, бу тирәләрдәге татарлар арасына православие җиһангирлеген үткәзү юлында, татар авылларын таратып, ул авыл урынына урыс утырту, татарларны чукындыру, татарлар өстенә эшләнгән патшалар Русиясенең каты җәбер вә золым сәясәтен бөтен мәгънәсе белән иҗраэ иткән[4] карангылык дәвере. Менә шул дәвердә, икенче нәсел буларак, Баллы Күлгә Тәтеш өязендән татарлар күчеп килеп утыралар. Баллы Күлдә минем белән мосахабәдә булган бабалар, гомумән ул авылда мин күргән кешеләр, ире һәм хатыны озын буйлы, мәһабәт кыяфәтле, үткен кара күзле, төреклек канын, төреклекнең җисмани җәһәтдән булган бик күп хосусиятләрен саклап килгән кешеләр иде. Әгәр боларга яхшы мәктәп тәрбиясе бирелгән булса, боларның эчендән уйламаган эшлекле адәмләр чыккан булыр иде дигән фикер килдем.

Бу авылның Баллы Күл дип аталуы турында минем белән мосахабәдә булынган картлар түбәндәге мәгълүматны сөйләделәр. Алар әйтәләр, иске заманнарда бу урын кап-кара калын урман имәнлек икән. Имән агачлары әнә авылыбызның эчендәге күлгә егылып үсәләр икән. Ул заманда калын имәнләрдә умарта кортлары ил булып бал җыялар икән. Хәтта ул заманда урманга умарта

---

[1] Дөресе: бөтенләй.

[2] Мәкъбүл булып – кабул ителеп.

[3] Варәсәт тарикы – варислык юлы.

[4] Иҗраэ иткән – эшкә ашырган.

куеп умарталык асрарга да хаҗәт юк икән. Кирәк вакытда халык шул имәнләрдән генә балны алып файдалана икән.

Менә шундый умарта кортлы калын карт бер имән, каты искән бер җил белән, әлеге, безнең менә шушы күл өстенә ауган (бу күл әледә бар, Баллы Күл халкы шуның суын эчеп көн итә) имән эчендә, бик зур ил бал җыйган, төбендән очына кадәр бал белән тулган булган. Имән күлгә аугач, аның эчендәге бал агып, күлгә чыккан. Халык шул суны эчкәндән соң, бу күл Баллы Күл икән дигәнләр болар. Шуның соңында бу авылны Баллы Күл дип атаганлар. Болар, бу авылдан берничә йорт аерылып чыгып, Яңа Баллы Күл авылын нигезләгәч, бу авылны Иске Баллы Күл дип атаганлар», – ди.

Шундан соң мин Яңа Баллы Күлгә якын шәһәр хәрабәсе хакында сөйләшдем. Иске Баллы Күл кешеләре ул турыда миңа түбәндәге мәгълүматны бирделәр: «Яңа Баллы Күл янындагы кала өсте (шәһәр хәрабәсе) ул Нократ исемле урыс авылының басуында, мондан унбиш еллар алда әле ул кала урыны чирәм булып торадыр иде. Анда тәртип белән утыртылган бик күп алма агачлары бар иде. Бу алмагачлар – эче алмагачлар түгел, баг алмагачларындан татлы булган алмагачлар иде. Бу каланы шәһре Болгар заманында бер ханның крепосте булган дип сөйлиләр, хан үзе дә шушы шәһәрдә торган, аның шәһәрендән Янбактыга юл булган диләр. Ул урындан мөселманча язулы әзгәрәй тәнкәләр[1] табыла иде, анда чүлмәк ташлары да бик күп. Соңгы вакытда инде Нократ урыслары бу кала өстен сукалап, җир итделәр, алмагачларын кискәләделәр. Кайсы берләре үзләре корыды. 1912 нче елда хөкүмәт акчасы белән күлләр казылганда бу каланың чокыры күмдерелде, аның чокырын күмгәндә байтак иске әйберләр тапканлар иде. Инде алар кайдадыр, белгән кеше юк, бәлки Нократ урысларында әле дә бардыр», – диделәр. Бу кала урыны Иске Баллы Күлдән өч чакрым ераклыкда булган[2].

---

[1] Әзгәрәй тәнкәләр – вак тәңкәләр.

[2] Иске Баллы Күлдә Габдессамад хәзрәт (Самад дип кенә язылды) Габдеррахман угълы Габдеррәхими. Габдеррәхим баба Янбакты авылының бер мужикның угълы булып үзе вафат булгач аның хатыны Габдеррахманны Казанга Кәрим хәзрәт мәдрәсәсенә йибәреп укыткан. Габдеррахман Кәрим хәзрәтдә гыйльме тәхсил кылгандан соң, Янбактыга кайтып мулла булган. Аның угълы Габдессамад Иске Баллы Күлдә бу көндә имам. Бу кеше заманасында [...] торганлыгын сөйли. Инде шактый таушалган, картайган. (С. Вахиди искәрмәсе)

Иске Баллы Күл авылында мин Самад мулланың хосусый көтепханәсендәге кульъязмаларны тәфтиш итдем[1]: бу авылдан берничә кульъязмалар таптым. Алар турында мәгълүмат Ыспас кантонына булган йөреш хатирәләренең ахырында булыр.

Июньнең унөчендә, көндезге сәгать беренче яртыда Иске Баллы Күл авылындан Янбакты авылына чыгып китдем.

## Янбакты авылына барганда

Янбакты авылына барганда, Урта Салман аркылы чыгып барырга туры килә. Урта Салманның бер өлеше урыс, бер өлеше мөслеман. Янбактыга барганда (бу олы юл Ыспаска да бара) Урта Салманның урыс кыйсемен үтеп чыгыла. Урыс урамы буйлап барганда, ызбасының алдына чыгып утырган бер карт урысны күреп, мин аңар башымдагы шапканы алып: «Бабай, исәнме», – дидем. Ул да башындагы тубал кебек бүреген алып, миңа: «Исәнме», – диде. Бу урысдан мин: «Бабай, син ничә яшьтә?», – дидем. «Батушка инде, яшем бар, восьмой десяток[2]», – диде. Карт урыс ватылган булса да, аның башы таза, хәтере яхшыга ошый, исемен сорагач ул миңа: « Минем исемем Иван», – диде. Мин: «Дәдушка, сез ник болай бик таркау булып утыргансыз?», – дидем. Ул: «Без борында алпавытның коллары булганбыз, безне алпавыт шулай утырырга кушкан, ул заманда алпавыт ни нәрсә теләсә, шул булган бит», – диде. «Шул сез монда ничек татарлар белән катнаш утыргансыз», – дидем. Бабай: «Әүвәле монда татарлар гына булган диләр, ничекдер безнең барин бу урынга килеп утырганда, крестьянларын да шунда күчергән», – диде. «Бабай син бу тирәдә шәһәр хәрабәләре белмисеңме, – дидем, ул – әнә, безнең авылдан алты чакрым чамасы, Яңа Баллы Күл дигән татар авылы янында бер шәһәр урыны бар. Шуны беләм», – диде. «Анда соң кемләр торган икән? Ул нинди шәһәр урыны булды икән», – дигәч. «Әйтәләр, анда татар ханы торган, әле аның бакчалары да исән булган. Күптән түгел генә, әле мин андан үзганда бик күп алма агачлары күргән идем, ул алма агачларын татар ханының бакчасында үскән алма агачлары дип сөйлиләр. Ул җир чирәм иде, әле соңгы елларда инде аны Нократ мужиклары сукаладылар, ул басу булды. Урыслар бит бу җиргә Казан халкын Иван Васильевич Грозный алгач кына килгәнләр, – диде. – Борын

[1] Тәфтиш итдем – тикшердем.

[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.

монда татарлар гына булган, урыслар булмаган», – диде Бабай Иван. Мин шундан соң Янбакты авылына таба китдем. Июнь аеның 13 ендә, көндез сәгать 3 тә Янбакты авылына килеп җитдем.

## Янбакты авылында

Янбакты авылында мин Хафиз Галиев йортына туктадым. Янбакты авылының тарихи яклары турында мондан берничә вакытлар алда минем анкетама җавап итеп, Хафиз Галиев байтак нәрсәләр язганга күрә, миңа ул язганларны үзем тикшереп чыгарга тиеш иде.

Янбактыда тикшерү планы түбәндә язылган тәртип белән булды.

1 – Кара тарихка оста булган зур яшьле картлар белән мосахабәләр ясау;

2 – каберстанларны вә андагы кабер ташларын тикшерү;

3 – кулъязмаларны тикшерү.

Янбакты авылы өч мәхәлләле зур гына бер мөселман авылы. Янбакты авылы чокыр урынга утырган, аларның эчә торган сулары күл суы гына, анда елга акмый, елга сулары кибеп, комлык, коры чокыр булып калган. Аларның кәсебләре игенчелек һәм юлчыларга чәй эчерү (олы юл өсте фатир йибәрәләр). Янбакты авылында өйләр икешәр катлы, тимер түбәле. Карап торырга бай гына авыл. Ләкин авылда җүнле мәктәп юк. Халык фикри якдан яхшы ук түбән торганга ошый. Әлгәре заманларда кадим мәдрәсәләрендә укып килгән агайлар байтак булган. Бу авылда мужик кулында да байтак кулъязмалар күрергә туры килде.

Янбактыда мосахабә өчен шул авылның имамы Гали мулладан башка мәгъкуль[1] кеше табылмады.

## Гали мулла белән мосахабә

Гали мулла Янбакты авылында туган, нәсел-нәселдән Янбакты кешесе, үзе инде туксан ике яшендә, әле сәламәт, зиһене саф, башы бик яхшы эшли, аның хатирәсе дә яхшы, кара тарихны ата-бабалардан күп ишетеп калган бер карт кеше. Тик аның күзләре генә зәгыйфь.

Гали мулла сөйли: «Безнең Янбакты авылы шәһри Болгардан килеп утырган Янбакты бабайның нәселендән үрчегән бер авыл. Бабайларның сөйләүләренә караганда, Янбакты бабайдан бирле

---

[1] Мәгъкуль – лаек.

килә торган безнең шәҗәрәбездә булырга тиеш иде. Ул һәм булган, фәкать, аны кемгәдер биргәнләр. Бәлки, чынлап тикшерсәң, әле аның икенче бер нөсхәсе авылында да табылыр. Җәй белән карарбыз, табылса, соңында аны да сезгә йибәрербез, – ди. Гали мулла сүзендә дәвам итеп сөйли, – безнең Янбакты баба сау заманда Болгардан, Биләрдән аңар зиярәтән[1] галим кешеләр, шәйхләр килә булганлар». Ул заманда әбиләрдән Янбактыга, Янбактыдан Ширбәтлегә, андан Болгарга йөри торган юл булганын сөйли. Янбакты авылындан Баллы Күл Гәрәй Хан шәһәренең, андан Ташбилге авылына урман эчендән, дошманларга мәгълүм булмаган яшерен юл булган. Болгар иленә җау чабу куркынычы булганда, әнә шушы урман эчендәге яшерен юлдан йөреп, шәһри Болгарга, Биләргә хәбәр итә булганлар. Бу юл тар, бары атка атланып кына, яки җәяү генә йөрерлек булган. Кайсы чакларда шәһре Болгардан Мөслим бабага зиярәткә килеп, андан Гәрәй Хан шәһәренә (Баллы Күлгә) андан Янбактыга андан Бүләргә йөри булганлар.

Безнең авылыбызның җәнүб ягындагы Ташбилге газизләре өсте дип, йөртелә торган каберстанда күмелгән Гәлләмәи Дивани, шәйх Хөсрәви дигән олугъ затлар шәһри Болгардан чыгып, Биләргә барышлый Янбакты баба янына зиярәткә дип кереп, Ходаның тәкъдире белән әҗәл ирешеп, шунда вафат итеп калган газизләр дип сөйли торганлар иде. Миңа Гәрәй хан шәйх Хөсрәви, Гәлләмәи Диванинең мин сөйләгән кыскача тарихларын миңа Равил хәзрәт сөйләгән иде. Равил хәзрәткә инде, исән булса, бер йөз егерме биш яшь булыр иде. Равил хәзрәт Иске Баллы Күлдә имам булып, гомер итеп вафат иткән кеше[2]. Гали мулла әйтә: «Безнең Ташбилге газизләре өсте дип йөртелә торган иске каберстандагы ташлар арасындан, әнә теге Гәлләмәи Дивани белән шәйх Хөсрәвинең дә кабер ташлары бар дип сөйлиләр иде һәм аны укыйлар иде. Инде хәзер байтак ташлар урынларындан алынып, юкка чыгарылганлар. Хәзер ул каберстанда ташлар аз калган инде. Без кечкенә чакларда анда таш бик күп иде. Хәзер инде кемләрнең ташлары бардыр. Минем күзем зәгыйфьрәк булганга, андагы иске язуларны укыганым

[1] Зиярәтән – зиярәт итеп.

[2] Гали мулланың риваятенә караганда Тәтеш кантонындагы Кариле авылы – шәһре Болгардан чыкган авыл икән. Гали мулла Янбактыга мулла булганчы, шушы Кариле авылында мулла булып торган. Анда Болгар иманасындан калган кабер ташы да бар икән, ул Иске зиярәткә халык читдән килеп бик зиярәт итә булганлар, ул шулай сөйли (С. Вахиди искәрмәсе).

юк. Аны бит бик тикшереп, җентекләп укырга кирәк. Минем күзем аңар ярап бетми.

Элеке элекедән шулай андый эшләр белән маташмагач, аны бит тиз генә таныб да булмый. Әле монда, Янбакты бабай янына шәһри Болгардан зиярәткә килгәч, Гәлләмәи Дивани, шәйх Хөсрәви икәве вафат булып калганлар дип, – сөйләнде. – Болар шулай булган. Моңар дәлил дә бар. Менә безнең Янбакты халкы яңгыр булмаган заманларда, яки бәйрәм вакытларында авылдан зиярәткә чыкганда, иң алда, бик иске каберстан дип әүвәле Гәлләмәи Дивани, шәйх Хөсрәви күмелгән, Ташбилге авылына бара торган олугъ юлның сул тарафындагы Иске каберстанны зиярәт итәләр. Халык телендә Янбакты баба Гәлләмәи Дивани белән шәйх Хөсрәвидан соң вафат иткән дип йөртелә. Шуның өчен Янбакты бабага зиярәт итү соңга калдырыла, – ди. – Әле без кечкенә чакларда, – ди Гали мулла – Янбакты бабага зиярәткә килгән кешеләр, аның кабере өстенә куелган кабер ташының язуын бик җиңел укыйлар, хәтта, байтак кешеләр күчереп тә алалар иде. Инде бу елларда, хәер, мин Янбакты бабаның кабер ташының язуын караганым юк, ничекдер, менә сез үзегез аны тикшерерсез, укырсыз инде». Янбакты авылындагы кулъязмалар һәм Янбакты авылының тарихы хакында Гали мулла түбәндәге мәгълүматларны бирде. Ул әйтә: «Кулъязмалар безнең үзебездә элеке элекедән бик күп иде. Минем кече угълым Зәки мулла, муллалыгын ташлагач, аның хатыны ул кулъязмаларны анда-монда таратып, әрәм-шәрәм итеп бетерде. Хәтта калын иске язма китапларның кәгазьләрен җыртып алып, түбә-түшәмгә, өй диварларныа ябышдырган. Үземнең күзем зәгыйфь булгач, китап моталәга кылу[1] белән күп шөгыльләнә алмадым. Әнә шулай таралып бетделәр. Безнең авылыбызда гавам халкында да элеке-элекедән уку-язу белән шөгыльләнүче кешеләр булып килгән. Алар кулында да байтак язган нәрсәләр булырга тиеш иде, – ди. – Әле, – ди Гали мулла, – безнең Янбакты авылының тарихы бар иде. Ул тарих китабы Һәфтияк калынлыгында, кәгазе зәңгәр төсдә, калын, язуы да хуш хатт иде. Бу тарих китабы минем мөәззинем Шәфи агай кулында иде. Шәфи агай иске нәсел кешесе. Шәфинең атасы Шагъбан булган. Аның атасы, бабасы, барысы да шулай укымышлы кеше булып килгәнләр. Аларның ике йөз елдан артык

[1] Моталәга кылу – уку.

тарихлары мәгълүм иде. Менә шушы минем мөәззинем Шәфи агай үлгәч, аның угълы Мөбарәкша калды. Мөбарәкша Алпарда мөгаллим булып торды. Инде ул Мөбарәкша ачлык елны вафат булды. Аның тарихы кайдадыр, мин аны ачык белмим. Аның кулында ата-бабаларындан калган башка кульязма китаплар да күп иде. Ул егеткә Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» исемле китаб да калган иде, алар инде кайдадыр, мин анысын белә алмыйм», – ди[1].

Гали мулла әйтә: «Минем мөәззин Шәфи аганың кулындагы иске тарих китабында, югарыда мин сөйләгән Гәлләмәи Дивани, шәйх Хөсрәви шәһри Болгардан чыгып, Бүләр шәһәренә барышлый Янбакты баба янына зиярәткә кергәндә вафат булып, күмелеп калганлары хакында, Янбакты авылындан Гәрәй хан шәһәренә, андан Ташбилгегә урман эчендән атка атланып кына йөри торган, дошманлар белми торган яшерен юл булганлыгы, андан башка бик күп тарихи вакыйгалар анда бар иде. Әгәрдә сез аны тапсаңыз, ул тарих китабын безгә дә бер укып чыксаңыз, яхшы булыр иде, – диде. – Мин әле сүз арасында шуны да әйтеп китим, – ди Гали мулла, – мин Тәтеш кантоны, Кариле авылында биш ел мулла булып тордым. Кариле авылында, бездән күп алда, Баһадиршаһ хәзрәт булган. Баһадиршаһ хәзрәт – Казанда Закир хәзрәт дип мәгърүф булган Закир хәзрәтнең атасы була инде. Баһадиршаһ хәзрәт озак гомер итеп, туксанларга җитеп вафат булган. Менә Баһадиршаһ хәзрәтнең бик күп язган китаплары бар иде. Үзендән соң аның бөтен әйберләрен Лаеш өязенә Күгәрченгә алып китделәр дип беләм, бәлки Күгәрчен авылында Мөхәммәдҗан мулланың угълы Сөнгәтулланың балалары бардыр әле. Сөнгатулла мужик булып калган бугай. Әнә шунда кульязмалар да булса, гаҗәп түгел, шундан белешергә мөмкин», – ди.

Гали мулла сүзендә дәвам итеп әйтә: «Безнең атабыз, мәрхүм, әйтә торган иде, Янбакты кешеләре Казан ханлыгы заманында, Казанга бик аралашып йөргәнләр. Казан ханлыгы заманасында,

[1] Гали мулла белән мосахабә вакытында, мөәззин Мөбарәкшасының кулында калган кульязмаларның кайда калганлыкларын тикшергәч, беленде ки, Мөбарәкша кулындагы бөтен кульязма китаплар Китәнче авылының мулласы Вәли Мөхәммәд Тәрҗемани кулында калган икән. Мөбарәкша Алпардан Китәнчегә мөгаллим булып күчкән. Шуның өчен аның китаплары Вәли Мөхәммәд Тәрҗемани кулында калган, аның кульязмаларын Тәрҗеманидән соратып алырга кирәк (С. Вахиди искәрмәсе)

Касыйм шәйх дигән мәшһүр шәйх – Янбакты кешесе булган, Казанда әле дә халык каршында Кәсәм шәйх дип йөртелә торган мәгъруф шәйх – әнә, ул безнең Янбактыдан Казанга килгән кеше[1]. Казан шәһәрендән Янбактыга, Янбактыдан Казан шәһәренә сәүдәгәрләр барып килеп йөргәнләр, безнең бу якда кыйммәтле җәнлекләр чыккан. Мондан бик күп чикләвек чыккан. Әнә, бездән ерак түгел мөселман авылы Киекдән, ул заманда мөселман авылы булган Буҗак, Буш, Кәшәй, Ямкә (хәзерге Энҗерәнең иске урыны), Әҗмәр авылларындан Актәче суындан иске Камадан бик күп сусар, шундагы урманлардан бик күп тиен аулаганлар. Менә мондый җәнлекләр әүвәле шәһри Болгарга, андан соң Казан шәһәренә озатылып, безнең бу җирдәге халык шуның белән кәсеп итеп торган. Бу якда ул заманда җир-суга бик иркенлек булып, халык мал-туар бик күп асраган. Мондан Казанга аяклы мал да бик күп озатылган.

Әле безнең бу якларда, без кечкенә вакытларда җир-суга муллык иде. Янбакты авылының җире борын заманда, тугыз чакрым озынлыгында, җәнүби гарбигә таба озаеп сузылган булган. Янбактының кырын урыслар тартып алып, шул урынга авыл булып килеп утырганлар. Хәзерен дә Янбактының җирендә Горки исемле урыс авылы утыра, бу урыс авылын Янбухтински Горки дип йөртәләр. Әнә Пичикас дигән урыс авылы берүзе биш-алты яңа авыл аерып чыгарды, бу яңа авылларның барысы да буш җирләргә чыга бардылар. Безнең бу якда, элеке-элекдән җиргә киңлек булган. Мондан ике йөз еллар алда, әле бик күп авыллар урнашырлык урманлар, басулар бөтеннәй буш ятканлар. Әүвәле урыслар шундый буш басуларга килеп утырганлар. Андан соң чуаш халкы мөселманларны кыса-кыса, авылларындан куып, татар авылларына килеп утырганлар. Татарлар урысның җәбер-золымына чыгыш

---

[1] Балаларга кызамык чыккач – кызыл этәч, чәчәк чыккач – ак этәч, яки ак тавык Кәсәм шәйхкә дип бирәләр. Бу бирелмәсә, чәчәк анасы, кызамык анасы кала, ягъни авырган баланың бер җирендә төзәлми торган бер авыру кала икән. Биргәч, калмый була. Әгәрдә бер бала чәчәк, кызамык белән авырып та аңар этәч бирелмәсә, аның бер йирендә төзәлми җәрәхәтле авыру калса, Кәсәм шәйх нәселендән булган әбигә этәч алып баралар да, әби этәченең кирәгендән кан чыгарып бирә, шуны баланың төзәлми тора торган җиренә, ягъни чәчәк, кызамык анасына сөртәләр. Кәсәм шәйх нәселе Казанда Захарскийдан Тукай урамына борылган почмакда борылган икенче йорт, бер катлы тәбәнәк йортда, бу әби әле исән (С. Вахиди искәрмәсе).

итә алмый, авылларын ташлап качканлар. Әнә бу чак Буш, Кәшәй, Тырым (Ямкә), Актачы суы буендагы мөселман авыллары. Аларны шул урыслар көчләп, мал-туарларын талап, күбесен үзләрен үтереп, шул авылларга килеп утырганлар. Мәскәү безнең Казан ханлыгына төрле җинаять белән гаепләнгән, эшдән чыккан урысларны сөргенә җибәргән. Әнә шушы сөргенгә килгән җинаятьче-урыслар безнең мондагы мөслеманга бигрәк дә каһәр иткәнләр. Безнең әбибабайлар урыслардан сөйләп бетергесез золым-җәберләрне күргәнләр инде. Безнең бабайларның башындан сөйләп бетергесез кайгылы хәлләр кичкәнләр, урыс патшалары, урыслар безгә күрсәткәнләр эт күрмәгәнне, без урысдан күпне күргән инде». Мин Гали мулладан: «Менә мондый, урысларның җәбер-золымлары турында, язылып калган хатирәләр юкмы, бу бит булырга тиеш иде», – дидем. Гали мулла җавабында әйтә: «Патшалар заманында бит без үзебезгә килгән хатларны да, җандыра-җандыра җөдәп бетә торган идек. Әле үзең дә хәтерли булырсың, татарларның аңлыларына иске хөкүмәт ничек карыйдыр иде, нинди тентүләр, нинди куркынычлы хәлләр булып уздылар, кемләрне һичбер гаепсез сөргенгә йибәрмәделәр. Галимҗан хәзрәт Баруди вә аның ибдәшләре Архангельскига ни өчен йибәрелделәр, әнә шундый кысынкылык заманларында безнең муллалар бездән әллә ничаклы хатирәләр, кулъязмалар яндырылдылар. Менә шунда алар беткәнләр инде. Бәлки бардыр да, хәзерендә дә, чыгарырга курка торганлардыр», – ди.

Шундан соң Гали мулла, үзенең Габденнасыйр ага Исмәгыйль угълындан ишеткән түбәндәге сүзләрен сөйли, ул әйтә: «Минем атам, мәрхүм, Габденнасыйр әйтә торган иде, безнең Янбакты бабайның Алтынбикә исемле кызы булган, ул үзенең кызын Ташбилге Мөслим бабаның улына биргән. Ул заманда Янбактыдан Ташбилгегә бары коры кара урман эчендән, Гәрәй хан шәһәре аркылы сукмак кына булган. Шул сукмакдан, атка иярләп атланып йөри булганлар, ди торган иде. Ул әйтә торган иде (әле сөйли торгач, хәтеремә килде ди), шәһре Болгардан Янбактыга юл булган, Янбактыдан Көрнәле урынындагы шәһәргә барганлар, андан Бүләр шәһәренә киткәнләр. Безнең Янбакты ул заманда Мирхәлә – станция булган, ди. Безнең Янбактының җәнүбе гарәби ягында киләк[1] бар. Әле дә ул киләкнең агачлары бар, әнә шушы киләк урынында бер шәһәр хәрәбәсе булган. Шундан әйберләр табылган ул заман-

[1] Киләк – умарталык урыны.

да чүлмәк ташлары да күп икән. Безнең Янбакты халкы чәй суын, авылдан читдә, басуда Озын Күл дип йөртелә торган Күлдән алып кайталар. Бу күл бик зур күл, моның суы бер дә бозылмый, суы да татлы, яхшы су. Менә шушы Озын Күлнең янында бик күп чүлмәк ташлары табыла. Шул тирәдә, сука сукалаганда, кеше башы сөякләре чыккан. Бу урында, борын заманда, авыл булып яшәгәнләр булырга кирәк. Безнең Янбакты авылыннан элеке заманларда бик күп «орчык башы» дип йөртелә торган уртасы тишекле, түгәрәк чүлмәк ташыннан ясалган таш тәгәрмәчләр табыла булган. Бу орчык башларын халык, ул заманның «шут төймәсе» булган икән дип сөйли торганлар иде», – ди Гали мулла.

Гали мулла мондан соң сүзне шәһри Болгарга, халыкның зиярәткә йөрүләре мәсьәләсенә күчеп, түбәндәге мәгълүматларны бирә, ул әйтә: «Безнең бу якдан гына түгел, шәһри Болгарга Сибириядән, Әстерхандан, Мәскәү, Питербур якларыннан, хәтта Польша мөселманларыннан анда зиярәткә бик киләләр. Безнең бу якда, заман алышканга чаклы, һәрбер авылдан утызар-кырыгар булып тәкәләр, сарыклар алып, мулла-мөәзинләрен үзләре белән утыртып, Шәһри Болгарга бара торганлар иде».

Мин Гали мулладан: «Халыкның шәһри Болгарны болай олугълауларының, анда болай күп-күп булып зиярәткә йөрүләренең сәбәбен белмисеңме?», – дип сорадым.

Ул миңа болай дип җавап бирде: «Безнең бит шәһри Болгар ханлыгы бик зур патшалыгыбыз булган. Ул заманда без бөтен дөньяга мәгълүм укымышлы халык булып, бәхетле яшәгәнбез. Шәһри Болгардагы изге бабаларыбыз безне туры юлга кертеп, ислам диненә кертеп калдырганлар. Алмас бабабыз турылыкны безгә күрсәтмәсә иде, без һаман да мәҗүсилекдә калган булыр идек. Менә шуның өчен шәһри Болгар тегеләй дә безгә мең хөрмәтле шәһәр. Шуның өстенә ислам динен Алмас бабабыз шушы шәһри Болгарда кабул иткән. Пәйгамбәр заманасында ук шәһри Болгарга сәхабәләр килгән, шәһри Болгарның тупрагында, шөбһәсез, бу көндә дә бик күп изге җанларның сөякләре ята, халык моны җаны, калебе, каны белән якын күрә. Яңадан, минем колагыма чалынган иде, – ди. – Алмас хан ислам динен кабул иткән көнне, шәһри Болгарда үзенең кул эманәтендәге ханларын җыеп, бик зур бәйрәм ясаган. Ул көнне шәһри Болгарга бөтен зур шәһәрдән: Бүләр, Сувар, Кашан, Ашлы, Җүкәтау, Кызлар шәһәрендән вә башка бик күп шәһәрләрдән, авыллардан хәдсез күп кеше шәһри Болгарга

җыелган. Багдад хәлифәсендән килгән илчеләр, алар белән бергә килгән. Бик күп галимләр ул көнне инде шәһри Болгарда булганлар. Бу зур көн, әлбәттә, халыкның күңеленә нык урнашып калган. Халык аны тиз генә оныта алмаган. Ислам кабул итү бәйрәме май аенда булган. Һәр елны бу олугъ һәм изге көнне искә төшереп, шәһри Боларда бәйрәм ителә булган. Халык, хәзер инде ачык белмәсәләр дә, менә шушы ислам динен кабул итү бәйрәмен хәтерләп, шәһри Болгарга зиярәткә баруны үзләренә изге гадәт иткәнләр икән. Минем колагыма шулай чалынган иде, моны халык шулай аңлый дип беләм» – диде.

Шундан соң Гали мулла Бизнә вакыйгасы хакында сөйли. Бизнәдә бер писарь малай патшаның приказын укып крестьянларга аңлаткач, халык инде без алпавытның коллары түгел икән, инде без азад икәнбез дип, мәшһүр Бизнә вакыйгасы кузгала. Алпавыт начар, каты күңелле, кире урыс була. Ул бик күп гөнаһсыз урыс крестьянларының канын түгәргә сәбәбче булды, – ди. Гали мулла үзенең сүзен – Әнә, безнең Янбакты авылының көньяк тарафыннан Яңа Сала исемле бер урыс авылы бар, бу авылны урыслар «Ермак» дип йөртәләр. Менә бер Яңа Сала авылы борында татар авылы булып, монда бер татар түрәсенең имениясе булган диләр, – дип, сүзен тәмам итә.

Гали мулла белән мосахабә тәмам булгач, мин Янбакты авылының Ташбилге газизләре өсте һәм Янбакты бабай өсте, дип йөртелә торган иске каберстандагы ташларны тикшердем.

*Материаллар С. Вахидинең 1928 елда Спас кантоны авылларына оештырылган экспедиция мәгълүматларын туплаган хатирә дәфтәреннән сайлап алынды. Дәфтәр Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана: 53 фонд, 1 тасв., 58 сакл. бер. Дәфтәрдәге язмалар гарәп графикасында С. Вахиди кулы белән язылган.*

*Текстны гамәлдәге язуга күчереп, басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәс сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

**Спас кантоны авылларына оештырылган 1928 елгы экспедиция материалларыннан**

Ташбилгедәге каберстанлар

Ташбилгенең җәнүб һәм җәнүби-шәркый багында беренче иске каберстанлар вә аларның кай берләрендә иске кабер ташлары әлегә кадәр сакланыб килгән. Бу каберстанлар, авыл халкының телендә – изгеләр өсте, йахшылар өсте, газизләр өсте диб йөртеләләр. Бу каберстанларга халык бик зур хөрмәт белән карый. Без бу каберстанларны вә алардагы каберстанларын түбәндә язылган тәртиб белән һәр кайсын аерыб тәфтиш итеб чыгабыз.

1 нче каберстан. Бу каберстан Ташбилгенең «атау» диб йөртелә торган өлешенең көн ягында, Акташы суы белән Кората юлының ике арасында тау битендә, дүрткел шәкелдә тирәли чокыр казылыб әйләндерелгән, тәхминән йөз сажин буе алтмыш биш сажин аркылысы булган мәйданны каблаб алган бер чирәмлекдән гыйбарәт. Бу каберстанда өй урыны зурлыгындагы, кайберләре аршын йарым тирәнлегендә булган, ләкин кабер чокырына ошамаган, байтак санда инкү урынлар бар. Кайбер кешеләрнең әйтүенә караганда, мондый инкү чокырлы урынлар элекедән калган өй урынлары булырга кирәк диб уйлана.

Бу урынларда, билгеле, раскопка-фәлән ясалганы юк. Шуның өчен ул чокырлар, ишле булыб күмелгән кешеләрнең каберләреме, яки халык әйткәнчә, өй урынымы, анысы әлегә ачык кала. Атау изгеләр өсте диб йөртелә торган бу каберстанда, безнең белән мосахабә иткән кешеләрнең әйтүенә караганда, иске заманларда кабер ташлары бик күб булган. Патшалар хөкүмәтенең урыслашдыру сәясәтенең татарлар арасына үткәрелә торган мәгълүм сәясәте буенча, Ташбилгегә урыс һәм чукынган чуашлар кертелгәч, хөкүмәт органлары һәм хөкүмәт кешеләре алдында үзләрен киң хокуклы, имтиазлы кешеләр итеб хис иткән әлеге урыс халкы, бу кабер ташларын үзләренең йорт кирәк-яракларына ташыб, бик күбесен юкга чыгарганлар. Ул кешеләрнең сөйләвенә караганда, урыслар бу кабер ташларының барысын да алыб бетерәчәкләр икән, ләкин, шул ташларны урындан кубарыб алыб китеб, өй алды бусагаларына, ваклаб-ватыб мунча мичләренә тоткан берничә урыс түзәлми торган авырулар белән мөбтәля булыб, ул авыруның шушы изгеләр өстенә хөрмәтсезлек күрсәтүдән булганлыгы татарлар тарафындан аңлатылгач, шундый мәгънәви рухани тәэсирләрнең куркынычлы хәлләргә очратуларындан куркыб кына туктаганлар була. Мәсәлән,

халык болай әйтә – Михайла исемдәге бер урыс изгеләр өстендән бер ташны кубарыб алыб өенә китергәндә өй алдысының ишеге төбенә баскыч итеб салган. Шундан соң күб дә узмаган, халкының әйтүенчә, Михайланың бөтен авыз, борын һәм муенларын шеш чорнаб алган. Ул докторга йөреб, озак дәвалатыб маташкан, шеше бер дә төзәлмәгән. Соңга таба Михайланың шеше җәрәхәткә әйләнеб сасыган. Михайла тәмам бу авырудан җөдәгәч, авылда гыйбадәтчәнлек белән танылган бер әбигә барган, әбигә үзенең хален сөйләгән. Әби аңар болай дигән[1]: «Син бит, Михайла, урыс кешесе булсаң да алла бәндәсе. Алла үзенең бәндәләренә көче җитә. Син бит, Михайла, безнең изгеләр өстендәге изге кабер ташын кубарыб алыб китеб, бусага төбенә салыб, баскыч иткәнсең. Беләсеңме син, без ул ташлар янына тәһарәтсез бармыймыз, анда бит зур хуҗалар, изгеләр күмелгән. Аларны кадерсез итәргә ярамый. Алар кадерсезә икән кешене тоталар. Мона сине шул изгеләр тоткан. Бар, син Михайла, тиз генә өеңә кайт! Карт мөәзингә барыб сәдәка бир дә, коръән укырга куш, үзең икенче андай ярай торган эшне эшләмәскә мөәзин алдында сүз бир, рәнҗеткән изгеләрнең рухына диб сәдәкалар бир, шундан соң ташны, мөәзинне чакырыб, аның белән илтеб куй, бу авыруың шундан соң бетәр» – дигән. Вакыйган, Михайла шуларның барын да эшләгәндә бу яман авыруындан тазарган, таза-сау урыс булыб яшәб үлгән диб сөйлиләр авыл кешеләре.

Авыл кешеләренең әйтүенә караганда, бу каберстанда мондан сиксән еллар алда бик күб карт каенлар, корыган хәлдә торалар икән инде, аларның берсе дә калмаган, аларның барысы да череб авыб беткәнләр. Фәкать, бу каберстанның шималь гарәби ягында Актачы суының шәрык ягы тау битендә, төбендән очына кадәр эче куышланыб менгән, бары бер ботагы гына яшәреб үсеб тора торган, андан башка бөтен ботаклары корыган, карт җуан бер каен бар. Бу каенны авыл кешеләре әллә нинди мокаддәс бер агач итеб ихтирам итәләр. Аның сыныб төшкән ботакларын да урыныннан кузгатмыйлар, бу каен ауса, дөньяга зур бәхетсезлек киләчәк икән диб уйлыйлар. Мин, үзем ничә мәртәбәләр күргәнем бар, авылдагы фәкыйрь кешеләр, икешәр-өчәр чакрымдан утын җыеб өйләренә алыб кайткан вакытларында, ник бу каен ботакларын алмыйсыз, дигәч, аңар тияргә ярамый, без аны алмыйбыз диб җаваб биреб,

[1] Ташбилгедә торучы урыслар татарча сөйләшә беләләр (С. Вахиди иск.).

әлеге каен ботакларын халенчә калдырганлар. Халыкның игътикадынча, ул каен Шәһре Болгар заманандан калган изге каен имеш.

Мәзкүр каберстандагы кабер ташлары.

Ташбилге авылының, тау башы изгеләр өсте каберстанының гареб ягында[1] халык тарафындан Самит арты чокыры диб йөртелә торган чокырның шәрык ягы тау битендә, жирда белән бураб ясалган чардуганның эчендә берничә кабер ташларының кисәкләре бар. Без монда нумер тәртибе белән ул кисәк кабер ташлары хакында язачакбыз.

1 нче кисәк кабер ташы: бу кисәк кабер ташының язуыфәләне юк.

Зурлыгы: – биеклеге – бер аршын, киңлеге – 1/2 аршын, 3 вершок, калынлыгы – дүрт вершок. Ташы: саргайган, каты ак таш. Бу кисәк таш, зур кабер ташының төб ягы, җиргә баткан өлеше булырга тиеш.

2 нче кисәк кабер ташы. Бу кисәк кабер ташының зурлыгы: биеклеге өч сөям ике вершок, киңлеге һәм шулай, калынлыгы өч вершок. Ташның михрабында (мин, кабер ташларының иң өске ягында ярым мохит = ярты даирә булыб әйләндерелгән сызыкның эчке ягы михраб диб атаб, аның эчендәге берничә канатлы бизәкне бадьян диб атаб йөртәм) сигез канатлы бадьян сурәте бар. Бу кисәк ташда түбәндә аерым юллар белән күрсәтелгән әнә шушы язулар да,

1 нче юл:

Һу әл-хәййе әл-ләдзи ля йәмүтү

2 нче юл: вә күллү хәййин сәйамуту

3 нче юл: Гомәр улы Исмәгыйль

4 нче юл: улы

Шундан соң 2 вершок киңлегендә буш урын булыб, калган язулары югалган, бары сүз кисәкләренә ошаган кабырчыклары гына бар.

5 нче юл: Мөхәммәд улы

6 нчы юл رَحيَر ... (Рәҗәб?) бәлүи

7 нче юл: рәхмәтуллаһи галәиһи

Шундан соң бу кисәк ташда язу бетә.

---

[1] Мәзкүр каберстанның гареб ягы чигендә, җәнүби шәркыйдән гареб шималига таба юнәлеб, Актачы елгасына төшкән зур бер юлның үзе бар. Авыл кешеләре бу юлны борын заманда Ташбилге аркылы Болгарга китә торган бер юлның калдыгы дип сөйлиләр. Шул турыда борын заманларда Актачы елгасы аркылы күпер дә булган имеш (С. Вахиди искәрмәсе).

Кечкенә изах: бу ташның язуында диккать ителергә тиешле булган, имля җәһатендән мона шундый хосусиятләр бар. Ә – «ى» хәрефенең астында ике нокта язылган:

Әл-хәййе, әл-ләдзи, حى, (бу сүзнең өстендә ике нокта) сүзләрендә ب – «ر » хәрефенең астында бер нокта языла. Мәсәлән: Гомәр, сүзләрендә ث – «س » хәрефенең астында өч нокта куела – сәямүт, Исмәгыйль сүзләрендә.

ج – угыл сүзен аңлата торган, «ул(ы)» сүзенең һәмзәсе өстендә, фәтхә куелыб, «اَولِ» сурәтендә языла. Кайбер сүзләрнең ас-өсләре языла ̃Аллаһы сүзендә «ئه» хәрефенең өсте галәйһә сүзендә «۶» хәрефенә дә фатиха куелыб языла. Безнең беренче юл игътибар иткән, һу әл-хәййе ля-йәмүтү җөмләсе, ташның михрабында бадьян сурәтенең астында язылган. Ташның рәсеме хаттый күфи. Язуы кабартылыб язылган.

3 нче кисәк кабер ташы. Бу кисәк кабер ташында түбәндә язылачак тәртиб белән күрсәтелгән сүзләр укыла.

1 нче юл «рәхмәт» бер сүз

2 нче юл: «ياتوى» бер сүз

Бу кисәкдә башка сүз юк.

4 нче кисәк каберташы.

Бу кисәкнең зурлыгы: ярты аршин биеклегендә, 12 вершок киңлегендә, дүрт вершок калынлыгында. Бу кисәк таш, зур бер ташның түбәнге бер өлеше. Бу кисәк ташда түбәндә күрсәтелгән юллардагы сүзләр укыла:

1 нче юл: Тарих җиаһ

2 нче юл: ти җүр җүр

3 нче юл: җүрә вә җәви рәҗәб

4 нче юл: айхы вәзәбиа

5 нче юл: әте

Шундан соң бу кисәк ташда язу тәмам була. Ташбилгенең Атау ягы изгеләр өсте каберстанында сәламәт сакланып калган бөтен кабер ташы бер данәдә калмаган. Бу каберстанны тәфтиш иткәндә берничә урында кечкенә кисәкләр булыб, чирәм өстендә аунаб ята торган кабер ташларының кисәкләре һәм берничә урында җиргә батыб калган таш төбләре очратырга туры килде. Мәрҗани хәзрәт исән вакытында, Ташбилге авылының мәрхүм Сафа хәзрәт бу каберстанның ташларындагы язуларын укыб, Мәрҗанигә йибәргән булган. Мәрҗани бу каберстанларның язуларын «Мөстәфадәл-әхбәр», 1 нче җилд, 27 нче битнең 11 нче юлында урнашдырган.

2 нче каберстан. Ташбилге авылының җәнүби гарби тарафында, авылдан ярты чакрым чамасы ераклыкда, өч кисәкгә аерылыб, һәрберсе тирәли канау казылыб әйләндерелгән, шәрыкдан гаребкә таба бер-бер артлы сузылыб ята торган, өсләре чирәм белән капланган каберстанлар бар. Безнең белән мосахәбәдә булган картларның әйтүенә караганда, мондан сиксән еллар алда бу каберстанлар бер-берләрендән аерылмаган тирәли канау казыб әйләндерелгән, хәзергедән бик күб зур булган мәйданны эченә ала торган озын һәм киң чирәмлекдән гыйбарәт булыб җәелеб ята булган. Аларның әйтүенә караганда, бу каберстан ул заманда җәнүб ягындан, хәзерге вакытда аралары шактый йырак булган, Мөслим бабай һәм Хисаметдин Мөслиминең каберләренә барыб тоташа торган булган. Хәлбуки, хәзер дә Мөслим баба Хисаметдин Мөслими каберләре озын алан тау башында үзләре генә аерылыб, сукаланмыйча аз гына чирәмлек булыб калганлар. Андан башка урынлар югарыда язылган икенче каберстанга таба сукаланыб, җир ителгәнләр.

Бу каберстандагы кабер ташлары.

1 нче таш. Бу ташның биеклеге биш сөям, киңлеге ун вершок, калынлыгы өч вершок. Бу ташның өске ягы михраб өлеше ватылыб юкга чыкган. Сәламәт калган өлешендә түбәндәге юллар укыла:

1 нче юл: әл-хөкми лилләһи әл-гали әл-кәбир

2 нче юл: Ирек улы Мөхәммәд.

Бу ташда шушы сүзләрдән башка язу танылмый. ташның рәсеме хаттый күфи язуы калкытыб язылган.

2 нче таш. Бу ташның югары өлеше сыныб йиргә төшкән, ләкин анда язу күренми. Ташның калган өлешендә түбәндәге юлларда күрсәтелгән сүзләр укыла.

1 нче юл: галәйһә рәхмәтән

2 нче юл: васыйгатән тарих җиат

3 нче юл: җүр биалым җал

4 нче юл: бераз урын ватылган, дәвамында: әл-әвәле айх.

Бу ташда шуннан соң таныла торган сүзләр күренмәде.

3 нче таш. Бу ташның биеклеге аршын ярым, киңлеге ике сөям, калынлыгы өч вершок, бу ташда һич бер таныла торган сүз калмаган. Ташның бөтен язуы югалыб юкка чыкган.

4 нче таш. Бу таш, сыныб, ике кисәккә аерылган. Ташның югары өлеше – михрабы эчендә, сигез канатлы бадьян сурәте ясалган.

1 нче юлда: күлли нәфсин-заикател-мәүт

2 нче юлда: иләйнә тәрҗигун Әтрәҗ

3 нче юлда: улы Әҗем улы Ырыс

4 нче юлда: улы Мәхмүд зиярату

5 нче юлда: рәхмәтуллаһи галәйһә рәхмәтән

6 нчы юлда: васыйгатән тарих йете.

Шундан соң бу таш сыныб ватылган; шуның өчен ул урындагы язулары да юкка чыкканлар.

5 нче таш.

Бу ташның биеклеге биш сөям, киңлеге ун ике вершок, калынлыгы дүрт вершок. Михрабында сигез канатлы бадъян сурәте. Язулары түбәндә күрсәтелгәнчә.

1 нче юлда: әл-хөкме миләһи әл-гали әл-кәбир

2 нче юлда: Ильяс улы Исмәгыйль

3 нче юлда: улы Мөхәммәд бәләви кә

4 нче юлда: рәхмәтуллаһи галәйһә рәхмәтән

5 нче юлда: васыйгатән, тарих җиати

6 нчы юлда: җәүри алтыш җала зөлькагъ – (шундан соң сызык «даль» хәрефе язылмый калган).

7 нче юлда: айхи ишза әҗи җәрәмсез

8 нче юлда: шәүзә бәр сәр ват

Изах: бу ташның язуында югарыда язылган изахдагы шикелле, « ٮـسـ » хәрефенең астына өч нокта, « ى» хәрефенең астына ике нокта, «ул» сүзенең «ا» хәрефе өстендә өс = фәтхә = галәмәте = ر = хәрефенең астында бер нокта куелыб язылган. Монда дәхый дикъкать итә торган як мона бу бар «جيات җиат» сүзе.

«ج » хәрефенең өсте, « ت » хәрефенең асты беләнә, جهياتى җәяти укыла торган формада, «جوُر » җүр сүзе, «ج » хәрефенең өсте «ﻬ» хәрефенең сәкене белән язылыб, «جهور җәүр» диб укыла торган формада язылган. 3 нче юлның 3 нче сүзе булган «بلوي бәләви» сүзендән соң, башка болгар кабер ташларында ул күренә торган, без аны тыныш галәмәте диб укыган күфи хаттының озын «ک» хәрефенә ошаган бер галәмәт бар. Бу галәмәт вафат булган кешенең исеме ата вә бабасының исеме һәм ул кешенең гонваны язылганның соңында дога җөмләсе булган «рәхмәтуллаһ галәйһу» الح җөмләсен икесен аерыр өчен язылган булырга кирәк. Зөлкагъдә сүзе «ذَاقع » сурәтендә «ذ » хәрефенең өсте белән «ع » хәрефендән соң «د » хәрефе язылмыйча төшерелеб калдырыб ялгыш язылган. Айы сүзенең мәгънәсен аңлата торган «اَيح » сүзе «اَ » хәрефенең өсте

«يَ» һәм «ح» хәрефенең асты белән «әйхы» диб укыла торган бер сурәтдә язылган.

Ташбилге авылының каберстанларындагы кабер ташлары турында шул авылның мулласы Әхмәдулла миңа түбәндәге язылачак кызык бер вакыйганы сөйләде. Ул әйтә: «Миңа, – ди, – күбдән түгел бер чуаш, ташбилге изгеләр өстендәге кабер ташлары чуаш телендә язылган икән, ул каберлекләрдәге изгеләр безнең кешеләр (чуашлар дигән сүз) икән, моны миңа «Сиктәрмә» авылының үзебезнең кодабыз булган чуаш сөйләде, ә аның кулында мона шушы кабер ташларының язуы төсле иске язу белән язган бер китабда бар икән, безнең кодабыз әнә шушы иске китабдан караб сөйли. Бу изгеләр безнең кешеләр икән», – ди.

Мин, Әхмәдулла мулладан бу сүзләрне ишеткәч, чуашның риваяте белән бик кызыксыныб, бу сүзнең ни чаклы дөреслеген, Сиктәрмә чуашы кулындагы иске китабның чындан да бу кабер ташларының язуы белән язылган, ягъни хатты куфи белән язылган иске бер китабмы, яки бу хәбәр нинди булса да уйдырылган бер хәбәрме икәнлеген Сиктәрмәгә барыб, мәзкүр хәбәрне сөйләүче чуашны табыб, тәфтиш итәргә булдым.

Сиктәр исемле чуаш авылы Ташбилгедән ун-унбер чакрым мәсафәдә хисаб ителә. Сиктәрмәгә барыр өчен, мин үземә ибдәш итеб, чуашлар белән әледә күб катыша торган, кечкенәдән чуашлар арасында үскән, аларның гореф-гадәтләрен, әхлакый рухияләрен бик яхшы белә торган Әхмәдулла мулланы алдым. Без икәү аның белән Сиктәрмәгә китдек. Ләкин, ул чуаш Сиктәрмә авылындан күчеб китеб, урман арасына яңа авылга барыб утырган икән, урман арасына яңа авылга барыб табдык. Чуаш үзе өйдә юк, хатыны гына иде. Чуаш хатыны безгә: «Хуҗа өйдә юк, йомышыңыз булса, шунда барыңыз» – диде. Бу чуашның умарталыгының кайда икәнлеген сорашыб, үзебезнең юлыбызда дәвам итдек. Әлеге яңа авылдан ике чакрым чамасы ераклыкда урман эчендә кояшка каршы бер урында чувашларның умарталыкларын без барыб табдык. Чуашлар, Әхмәдулла мулланы белгәнгә күрә, безне бик яхшы каршы алдылар. Алар безгә яныб тора торган утның көленә күмеб пешергән бәрәнге, чәйнек эченә салыб кайнатылган куе чәй вә икмәк тәкъдим итделәр. Чуашлар белән без тәмам тынышыб китдек. Алар белән байтак сөйләшеб утырганның соңында, әлеге иске китаб мәсьәләсенә күчеб, сүзне шуның тирәсендә дәвам иттердек. Инде чуашлар белән аңлашу-танышу

җитәрлек дәрәҗәсендә булганлыгындан, мин чуашка болай диб сүз башладым: «Мин Казандан кайткан бер кеше булам. Үзем төб Ташбилгенеке. Әле без Ташбилгегә кунаклый кайтдык. Безгә Казанга алыб китәр өчен бер аз бал һәм май кирәк булачак иде, сездә бәлки табылыр, диб килгән идек» – дидем. Чуаш миңа: «Бик яхшы буласы икән, мондан берничә көн алда гына балны сатыб йебәргән идек шул, май бераз табылыр», диде. Мин: «Алай булса, ярый, әгәр дә башка төшдән табалмасак, Матак базарына сез чыга торгансыз, шунда тагы белешербез; инде башка төшдән табсак, сезгә килеб йөрмәбез» – дидем. Миңа чын-чында бал да, май да кирәк түгел иде. Тик бары турыдан-туры китабка күчелгәндә чуаш әллә нинди хыялларга китеб, мәкер белән, хәйлә белән йөрүче кешеләр диб куркыб, безгә ул китаб хакында дөрес мәгълүмат бирмәү куркынычындан качу өчен саклык чаралары кылыб, чуашка мона шундый бер комбинация ясарга туры килде. Шундан соң мин чуашка: «Ярый инде, шул кадәр җирдән килеб бал да булмады, инде мондан соң дус булыб китәрбез, без дә шулай сезгә килгәләрбез, сез дә Ташбилгегә кунак булыб барыңыз, Ташбилгедә сезнең кодаларыңыз да бар әле. Сезгә килергә дә Ташбилгедәге кодаңыз кушкан иде. Шуңар күрә килгән идек», – дидем. Шундан суң мин чувашка: әле кодаңыз дигәч, искә төшде, сезгә ялан килеб булмый. Килгән чагында сораб китим әле, сезнең Ташбилгедәге кодаңыз «Мәтрәй» әйтә, аларда иске бер китаб бар, ди, ул китабның язуы Ташбилге изгеләре өсте зиратындагы ташларның язууы шикелле, ди, ул китабда Ташбилге изгеләре безнең кеше (чуаш) булган, дип сөйләде. Моңа бу бик кызык хәбәр, шушы китаб сездә бармы, Митрәй кодагыз дөрес сөйлиме, дидем. Чуаш миңа җавабында: «Дөрес, ул китаб бездә бар. Түлке монда – умарталыкда – юк. Өйдә» – диде. Без анардан, ул китабны өендән умарталыкга алыб килеб күрсәтүен үтендек. Чуаш безнең үтенечне кабул итеб, умарталыкдан авылына кайтыб, ул китабны алыб килеб безгә бирде. Мин инде, Идел буе болгарларындан калган мөһим иске бер тарихый китабны кулыма төшерәм, Болгар халкындагы бик күп карангы мәсьәләләрне безгә ачыб бирә торган тарихый материал инде миңа килеб керә диб торганда, чуаш минем кулыма тышланган бер китаб китереб бирде. Ул китабны ачып карасам, ни күзем белән күрим, 1922 нче елда, Катанов тарафындан нәшер ителгән, болгар кабер ташларындагы чуашча гыйбарәләр хакында язылган бер кенәгә

икән. Мин шундан соң чуашдан бу китабны сезгә ...: «Казанда безнең попның белешләре бар, без поп белән дус торабыз, әнә шулар попка да, миңа да берәр кенәгә йебәргәнләр иде, поп безгә бик яхшы аңлатыб-төшендереб сөйләб биргән иде, поп безгә, Ташбилге изгеләре чуаш булганлар, дип сөйләгән иде, без побдан ишетеб сөйләгән идек» – диде. Шундан соң без чуашлар белән бик дусларча исәнләшеп, Ташбилгегә кайтыб китдек. Юлда кайтканда Әхмәдулла мулла миңа, борынрак заманларда урыс түрәләренең татар авылларындан китабларны җыеп яндырганлыкларын, бу хәбәрне аңар үзенең бабаларындан ишетеб, этиләре сөйләгәнлеген риваять итде.

Югарыда язган мәгълүматлар белән минем Ташбилге авылында ясаган тәфтиш вә тәдкыйкларым шуның белән тәмам була.

Июнь аеның ун өчендә Ташбилгедән Иске Баллы Күл авылына килдем. Мин Иске Баллы Күлгә килгәндә вакыт көндезге унбер сәгать иде.

Коры Көрнәле

Коры Көрнәле авылы фәкыйрь генә бер мөселман авылы, халкы мишәрчә сөйлиләр.

Көрнәле турында бу авылның картлары болай сөйлиләр. Безнең Коры Көрнәле авылы тирәсендә шәһре Болгар заманасында бер авылмы, шәһәрме булган икән. Әнә безнең авылыбызның бер кырында булган кабер ташлары шул замандан калган. Безнең басуыбызның бер җирендә бик күб Чулман ташлары таралыб яталар. Ул урындан иске акчалар, я әзгәри тәнкәләр дә табыла. Бу акчаларның язулары мөселманча. Андан башка бизәк әйбер һәм хәнҗәр, ук очы кебек нәрсәләр дә табыла. Шунардан ул урында борынга заманда я шәһәр, я авыл булуын болай да уйлаб белергә мөмкин, диләр.

Әнә шул иске шәһәре, авылы, инде нинди сәбәб беләндер, беткән. Анда әсәре булыб, кабер ташлары, Чулман ташлары, башка шундый иске әсәрләр генә калганлар. Шундан соң күбме еллар үткәндер, бу урынлар тагы, кап кара калын урман булыб киткәнләр. Казан шәһәрен урыслар алгач, безнең мөселманларга авыр тормыш башланган. Әнә шул чакда безнең Көрнәле бабай урысларның җәбер золымындан котылу уе белән Пенза яныннан килеб, мона шушы урынга утырганда, шундан соң үрчи-үрчи мона шушы безнең Көрнәле авылы килеб чыккан. Көрнәле ике авыл: берсе безнең авылыбыз, Коры Көрнәле = Сукый Көрнәле, диләр. Икенчесе Җүеш = Мокрый Көрнәле диб йөретелә.

Коры Көрнәле авылы 1921 нче елның 7 нче маенда бөтеннәй яныб беткән, бу янгында барлыгы бер йөз сиксән йорт янган. Картларның әйтүенә караганда, әнә шул зур янгында, халык кулында булган бик күп кулъязмалар утда яныб юкка чыкканлар.

Бу авылда хосусый мосахабә йетәрлек кешедә булмады. Мосахабәгә артык эш дә күренмәде.

Бу авылның картлары мондан утыз ел алда Гыйляҗеддин Фәйзрахман углында язган бер тарих китабы барлыгы сөйләделәр. Хәтта бу тарих китабы укыган кешеләр дә әле исән икән, алар бу китабда Казан, Болгар халыклары турында бик күп нәрсә язылганлыгы сөйлиләр. Шулай ук бу авылның картлары шәһре Болгардан Биләргә барышлый Рабига авыстайның кыз шәкертләре, шул тирәдә үтеб йөри булганлар дип сөйлиләр.

Коры Көрнәледә борынгы Каберстан һәм кабер ташлары

Коры Көрнәле авылының җәнүб ягында, тау битендә, борын заманларда аерым иске каберстан булыб, хәзер инде кайбер ташлар урамда, кайберләре ындыр артында берәрсе хәзерендә дә үлекләр күмә торган каберстанда калган. Бер каберлек булган. Коры Көрнәле авылының мулласы Габеррахман Хәмзинның әйтүенә караганда, борын заманларда, бу каберстан зур бер мәйданны эченә алган чирәмлек булыб, аның ташлары да күб санда булган. Хәзер инде каберстанның мәйданына урам корылыб, йортлар эшләнгән, ташлары да байтагысы юкка чыккан, инде.

Бу ташларны урынларына барыб, язуларын укыб, зурлыкларын, дикъкать илән тәфтиш итдем. Ул ташлар турында тәртиб илән монда язачакмын.

1 нче таш.

Ташның зурлыгы.

Биеклеге – тукыз сөям.

Киңлеге – дүрт сөям.

Калынлыгы – дүрт вершок.

Бу таш, Коры Көрнәле авылының урамында рәшәткә эчендә тора. Ләкин инде ташның язуы тәмам беткән.

2 нче таш.

Зурлыгы.

Биеклеге – җиде сөям.

Киңлеге – өч сөям.

Калынлыгы – биш вершок.

Таш ак төсдә булыб, инде бераз саргайган. Каты таш. Михрабында алты канатлы бадьян бизәге бар. Язуы хатты күфи, казылыб язылган.

Ташлар язуы:

1) – -әл-хөкме миләһи әл-Гали әл-Кәбир

2) – Госман улы Мохсин белүи (билгесе)

3) – мәк, рәхмәтуллаһи галәйһа

4) – рәхмәтән васигатән, тарих

5) – җиде җиат(и) җүр йөз егерме дүртенче җиарем җал[1] тәва.

6) – тем җал зөлхиҗҗә

7) ае ван сәкер күән (ун сигезенче көн)

8) әте (булды).

Ташның язуы «تَا» сүзе белән тәмам була. Әмма ташда язу беткәндә соңыда, җиде вершок буш урын калдырылган. Иске Рәҗәб авылында, тарихы язылмаган бер ташда шунда язылмыйча калдырылган буш урын булганлыгын языб киткән идек. Бу ташда тарихы булдыкы хәлдә буш урын калган. Бу ташның беренче юлындагы сүзләрнең ас, өс һәм нокталары беткән. Икенче юлның беренче сүзе: «راشع» дип «ع» каты гайн, «ش» урта «ر», «ر», ялгыз белән язылган. Башка Болгари ташларының имляларында күренә торган кагыйдә буенча, бу ташның язуында да «ي» хәрефенең астында ике нокта, мәсәлән «ي» шәкелендә, «ر» хәрефенең астында бер нокта, мәсәлән «ٮٜ» кебек күзгә бәрелгән аерымлыклар бар. Өченче юлның беренче сүзе бүлеб «کمـ» ягъни «کمـ» диб укырга мөмкин булган бер билге язылa. Башка Болгари ташларда бу билге «ک» формасында гына да язылa. Моның турында инде бераз языб киткән идек. Шуның өчен яңадан тукталыб тормыйбыз. Тарих сүзенең соңгы хәребе булган «ح»ның алдындагы «ي» хәрефенең астына куелырга тиешле ике нукта, астлы-өстле итеб «ي» хәрефнең нәркәсе янында куелганлар.

III таш.

Зурлыгы:

Биеклеге – алты сөям.

Киңлеге – унбер вершок.

Калынлыгы – дүрт вершок.

Таш бераз саргайган, башда ак төсдә булган, михрабында сигез канатлы бадьян бизәге. Язуы казылыб язылган, хатты күфи.

1) Әл-хөкме лилләги әл-Гали әл-Кәбир

2) хаҗи Хөсәен улы хаҗи

3) Гомәр бәк [зиярәте][2] рәхмәтуллаһи
4) галәйһа рәхмәтән васыйгатән вафа-
5) т балтуй тарих җиәти
6) җүр җерем алтысы җал (йөз егерме алтынчы ел)
7) сәфәр айхы җерем алтысы (сәфәр ае егерме алтынча
8) күән әте (көн булды)

Өченче ташның язуы шуның белән тәмам була: язулары тәмам булгач, ташның түбән тарафында биш вершок язылмый калган буын урыны бар. Таш урынында нык вә мәхкәм торган, бозылган урынлары күренми, таш каты, бераз саргайган. Тирәсендә бер нәрсә дә юк. Бөтеннәй ачык бер мәйданда утыра. Бу ташны киртә белән тирәләб алырга Көрнәле агайларына әйтеб калдырдым. Тарихый әйберне саклау кирәклек хакында сөйләдем.

Кечкенә изах:

Ташның язуында «س » (с) хәрефе астында өч нокта «ڛ» сурәтендә, «ی » хәрефе астында ике нокта «ي» сурәтендә, «ر » хәрефенең астында бер нокта «ڔ» сурәтендә языла. Байтак сүзенең хәрәкәсе куелган. «Гомәр» сүзе белән «بلوی» арасында күфи хаттының ك хәрефе рәвешендә бер билге куелган. Вафаты «җиати» جياتِ сүзләре ت хәрефенең асты белән куелган. Ташда барлыгы сигез юл язу бар.

IV нче таш.

Зурлыгы:

Биеклеге – бер аршын.

Киңлеге – ярты аршын.

Калынлыгы – өч вершок.

Ташның язуы:

1) Әл-хөкме лилләһи
2) әл-Гали әл-Кәбир
3) көлли нәфсин заикате-
4) ль мәүт тем иләйнә тәр-
5) җигун

Шундан соң бу ташның язуы танылмый.

Ташның кашкасында – ягъни иң югарыгы михраб урынында кечкенә генә дүрт канатлы бадъян бизәге, башка зур ташлардагы кебек, бу ташның ярты даирәләндереб ясалган микраб өлеше юк. Таш кечкенә.

7 нче таш.

Бу таш бөтен түгел, бары михраб өлеше белән бер юл язуы гына калган. Ташның башка өлеше ватылыб юкка чыккан. Михрабында даирә эченә алты канатлы бадъян бизәге бар.

Язуы:

يموت لا الذي لحى الا هو

Мондан башка Коры Көрнәле авылының урамында бер таш ята. Бу ташны Нуреддин мулла Сәгыйтдин углы дигән кеше, шул урындан кабер чыкканлыгындан, кабер иясенә әҗре барыб торсын өчен, авыл халкына, балта, пычак, кебек нәрсәләрне чарлар өчен (ышкыб үткенәйтү өчен), шул урынга китереб куйган иде, диб халык сөйләде. Ватылган бу таш, тегермән ташы.

Мәзкүр Көрнәле авылының хәзерендә мәетләрен дәфен итә торган каберстанында Рәхимкол бабаның өстенә куелган бер таш бар. Бу ташның язуы урыс истилясы соңындагы ташларда очрый торган тарызда язылган.

Ташның язуы:

1) Бисмаллаһир ир-рахман ир-рахим

2) Калә Аллаһү Тәгалә

3)

4) вә әл-кирам, тарих һиҗрия

5) 1247 нче сәнә йылда зөлхиҗҗәнең

6) 9 нчы йәүмендә Рәхимкол бине Сөләйман

7) 56 яшендә дарелфәнадән

8) дарелбәкайә рихләт кылды

1831

Бу ташның ике як кабыргасында калкытыб сызылган сызыкның ике ягына дәкый озын юл итеб язу язылган.

Әнбияләр Әүлияләр? тормады әй кәмал

Кичде адәм вә Мөхәммәд әнбияләр бил тәмам

Монә бу кадәр язу ташның кабыргасының беренче юлында, икенче юлы ачык танылмагандан языб алмадым. Ул юлның да мәфһүме беренче юлында мәфһүме белән берүк.

Авылдан ике чакрым шәрык ягында, Казначы диб йөртелә торган елга буйларында һәр төрле мөселманча язулы иске акчалар вә башка шундый тарихый әйберләр табылыб килгәнлеге миңа хәбәр итделәр. Риваятьләргә караганда, мона бу ташларның хуҗалары яшәгән кечкенә бер болгар шәһәре шушы иске акчалар табыла торган җирдә булган имеш.

Июнь 19 нда өйләдән соң Коры Көрнәле авылындан Көекгә кайтыб китдек. Көекдә янә бер кич куныб, июньнең 20 ндә көндез сәгать икеләр тирәсендә Әҗмәр аркылы Ыспас шәһәренә баруны касд кылыб юлга чыкдык.

Көекдән Әҗмәргә барганда, биек урындан, байтак юлы, ике урман арасындан бик күңелле җирдән бара икән. Әҗмәргә барганда безнең уң ягыбызда борынгы Чулман (Иске Кама)ның җәнүб ярлары, аның өстендән шималь шәркый якларындагы ерак урынларын күреб була.

Әҗмәрдә артык туктаб торырга туры килмәде. Без андан үтеб генә китдек.

Июньнең 20ндә Ыспас каласында кичке сәгать уникегә кадәр ял итеб, төнлә белән затунга барыб, пароходка утыру максады белән бер урыс яллаб юлга чыкдым.

Без Ыспас Затунына иртә сәгать өчләрдә барыб җитдек. Затонда авыл базарындагы кадәр атлы агайлар җыелыб, атларын туарыб киләчәк. Парахуддан төшәчәк кешеләрне Ыспаска алыб китәр өчен көтеб торалар иде.

## Төгәлбай авылында

Төгәлбай ике мәхәлләле, Бизнә суы буенда, гади генә бер мөселман авылы. Авылда бакча-фәлән юк. Халкы мәктәб тәрбиясе күргәнгә ошамый. Бу авылда истибдад заманасында бер ишан булган, инде ул үлгән. Шуның өчен булырга кирәк җәдид мәктәбе булмаган.

Мәзкүр ишан Әхмәдҗан хәзрәт диб халык телендә йөртелә. Үзе Төгәлбай авылының беренче мәхәлләсендә имам булыб хезмәт иткән. Ишан хәзрәт төб «Бүәле йөрткел» диб атала торган авылның крәстиян баласы булган. Ишан булганчы Казан шәһәре Күл буе мәдрәсәсендә тәхсилдә булган. Бу кеше Казан сәүдәгәре Садыйк хаҗи Галикәев белән бергә бер мәдрәсәдә тәхсилдә булган икән, Садыйк хаҗи бу кешенең галим түгеллеген сөйли икән.

Мәдрәсәдә тәхсилдә вакытында Әхмәдҗан ишан мәдрәсәсенең казыйсы булыб торган. Үзе шәхсән бик мәһабәт, үзен буйлы, киң күкрәкле, дәү сакаллы бер адәм икән. Халык кашында, бигрәк дә гавәм кашында хөрмәте- игътибары зур булган. Әхмәдҗан хәзрәтне чындан да диндар, суфи, тәкъви, бик тәхәммелле (түземле) кеше иде диб миңа сөйләделәр. Вафатындан соң, җәназасын озатканда, гәрчә эш өсте булса да, Спас кантонының һәр тарафын-

дан унбиш меңләб кеше җыелганын сөйләделәр. Ходаның рәхмәтендә булсын, яхшы адәм икән, диләр.

*Төгәлбәйдә Сиддикъ Арсланов белән мөсахабә*

Мәзкүр авылның икенче мәхәллә имамы Сиддикъ хәзрәт Арсланов, авыл картларындан күб мәртәбәләр ишеткән, бу авылның кара тарихындан түбәндә язылачак сүзләрне миңа сөйләде. Ул әйтә:

Картлар хикәя кылалар иде, Төгәлбай авылында, борынгы иске заманларда, бу инде татар ханлары заманасында булырга кирәк, бер мөселман түрә булган. Халык аңар «бәй» диб, «бәк» диб әйтә булганлар. Бу бәй бик гадел кеше булган. Мөселманларга һәм башка халыкка да бер дә җәбер-золым итмәгән. Кыскасы, аның барлык эше дә төгәл булган, бөтен булган. Кыеклык-китеклек фигыле аңарда булмаган. Тик бөтенлек, төгәллек генә булган бу бәй урыс белән татар ханларының сугышында урысларга күб зарар китергән. Хәтта зур егетлекләр, зур эшләр күрсәткән. Кайбер кешеләрнең әйтүләренә караганда, мона шундый ханлар белән урыснық сугышында зур егетлекләр, зур эшлеклелекләр күрсәткәнлегендән, аңар, ул «бәйгә» Төгәлбай (мөкәммәл түрә, кямил түрәлекгә лаек түрә мәгънәсендә була) диб, татар ханлары тарафындан аталган исеме. Мона бу бәйгә зур эшлеклелеге өчен безнең Төгәлбай халкы аңар [кол] итеб бирелгән имеш. Бу йер аның милеге булган имеш, диләр. Моны шулай халык сөйли. Халыкның ата-бабаларындан бирле телдән-телгә сөйләнеб килә торган кара тарихның хәбәре инде ди Сиддикъ хәзрәт. Шундан соң Сиддикъ хәзрәт Фәзлуллин Төгәлбай авылының шималь ягында, авылдан 3 чакрым чамасы йыраклыкда Күшкә дигән урыс авылының шәрекъ тарафында, Төгәлбай халкы тарафындан «Кала тавы» диб йөртелә торган борынгы бер шәһәр хәрабәсе барлыгын миңа хәбәр бирде. Шундан соң ул миңа бу кала тавындан биш чакрым чамасы җәнүбә таба йыраклыкда, кала капкасы диб йөртелә торган әйләнәсе тирәли үр һәм чокыр белән әйләндерелгән борынгы бер ныгытма урыны барлыгын сөйләде.

*Җитмеш сигез яшендәге Хәлилулла Габидулла улы белә(н) мосахәбә.*

Минем белән булган мосахәбәсендә Хәлил баба әйтә: безнең Төгәлбай авылында ике бабабыз бар, икесе дә Төгәлбай, диб йөртелә. Беренче бабабыз бик иске заманда «Хаклар заманында» зур бер түрә булган, әнә шул түрә, бабабыз.

Икенче Төгәлбай баба әле ул соңрак заманларда, Казан ханлыгы зәгыйфләнеб, безнең бу якка урыслар килгәч, урыс патшалары

заманасында Төгәлбай авылына килеб утырган кешене соңгы Төгәлбәй бабай ул ниндидер урыс патшасына эш күрсәткән. Төгәлбәй бабаның эш күрсәтүе болай булган. Ниндидер, кайсы патша беләндер, инде анысын ачык белә алмыйм, сугыш булган. Сугышда безнең бер полк гаскәр без җиңелгәч, Төгәлбәй баба әләмне (знамя) саклаб алыб калган. Аның бу эше урыч патшасына ишетелгәндә Патша Төгәлбәйне үзенең катына чакырткан, синең бу хезмәтеңә ни бүләк бирим, җир суы, урманмы, акчамы бирим диб патша сорагач, Төгәлбәй миңа боларның берсе дә кирәкми, бары борын-борындан мөселман туфрагы булыб килә торган бер җиргә утырырга рөхсәт сораган. Патша рөхсәт иткән. Шундан соң Төгәлбәй баба Спас өязендә Шәһре Болгар заманасындан бирле мөселман авылы булыб килгән Төгәлбәй авылына килеб утырган, ди. Төгәлбәй баба үзе Сембер вилаяте, Буа өязе чите авылындан булган имеш.

Төгәлбәй баба, Төгәлбәй авылына килгәндә аның белән бергә ике чуаш да килгәнләр, бу чуашның берсе «Борнай», икенчесе «Биктебай» исемле булганлар. Чуашлар ул чагында безнең мөселманга бик якын торганлар. Чуашлар ул заманда гел мөселман белән бергә катнашканлар. Хәтта мөселманга кыз биргәнләр, мөселманларның мулласын үзләренә чакыртыб исем кушдырганлар, авыру һәм сырхауларын муллага китереб яки мулланы алыб килеб, өшкерткәнләр, шулай чуашлар татарларны үзләренең иң якын туганлары итеб бөтен эшдә татарлар белән бергә булганлар, ди.

Төгәлбәй бабайга ияреб, бу якка да «Борнай», «Биктебай» исемле ике чуаш килгән. Болар килгәндә шәһре Болгар җирендә әле буш урынлар, әүвәле авыл яки шәһәр урыны булыб да, урыслар бу якка килгәч, хәраб итеб, ул авылларында яки шәһәрләрендә үзләрен яндыргач, халкын үтереб бетергәч, кырлары, басулары буш сахра булыб калган җирләр бик күб булган. Төгәлбәй баба мөселман кеше; әлеге безнең Төгәлбәй авылына килеб утырганда, икенче нәсел булыб, бу Төгәлбәйдән аның балалары таралган. Борнай татар Борнас янындагы буш бер урынга утырган, анардан хәзерге замандагы чуаш Борнае авылы хасил булган. Биктебайда шундый ук буш урынга утырыб, хәзерге Биктебай авылы хасил булган. Кайбер кешеләр боларны үзара шобага салганлар да диб сөйлиләр.

Хәлил баба әйтә:

– Төгәлбәй бабаның атасы Җулмәт (Җәл Мөхәммәд), аның атасы Тукмак баба, аның атасы Сакмак баба, ди. Төгәлбәй бабаның улы Сөләйман булган. Аның улы Сәин, аның улы Зөбәир бул-

ган. Аның улы Гобәйдулла, аның улы Хәлиулла мин булам, Минем улым Әхмәд-Гата, ди.

Димәк, Төгәлбәй авылының ике дәвере бар, аның беренче дәвере, халкының риваятенә караганда, шәһре Болгар яки Казан ханлыгы заманасында бер мөселман түрәнең милке уларак яшәгән. Урыс патшалары заманасында бу авылга яңадан бер Төгәлбәй исемле солдат килеб утырган, моның килүе Төгәлбәйнең икенче дәвере булыб, шул ук авылга икенче нәсел килеб катнашкан була.

Бу авылда иске кабер ташлары борын-борындан күб булыб килгән. Ләкин инде хәзерендә бер генә калган. Әнә ул борынгы кабер ташы борынгы Төгәлбәйнең элеке заманасындан калган булган диләр.

Мондан дәкый шуны аңлаб була ки, мондан, әйтик, ике йөз илле йыллар яки өч йөз йыллар элек Спас кантонында, борынгы Казан, Болгар ханлыклары заманасындагы яшәгән татарлардан калган басулар, кырлар сахра булыб ята булганлар. Алар күб булганлар. Аларның борынгы хуҗалары урыслар тарафыннан юк ителгән булганлар. Аларның урынларына соңындан урыслар, чуашлар, мишәрләр килеб утырганлар.

Шулай да бик калын кара урман эчендә булганлыкларындан, Рәҗәб, Ташбилге, Янбакты, Борнай, Әлки авыллары шәһре Болгар заманасындан бирле борын-борындан бер нәсел булыб, Төгәлбәй, Баллы Күл кебек авыллар соңындан килеб кушылган икенче бер нәсел белән катнашыб, элеке-элекедән бирле йәшәб килә торган авыллар булыб, безнең заманыбызга чаклы килгән булалар. Кара тарих шуны аңлатадыр.

Хәлил бабайның әйтүенә караганда, Бизнә, Никольский, Ширбәтле исемендәге хәзерге урыс авылларының барысында да элгәре заманда мөселман алпавытлар булган. Бу авылларның барысы да шул заманда мөселман авылы булган. Иң соңгы заманда берсен Никольский диб атаб, исемен үзгәрткәнләр.

Төгәлбәй авылында, Нуреддин Әхмәджан хәзрәт углы кулъязмалар турында миңа түбәндәге мәгълүматны бирде. Ул әйтә:

– Шәһре Болгар газиләре исемендә бер китаб, Әнҗерә авылында мөәзин хатиб Галяведдин углының кулында бар иде. Бу кулъязманы мәзкүр мөәзиннең бабасы Габделвәли мөәзин Габделгазиз углы язган иде. Шулай ук мин Төгәлбәйнең шәҗәрәсендә күргәнем бар иде. Боларны шаять тикшереб, сезгә белдерермен диб, миңа белдерергә вәгъдә кылды. Төгәлбәй авылында табылыб килгән тарихи әсәрләр турында.

Хәлил баба әйтә: кала кабкасының төн ягына таба (Төгәлбәйгә таба) ике йөз сажин чамасы ераклыкда булган бер атаудан, мондан бер ничә еллар алда, зур көмеш беләзек табканлар иде. Бу беләзек ике вершок киңлегендә, калын, авыр беләзек иде. Бу беләзекне Җура Мөхәммәдҗан диб йөртелә торган бер авыл кешесе табкан иде. Инде ул беләзек кемдәдер хәзер белмибез, ди. Хәлил баба кала кабкасы исемендә йөртелә торган борынгы ныгытманың кабкасының ике ягында чуен булганлыгын, йыллар үтә-үтә бу чуен баганаларының җиргә сеңгәнлекләрен хикәя кыла.

Сиддикъ хәзрәт Габделхак углы әйтә. Төгәлбәй авылындан өч чакрым шимальга таба, Төгәлбәй басуында, Кала тавы диб йөртелә торган шәһәр харәбәсендән борын-борындан бик күб тарихи әйберләр табылыб килгәнлеген сөйли. Ул әйтә: «Мәзкүр шәһәр хәрабәсендә сукалаган чакда игенчеләр (крәстиянләр) чүлмәк белән күмелгән мөселманча язулы вак тәнкәләр, колак алкалары, беләзекләр, хәнҗәрләр, сөнгеләр, пычаклар таба торганлар иде. Инде соңгы елларда, бу турыда иске әйберләр аз табыла башлады. Хәтта, халыкның әйтүенә караганда, мондан йөз еллар алда, әле шәһәр хәрабәсе сукаланмаган чирәм булыб торган заманларда, бармак кебек итеб, дүрт кырлы ясаган, тырма теше шикелле көмеш кечкенә таякларны унарлаб-унарлаб җыеб табкан булганлар. Ул заманда әле бу шәһәр хәрабәсендә яңгырдан җирдә бик күб мөселманча язулы көмеш тәңкәләр табыла булганлар».

Нургали Галиулла углы әйтә:

– Мондан илле еллар алда Калалар тавындан (Төгәлбәйнең шималь ягындагы шәһәр хәрабәсендән) безнең атабыз Галиулла Гомәр углы яңгыр чугандан соң, мөселманча язулы тәңкәләрне уч белән тотыб, җыеб кайткан иде. Инде ул тәнкәләр анда-монда таралыб, югалыб беткәнләр, хәзер берсе дә калмаган, ди.

Нургали Галиулла сүзендә дәвам итеб әйтә: безгә этиләр сөйли торган иде. Морзалар Салманы авылының Җәләлетдин Габденнасыйр[1] углы сөли булган: «Төгәлбәй авылының басуындагы борынгы шәһәр хәрабәсендән тырма теше шикелле, дүрт кырлы бармак шикелле кечкенә көмеш таякларны унарлаб-унарлаб таба идек, ул урында бик күб иске әсәрләр табыла торган иде», – диб.

---

[1] Бу кеше авылдан-авылга исламчылык кылыб, сәүдә итеб йөргән, моңар туксан еллар чамасы булырга кирәк, бу кешенең сәүдәсе кытат, басма кебек маллар булган.

Мөхәммәдрәхим углы дигән кеше бу шәһәр урыныннан, мөселманча язулы, бик матур итеб эшләнгән корыч хәнҗәр табкан иде. Инде аны кайда куйганлардыр мәгълүм түгел, ди. Ул кеше, бу хәнҗәрне беләсезме, бу хәнҗәр безнең борынгы бабаларыбыздан калган бик кадерле хәнҗәр, мин аны Кала тавындан табдым, диб мактаныб сөйли торган иде. Инде ул кешеләр үлеб бетделәр, ди. Мондан башка да Кала тавындан, бик күб ук очлары, төрле кораллар, бизәкле әсбаблар, савыт-сабалар табылыб килә торган иде, ди. Төгәлбәй авылында хәбәр бирделәр. Мондан ун-сигез еллар алда, Спас кантоны, Әлки авылының басуында җир төбләгән чагында, Әлки авылының Яңа Кората дигән урыс авылына чикдәш басуыннан, зур гына чүлмәк белән, мөселманча язулы эреле-ваклы акчалар табканлар. Төгәлбәй авылының югарыда сөйләгән борынгы шәһәр хәрабәсендән табкан берничә иске әсәрләрне, мин үзем дә агайлардан сатыб алдым. Ул әйберләрнең берсе колак алкасы кисәгенә охшаган бакыр ярты даирә, икенчесе гарәб хәлифәләренең акчасы, көмеш тәнкә һәм башка әйберләр иде. Бу әйберләр турында Спас кантонына ясаган гыйльми йөреш вакытында табылган кулъязмалар вә тарихи әсәрләрне язган вакытда мәгълүмат биреләчәк булдыгындан, бу урында алар турында артык тәфсилләб языб торуны тиеш күрмәдек.

Төгәлбәй авылындагы кабер ташы турында.

Төгәлбәй авылының зиярәтендә борын замандан калган бер ташның булганлыгын миңа сөйләделәр. Мин, үземә шул авылның II нче мәхәллә имамы Ситдикъ хәзрәтне һәм үзем белән бу йөрешемдә бергә булган Х. Галиевны юлдаш итеб, ул ташны карарга мәзкүр каберстанга бардык. Бу каберстанга хәзерендә дә Төгәлбәй халкы мәетләрен күмәләр икән әле. Бу каберстанда әлеге ташдан башка, иске таш юк. Булыб да беткәнме, әллә бу ташның үзендә икенче бер урындан күчереб китереб куйганлармы, ул турыда белүче кеше миңа очрамады. Ташның зурлыгы

Биеклеге: 22 вершок

Киңлеге: 10 вершок.

Калынлыгы: 3 вершок.

Таш инде карала төшкән, таш үзе каты, язуы казылыб язылган, бозык куфи хатты белән. Язуында бик фахиш хаталар бар. Язучы хаттат бик надан кеше булырга охшый[1].

---

[1] Истәлектә ташның тексты да китерелә.

Һич бер сүзенә нокта куелмаган. Шундан соң бу ташның берничә юл язуы танылмый.

Төгәлбәй авылында, бу каберстандан башка тагын бер каберстан бар, аны Төгәлбәй халкы изгеләр өсте дип йөртәләр. Хәзер инде ул изгеләр өстендә һич бер таш калмаган. Мәзкүр изгеләр өсте Төгәлбәй авылындан өч чакырым читдә, шәркый шимали тарафында, куаклык эчендә, бер дисәтинә чамасы мәйданны эченә ала торган бер урында гыйбарәт булып калган. Риваятьләргә караганда, бу иске каберстан, югарыда языб үткән шәһәр хәрабәсенең шәһәр булыб йәшәгән заманасындагы каберстаны булган икән. Мондан йөз йегерме еллар мөкаддәм, бу каберстанда кабер ташлары да күб санда булыб торалар икән. Ләкин шул тирәдәге урыслар ул каберлекдәге ташларны үзләренең йорт кирәкләренә татар өчен кубарыб алыб, авылларына китергәнләр, шул сәбәбле, ул ташлар инде бөтенләй юкка чыкканлар икән.

Бу каберстан мөнасәбәте белән Төгәлбәй авылының картлары миңа түбәндәге мәгълүматларны сөйләделәр. Алар миңа әйтделәр: әнә ул кала өсте диб йөртелә торган урында Шәһре Болгар заманасында бай гына бер шәһәр, бабайлар аның исемен дә беләләр иде. Инде без онытдык, тик без анда шәһре Болгар заманасында шәһәр булганны гына хәтерлибез. Әнә шушы шәһәргә чит илләрдән, чит мәмләкәтләрдән сәүдәгәрләр килә булганлар. Бу шәһәрдә зур базар булган. Анда гарәбләр дә килгәнләр. Урыслар да килгәнләр. Бу шәһәр үзенә күрә хәзерге Мәкәрҗә сымак сәүдә урыны булган.

Гарәб ягындан килә торган сәүдәгәрләр әнә шушы шәһәрдән узыб, кайберләре әйберләрен шушы шәһәрдә сатыб китә торган булганлар. Шәһре Болгар булган олуг юлның берсе әнә шушы шәһәрдән узыб, шәһре Болгарга бара икән.

Шундан соң Төгәлбәй картлары бу шәһәрнең зиратына изге хатынлар күмелгәнлеге, бу хатынларның шәһре Болгарда икенде намазын укыб, ахшам намазын укырга хуҗалар тавына барыб җиткәнлекләрен, мона бу Төгәлбәй янындагы шәһәрнең зияраты булган каберстанга әнә шушы изге хатыннарның шәһре Болгардан хуҗалар тавына барганда вафат булыб, шунда күмелеп калуларын, шуның эчендә халык хәзерге заманда да бу кадими зиярәткә – «Изгеләр өсте» каберлегенә – һаман да барыб зиярәт иткәнләрен сөйлиләр...

*53 ф., 1 тасв., 58 сакл. бер.*

*Текстны гамәлдәге язуга күчереп, басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәс сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре Венер Усманов әзерләде*

**С. Вахидинең 1934 елда Әтнә районына оештырылган археографик экспедиция турында истәлекләре**

Әтнә Казандан 55 чакрымлар чамасы җыраклакда, хәзерендә урмансыз, сусыз яланда утыра. Аның урыны күңелле түгел. Ләкин әйләнәсен шактый якындан чолгап алган татар авыллары аңа ниндидер шәһәрлек-мәркәзлек хосусияте биреп, аның урынының әһәмиятен артдыралар.

Халыкның тормышы йорт һәм йорт җиһазлары, кием-салым, хатын-кыз әйберләре – барысы да шәһәрчә. Әтнәнең янмый калган өлеше үзенең корылышы ягы белән урамларның тар вә төрле якларга таралыб китүләре, хәтта кайберләренең ишек алдына барып кереп чикләнүләре кебек аерым хосусиятләре белән дә ниндидер бер борынгы шәрык шәһәрен искә төшерәләр. Әтнәдә татар этнографиясе өчен бик күп материаллар табып була. Гадәттә өйләр урамдан берничә сажин эчкә кертеп салынып, өйләрнең урам ягы, капка белән беррәтдән, койма белән уралып алынган була. Өй белән урам өсте коймасы арасы бакча була. Әгәр дә бу авылдан тимер юл сызыгы үткән булса иде, ул чакта бу авыллар шәһәр булып киткән булыр иде. Әгәр дә Әтнәнең байлары Әтнәдән Казанга иске чакларда тар юллы тимер юл эшләтеп, вак кустарьчылыкдан эре промышленник булуга бару кебек завод-фабрикаларда машиналаштыруга күчкән булсалар да, балаларын гали мәктәпләрдә укытып, шушы Әтнәнең үзенең урта мәктәбендә хисап һәм икътисад белгечләре курслары, һөнәр мәктәпләре ачып, шәрыкдан гаребкә таба йөз тотып, Яурупача тору, Яурупача эш итү, Яурупача баю юлына кергән булсалар, Октябрь инкыйлабына бөтенләй башка бер халык булып кергән булырлар иде. Бу авылларда кулаклык җәфасына да дучар булган агай-энеләр урынына меңләп эшче хәзерләгән булырлар иде. Агай-эне мәгърур булып, үзенең наданлыгында, кирелегендә үзен танымаучылык авыруы белән мөбталә булып, тәгассыб вә кирелегендә яшәүне табигать итеп алу авыруындан да котылган булыр иде.

Тузан чаклы эшчәнлек, тау чаклы мактанып, надан мулла-мөзинләрнең үзләренә дә ярамаган кыек фикер, ялгыш карашларына кол булып, үз-үзебезне наданлык, караңгылык бәхетсезлегенә ташлаганыбызны тоймыйча да калганбыз. Бу халык арасында бер карау белән зур гына истигъдадлы[1] егетләр, кызларны очратып

[1] Истигъдадлы – сәләтле.

була. Болардан зур гына талантлар чыгуына нык иман белән карау бер дә ялгыш булачак түгел дип беләм. Авыл шурасы күмәк хуҗалык идарәсендә, шулай ук район мәркәзе мөәссәсәләрендә[1] чабаталарын чишенеп, ботинка киеп, хәзерендә кайберләре әле дә чабатадан эшләп утыручы егетләр һәм кызлар югарыда сөйләгән сүзләрне көчәйтүче җанлы дәлилләр булып торалар. Шул ук егетләр исәп-хисап эшләрен, бөтен финансын һәм икътисад эшләрен алып баралар. Эшләгән чакларында карап торсаң, гаҗәп пөхтәлек, иплелек һәм чыгышлы итеп алып бару юлы күзгә бәрелә. Элек-элекдән укымыш күргән булса, болардан әллә ничаклы профессорлар җитешер иде. Безнең авылларыбызда чабаталар өстендә, тупый бүрек астында, сары тун яки тула чикмән эчендә әллә нинди даһилар мәктәп юлына кермичә, үзләренә тиеш юлны, тиеш эшне сайлап ала белмичә, үзләренең истигъдадларына карап эш итүнең кирәклеген төшенмичә, белгечлек алудан мәхрүм булып, тузан-тупрак астында капланып, тормышның дуамаллык һөҗүме астында капланып кала баралар...

Инде хәзер аларның күбесе күмәк хуҗалыкка кереп алып, ныклап эшкә керешкәнләр. Советның Октябрьнең алар өчен нинди файдалар биргәне һәркемдән алда төшенгәнлекләре, октябрьнең алар өчен булганлыгын аңлаганлыклары, аларның күмәк хуҗалык эшенә актив катнашуларында ук күренеп тора. Инде хәзер Әтнәдә берничә мәктәпләр ачылып, уку-укыту эше акрынлап юлга салынып бара. Мәгәр бу авылда су юк, халык суны коелардан алып истигъмаль итә. Инеш суы начар, кечкенә, җәй көне су коену өчен читкә – Кайсар дигән җиргә – Әтнәдән 4 ярым километр чамасы ераклыкда булган урынга барырга кирәк.

Без Әтнә авылында борынгы кабер ташларын тикшереп укып чыгудан Әтнәдә нинди китаплар, нинди кульязмалар, нинди документлар бар – барын да җентекләп тикшердек, өйрәндек. Әтнәнең иске зиратында Казан ханлыгы заманындан калган байтак кабер ташлары бар. Аларның бик мөһимләре дә бар. Алар турында без инде алда язып узган идек. Хәзер ул турыда артык тукталуны тиеш күрмибез.

Әтнә авылында тикшерү эшләребезне бетергәч, Бәрәскә авылына китдек. Чөнки безнең маршрутыбыз шулай иде. Югары Бәрәскәгә барырга юлга чыктык. Бу вакытлар коры, яңгырсыз

[1] Мөәссәсә – оешма.

вакыт булганга, төнлә белән юлда барганда безнең арткы һәм алгы якларда ниндидер авыллар яна иде. Аларның януыннан хасил булган ялкын яктылыгы асманга күтәрелеп, ай чыгып килгән вакыттагы шикелле яктылык күк йөзендә хасил булган иде. Без юлда барганда әллә ничә урында күмәк хуҗалык басуларын саклаучы сакчыларның кибәнләр, саламлар һәм башка ашлыкларны саклап йөргәнләрен күрдек. Алар үзләренең эшләрендә бик уяу күренәләр. Юлда барганда байтак санда очраган бу сакчыларны утырып торган хәлдә очратмадык. Барысы да кулларында мылтыкларын, һәр куркынычка таяр итеп тотып йөреп торган хәлләрендә очратырга туры килде. Төн урталарында басулар аркылы сузаеп киткән авыл араларындагы басу юлларыннан атка утырып йөрү безгә күңелле генә булды. Без Югары Бәрәскәгә төн уртасында караңгыда барып кереп, авыл шурасының ярдәме белән бер карт белән карчыкның йортына урнаштык. Бу кешенең өендә кандала һәм таракан кебек хәшәрәтләр булмаганга күрә, бик тыныч, рәхәт йокладык. Гадәттә, авылларда бу хәшәрәтләрнең җәфасын күп татырга туры килүчән була. Монда алай булмады.

### Югары Бәрәскә

Югары Бәрәскә – матур гына, зур гына бер татар авылы. Йортҗирләре төзек һәм бай гына булып, урамлары да төп-төз генә бер авыл. Кайчандыр бу авыл тагы да бай, тагы да төзек булган икән. Мондагы халыкларның сөйләвенә караганда, Югары Бәрәскәдә борын-борындан бик зур байлар булып, аларның кытат[1] фабрикалары, күн заводлары һәм зур-зур тегермәнләре булган. Бу авылның халкы мәзкүр завод-фабрикаларда эшче булып эшләү белән көн итеп килгәнләр. Борынгы татар эшчеләренең тормышларын, ул чордагы завод-фабрикаларның тарихларын, алардагы коралларны, эш алып бару әсбаблары һәм станок кебек әйберләрнең татарча исемләрен өйрәнү ягыннан бу авыл бик мөһим бер авыл икән. Югары Бәрәскәдә бик иске замандан бирле яшәп килгән бер таш мәсҗед булып, аны соңгы елларда гына ватып эшдән чыгарганлар. Аның ташларын алып бетерә алмаганлар, тик ватып-җимереп харап итеп эшдән генә чыгарганлар. Хәлбуки, бу мәсҗедне бер дә ватмыйча, җимермичә асдагы катын таш склад итеп (гаять нык эшләнгән склад булган), өстен я мәктәп яки клуб өчен бер бина

[1] Кытат – тыгыз ефәк тукыма.

итеп истифадә итәргә[1] мөмкин булган. Мәзкүр мәчетнең чормасындан гасырлардан бирле җыйналып килгән (авыл халкының әйтүенчә) өч ат йөге кулъязма китаплар һәм төрле хатлар, архивлар булганлар. Мондан ике ел алдан мәчетне ваткан вакытда бу кирәкле булган тарихи әсәрнең күлләре күккә очып юкка чыкканлар. Без ныклап тикшергәч, берничә пот китапның иске зиратка илтеп күмелгәнлеген сөйләделәр. Китапларны җиргә күмү вакыйгасының булганлыгы миңа инде элекдән үк мәгълүм иде. Югары Бәрәскә авылында китапларны җиргә күмү вакыйгасын күз белән күрү өчен без берничә кешене кулларына көрәкләр тотдырып, әлеге зиратка алып китдек. Анда үз күзебез алдында бер чардуганны казытып карадык, ләкин бер нәрсә дә чыкмады. Икенче чардугандан берничаклы җирне казыткач, черегән китаплар килеп чыкдылар. Бер биш кадак чамасы (ике кило) авырлыгындагы череп балчыкка әйләнгән, шулай да кулъязма икәнлекләре әле тәмам беленмәслек хәлгә килеп бетмәгән шушы китапларны «Фәнләр академия»сенә җибәрдек. Шул ук иске зиратда Югары Бәрәскә авылындагы югарыда күрсәтелгән мәсҗедне салдыручы – Ибраһим бине Йосыф Бәрәскәвинең кабере һәм шул кабер өстенә куелган таш бар. Мәзкүр ташның җир өстендән озынлыгы 11 сөям[2], киңлеге 4 сөямдән 4 вершок ким булып, калынлыгы бер сөям. Төбенең калынлыгы җиде вершок. Бу ташда барлыгы 11 юл язу булып, юллары татар рәсме хатты белән язылгандыр[3]. Бу ташның бизәкләре Казан-Болгар ханлыгының бизәкләренә башка. Бу таш турында кечкенә бер изах: өченче юлда вәл-икрам сүзе «вәликрам» сурәтендә тоташ язылган. Шул ук 3 нче юлның ахырында «калә» сүзендән соң «ا» хәрефе аерып алып, язу кагыйдәсенә хилаф уларлык берүзе генә шул юлның азагында калдырылган. 4 нче юлда беренче сүз итеп «ән-нәби» сүзе «ا» хәрефендән башка гына язылган. 7 нче юлда: Ибраһим бине Йосыф Бәрәскәи дип «ی» хәрефенең астына ике нокта куеп язылган. Әмма «Бәрәскәви» түгел. «вау» белән язылмаган. Мәзкүр Ибраһим бине Бәрәскәви, заманында зур байлардан булып, халыкның әйтүенә караганда, аның зур-зур фабрикалары булып, анда бөтен Бәрәскә авылы эшче булып эшләгән. Халык ул кешене бик мактап, бик яратып, сагынып сөйлиләр. Ул халык

[1] Истифадә итәргә – файдаланырга.

[2] Сөям – 17,7 см.

[3] Истәлектә ташдагы язулар тулы килеш китерелә.

каршында зур хөрмәт белән яд ителә. Ул кеше (Ибраһим) халык каршында яхшы исем (авторитет) казанган. Бу байның Әшиасты тегермәне урынында кап суга торган фабрикалары да булган икән. Анда бик күп халык кап сугу эше белән мәшгуль булганлар. Сүтелгән таш мәсҗедне халык бик кызганып сөйли, ул мәсҗед Казан мәсҗедләрендән дә алда салынган иде, диләр. Бу турыда алар күп сүзләр сөйлиләр. Риваятьләргә караганда, Югары Бәрәскәдән өч чакрым төн ягында тау башында Кала тау дип атала торган бер тарихи урын бар икән. Бу урында халык әйтүенчә, борынгы заманда хан булган, хан шунда торган дип сөйлиләр. Халыкның риваятенә караганда, соңындан хан бу урынны яратмыйча анда су да юк, дип хәзерге Идел буена – Казанга күчеп киткән икән. Шактый соңгы елларга чаклы халык бу урынга барып, зиярәт итеп йөри булган. Ул урынны изгеләр урыны итеп йөреп хөрмәт иткәнләр. Анда әле каралты урынлары да булган һәм тирә-як халкы хәзерендә дә шунда зиярәткә баралар икән.

Югары Бәрәскә авылында безгә шул авылда мөһим тарихи әйберләрдән хисапланган зур агач чүмеч бирделәр. Бу чүмечнең сабы ярты сажин чамасы булып, калынлыгы һәм көрәк сабы кебек. Ә чүмечнең башы зур табак чаклы. Бу зур чүмеч юкә агачындан, юкәнең бер дә ярылмый торган могылындан ясалган.

Халкының сөйләвенә караганда, борын заманда бөтен авыл белән җыелып зур бер халык бәйрәме – халык тантанасы яки келәү бәйрәме уздырганда авылның читендә зур казанларда пешерелгән ашлардан җыелган халыкка шушы зур чүмеч белән берничә кешегә берьюлы ризык өләшә булганлар. Чүмечне Югары Бәрәскә авылының Уразай исемле бер кеше ясаган икән. Безгә бу чүмечне Хөснетдин Кадыйр углы дигән бер авыл кешесе китереп күрсәтде. Хөснетдиннең шәҗәрәсе үзе әйтүенчә болай: Хөснетдин Кадыйр углы, Кадыйр Латып углы, Латыйп Ваһаб углы, Ваһаб Мостай углы, Мостай Уразай углы, Уразай Әтнаш углы.

Димәк, Хөснетдин, Кадыйр, Латыйп, Мостай, Уразай, Әтнаш. Болар эчендә Ваһаб йөзгә җитеп, озын гомер итеп үлгән. Атнаш, Байҗегет, Таңчулпан – болар барысы агай-эне була.

Болардан Атнаш Бәрәскә авылын, калганлары «Көек» белән «Каенсар» һәм «Әшиасты» авылларын нигезләүче берничә балалардан булганлар. Мәгәр кайсы бабай кайсы авылны нигезләвен инде хәзерге буын авыл кешеләре хәтерләп бетерә алмыйлар. Бу авылда борын чакларда төрле фабрик һәм заводлар күп булып,

бөтен авыл халкы шул завод-фабрикаларда эшләп килгәнләр. Элек-элекдән эшче булып килгән бу авыл татар эшчеләренең тарихын өйрәнү ягыннан бик мөһим урын тотарга тиеш. Бу тирәдә Бәрәскәдән ерак түгел, мәсәлән, «Байчыга» исемендә бер урыс авылы бар. Бу авылның урыслары да элекдә татар байларының күн заводларында эшләп килгәнләр икән.

Без Югары Бәрәскә авылында күп кенә кулъязма китаплар, документлар тапдык. Югары Бәрәскәдә табып алган бөтен китапларны, кулъязмаларны махсус ящикларга тутырып, ат белән Казанга озатдык.

Казаннан Ленинградка җибәреләчәкдер.

Югары Бәрәскә авыл шурасына җыелган халык «хәзерге газеталарда бик күп урыс сүзе язалар, телне бөтенләй бозып бетерделәр» дип, безгә шикаять итеп сөйләделәр. 29 нчы елда Казанда басылып таратылган бер китапны алып килеп, «менә бу китапны без таныймыз, моның теле безнең телебез, ә менә бу елгы гәҗитләр, бу елгы китаплар чат урыс сүзе белән язылып, безгә аңлашылмый торган җөмләләр белән тулган, бу татар гәҗите түгел, белмибез, шунда әллә керәшенләр өчен чыкганмы юк исә» диләр. Алар бездән мөмкинлек бар икән, сез булышлык итеп телне бозудан туктатып калдырырга, без күмәк хуҗалык крестьянлары (колхозчылар) аңларлык гәзит чыгартырга үтенеч ишетдерделәр. Аларга без бу эшнең безнең эшебез түгел икәнлеген сөйләп, төшендереп китдек..

Аларның бу турыдагы моң-зарлары бик зур, бу турыда авыл халкы кемгә мөрәҗәгать итәргә дә белмиләр. Алар инде телнең бозылуындан бөтенләй гаҗиз калганлар.

### Киме авылында

Югары Бәрәскәдә эшләребезне бетергәндән соң, «Күлле Киме» авылына ат белән китдек. Юлда безгә болынны үтеп, Ашыт суын чыгарга туры килде. Ашыт суының кичү урыны турындагы тегермәне вәйран булганга күрә, Ашыт елгасы аркылы салынган күпер дә беткән икән. Безгә шактый читенлек белән елганың саерак бер урыныннан су аркылы кичеп чыгарга туры килде. Кичү урынында елганың теге якдагы яры да шактый текә булып, ат белән күтәрелеп менү дә шактый читен булды. Әгәр дә кичкә калынса, бу суны кичү һич мөмкин булмаячагы безгә аермачык беленде. Кичү урыныннан бераз гына сулга ялгышып, әйтик бер сөям чамасы ат сулга атлап китсә, ат-арбалары белән

чумып һәлак була торган тирән чокыр бар икән. Без юлда Әшиасты авылыннан аркылы үтеп китдек. Бу авыл ярлы, надан бер авыл икән. Монда безгә тарихи нәрсәдән бер әйбер дә бирә дә һәм күрсәтә дә алмадылар. Бик томана авыл икән. Уку-язу, аң-белем эше Әшиасты авылында борын-борыннан булмаганлыгын сөйләделәр. Анда без озак туктап тормадык, тиз үтеп китдек... Киме авылына барып кергәндә көн шактый караңгылана башлаган иде. Киме төзек, бай, күңелле бер татар авылы. Күмәк хуҗалык да бай һәм эшлекле күренә. Риваятьләргә караганда Киме авылы иске заманда Казанга бик якын бер урында булган. Киме авылы Казанга якын бу урында булганда аның болыны, суы, урманы күп булып, басулары, үсдерүче мал-туарлары бик үрчемле һәм күп булган. Бу авыл ул чакда бик төзек бер татар авылы булган. Ул чакларда бу авыл Бәерле дип аталган икән. Бәерле, риваятьләргә караганда, Казан шәһәре белән бик нык элемтә тоткан вакытда, бу авыл Казан белән һәртөрле сатып алу мөнәсәбәтләрендә булып, сугыш вакытларында шәһәргә азык-төлек, гаскәргә атлар хәзерләү белән булышлык иткән диләр. Бәерле сүзе кайдан чыккандыр, ул ни дигән сүз, аны белүче булмады. Әлегә Бәерленең ул урындан күчеп китүе Казанны урыслар алгандан соң, Иван Грозный боерыгы белән Казан тирәсендәге татар авыллары сөрелеп җибәрелгән чорларда куылып, таланып җибәрелгән бер авыл дип, безгә картлар сөйләделәр. Габдрахман Арсланов һәм Дәминовларның риваятьләренә караганда, Бәерле авылыннан хәзерге Киме авылына иң элек күчеп килгән кеше «Иртуган» баба булган. Аның улы Шәмсетдин, аның улы Туемчы булган. Туемчының дүрт улы булган. Аларның берсе Арыслан, икенчесе Ибраһим булган. Калганларын исемләре белән әйтә алмадылар. Боларның барысы шәҗәрәдә бар иде. Аны табып булса карарбыз, диде Габдрахман Арсланов. Арслан баба Бәрәскәдә мулла булган ди.

Киме авылы патша заманында ук җәдид мәктәпле, аң-белемле матур һәм төзек, нык тормышлы бер татар авылы булып яшәп килгән. Бу авылда Сибгатулла хәзрәт дигән атаклы бер мулла яшәп, шушы кеше халыкны яхшы ук рәткә, җүнгә керткән диләр. Аның улы Габдрахман мулла да уку-укыту эшендә дан тоткан, мәгариф сөюче, туры фикерле бер хәзрәт булып яшәгән. Габдрахман хәзрәт нигезләгән җәдид мәктәбе бу авылда бик күп аңлы егетләр, истигъдадлы күп кенә эшчеләр биргән икән. Бу көндә дә Габдрахман хәзрәтне аның мәгарифкә булган хезмәтләре белән

искә алып сөйлиләр. Габдрахман хәзрәт безгә зур гына булышлыклар эшләве белән бергә шактый мөһим генә гыйльми нәрсәләрне эченә алган күп кенә кулъязма китаплар, документлар бүләк итде. Без аның бу эшләре өчен Академия наук исемендән рәхмәт кәгазе биреп калдырдык. Ул безгә мондан соң үзендә калганларын да бөтенесе белән, үземдән Академия наукка бүләк итәчәкмен дип вәгъдә итде.

Киме үзенең төзеклеге, байлыгы, халыкның аң-белем һәм шомалык яклары белән башка гади авыллардан аерылган шикелле, бүгенге көндә урта мәктәп, үзендән зур гына санда эшчеләр чыгаруы белән байтак татар авылларындан аерыла. Киме авылының мәктәбе тау башында, саулык саклау ягындан да яхшы ук мөкәммәл итеп эшләнгән. Бу мәктәп янында тулай торак да бар. Башка авыллардан килеп укучы кыз һәм ир балалар шушы тулай торакда торып укыйлар. Шулай ук аларны анда ашау-эчү белән дә тәэмин итәләр икән.

Киме мәктәп укытучыларындан безгә кулъязмалар бирүче һәм тел мәгълүматлары бирү белән безгә булышлык итүчеләр булды. Без эшебезне бетергәч, Киме авылында кулыбызда булган кулъязма һәм документларыбызны ящикларга тутырып, Казанга озатдык. Киме авылындан Иске Өҗем авылына китдек. Өҗем авылына барганда без Иске Тазлар авылына туктап, тарихи мәгълүматлар сорашып, андан Габбасов Габдулла дигән, элек-элекдән имамлар нәселендән килгән бер егетдән 32 данә кулъязма китап, 15 данә басма китап бүләк кабул итеп алдык, аңар бу бүләк өчен рәхмәт кәгазе бирдек. Бу авылларда халык җыелып, иске китапларны ни өчен җыялар икән, бу боларга нигә кирәк икән, аларны җыеп яндырмакчылар микәнни, фәлән микән, төгән микән дип бик гаҗәпсенеп, безнең ящикка китап тутырган чагыбызда кооператив кибете янында җыелып, без шундан ящик алып китаплар тутырганда сәгатьләр буена сөйләшеп, хәйран булып тордылар. Арадан кайбер батырраклар: «Элек бетерделәр, инде үзләре эзләп акча тотып җыеп йөриләр» – диде... Эшләрне бетергәч, без Иске Өҗем авылына китдек.

### Иске Өҗем

Иске Өҗем авылы да зур, матур, төзек һәм күңелле бер татар авылы. Урамлары, каралтылары, йорт-җир һәм бакчалары – барысы да буын-буыннан татарның этнограф аерымлыгын эченә алган бер карау белән, аерым бер зәвык, аерым аһәң, аерым бер

хозур тудыра торган тарызда эшләнгәннәр. Заманында бу авыл җәй көне сайфия[1] итеп торырга мәгъкуль булган татар авылларының берсе булган.

Халкы шома, сүзгә дә чибәр генә, осталар, кием-салым шәһәрчә булган, халкы элекке чакларда сәүдә белән шөгыльләнгәннәр.

Иске Өҗем авылының салыну һәм башлап корылуы турында мондый риваятьләр бар:

Кайбер авыл картларының сөйләвенә караганда, Иске Өҗем авылы шәһри Болгардан күчеп китеп утырган Идел буе болгар бабалардан үрчегән булганлар икән.

Кайбер агай-эненең сөйләүләренә караганда борын-борыннан Идел буе болгар бабайлары торган Өҗем авылына Өмбе авылындан берничаклы күчеп килеп кушылган икән. Өченче риваять болай:

Шәһри Болгар заманасында ук бу тирәләрдә, ягъни Өҗем авылы тирәләрендә Идел буе мөселман болгарлары яшәп килгәннәр. Мөселман болгарлар бу җирдә бик матур, тук һәм бай яшәгәнләр. Аларның басулары һәртөрле иген-тару белән, урманлары һәртөрле җәнлекләр, кош-корт һәм һәртөрле урман хайваннары белән туп-тулы булган. Бу чакларда балык, сусар бик күп булган. Һәрбер тырыш гаиләнең әллә ничәшәр баш умарталары, кайбер хәлле кешеләрнең хәтта меңәрләп санала тооган күп умарталары булган. Йорт хайваннарыннан ат, сыер, сарык, йорт кошларыннан каз, үрдәк, күркә исәпсез булган. Халыкда әхлак иң төзек булган. Урлау-талау, үтерү кебек хыянәт эшләрне белмәгәнләр. Болар җәннәтдә яшәгәнләр.

Бу илдә яшәүче болгар-мөселманларының рәхәтдә яшәүләре чит илләргә дә җәелгән, ди. Боларның күршеләрендә яшәүче урыслар бу тирәдәге халыкның рәхәт тормышын дастан итеп сөйләп, бу як илне җәннәт җире дип мактап, кызыгып сөйли торган булганлар имеш. Шуңар күрә бу ил урыс каракларының чапкынлык итүләренә сәбәп булган икән. Кайчандыр бер вакытда күп сандагы урыс баскаклары бу якка Нократ-Идел ягыннан килеп чыгып, бу тирәдәге болгар мөселманларының мал-туарларын, хатын-кыз, бала-чагаларын тоткын иткәнләр, ди. Урыс каракларының баскаклык, талауларыннан гаҗиз калган булганлар. Казан ханына илче йибәреп, бу баскаклардан котылдыруны үтенгәнләр, ди. Казан ханы һөҗүм белән ул явызларны илдән сөреп йибәрегез дип, зур

[1] Сайфия – дача.

чирү йибәргән, ди. Хан чирүе беренче көчле һөҗүме хәзерге Өҗем авылы утырган җирдә ясаганлыкдан, бу авыл Өҗем «Һөҗүм» дип аталган имеш.

Кайберләрнең әйтүләренә караганда, хан гаскәрләре урыс баскакларын тар-мар итеп бетергәч, дошманны җиңү шәрәфәтенә бу авыл корылып, шул авылны «Һөҗүм» дип атаганлар имеш.

Иске Өҗем авылында Иске Казан ханлыгы заманындан калган борынгы кабер ташлары бар. Без бу кабер ташларын барып тикшердек – тарих тугыз йөз ун, тарих тугыз йөз һиҗридә язылганлар. Бу ташларның берсе әле үзенең бөтенлеген югалтмаган. Башкалары инде таушалган, уылган һәм кайберләре инде ватылганлар да. Сакланып сау калган ташның нәкышьләре, кашкасы Казан дәвере кабер ташларында җыш очрала торган нәкышьләр, кашкалар.

Сау килеш әлегә чаклы сакланып калган ташның арт ягында: «Бу ләүхәне Солтан Дәүләт бина кылды» дип язылган. Ташларның телләре саф татарча.

Икенче бер ташның арт ягында: Бу ләүхәне энесе Чынбулат бина кылды» дип язылган. Тагын бер ташның артында каз аягы төсле, ягъни каз аягы яфрагы төсле яфрак тамга бар. Бу кабер ташының тарихы болай языла: «Тарих мең ел узып ун сикездә мөбарәк зөлхиҗҗә аенда...»[1]. Безнең тикшерү нәтиҗәләренә караганда, бу Иске Өҗем авылы каберстанында барлыгы җиде борынгы кабер ташы бар. Барысы да Казан ханлыгы дәвере кабер ташлары.

Безгә сөйләүләренә караганда, Иске Өҗем авылында элек-электән берничә нәсел олыларында байтак кулъязмалар сакланып килгән икән. Нигъмәтҗан Галиәкбәр углы дигән кеше кулында Иске Өҗем авылының тарихы булган. Әлегә без бу китапларны таба алмадык. Бу тарих китабын элегрәк чакларда кулдан-кулга йөртеп укыйлар, укый белмәгәнләр белгәнләрдән укытып, тыңлап файдалана иде дип безгә сөйләделәр...

Бу авылда Мәрьям Төхвәтуллина дигән бер ханым безнең аркылы Академия наукга күп кенә тарихи әсәр бүләк итде. Шул авылда укытучы Кашшаф Шәмсетдинов һәм аның хатыны да берничә кулъязма бүләк итде

Бу авылда татарның борынгы мигъмарчылык[2] сәнгатен өйрәнү ягыннан мөһим урын тоткан борынгы аерым бер ысул да,

---

[1] Дәвамы язылмаган.

[2] Мигъмар – төзүче.

урыс авылларында яки урыс авыллары арасында катышып яши торган татар авылларының берсендә дә күренми торган тарызда бөтен аерым бер төзелешдә, корылышда булган бик күп йортлар, каралтылар бар...

Шушы зур тупракда сакланган язма һәм мадди материаллар тикшерелеп, өйрәнелеп бетмәгәндә безнең тарихыбыз тикшерелгән, өйрәнелгән дип уйлау хата булачак. Моңа чаклы тикшерүләр эле киләчәкдә дәвам итдерелергә тиешле олы вә киң күләмдәге тишерүләрнең башлангычы гына. Табылган, җыелган хатирәләр җыелырга, табылырга тиешле тарихи хатирәләрнең диңгездән тамчысы, таудан тузаны гына дип карарга тиешле. Әгәр дә без чын күңел белән, керсез күңел белән эшкә бирелеп, эш ягындан мәсьәләгә якынаюны үзебезгә дөрест максат итеп алсак, шапырыну, мактануны әмәл итеп алучылар өчен билгеле бу сүз сөйләнми. Аерымачык кына хакыйкать шушы әле без үзебез дә, безнең өчен читләр дә тарихи материалларны җыю, алардан файдалану һәм файдаландыру, аларны гыйлем дөньясына чыгару вә киң эшләрне эшләүдә, шул эшкә керешергә кызыкдыручы адәм булудан артык эш эшли алганымыз юк. Башкалар инде: кеше эше кештәкдә итеп кенә эшләгәнләр.

Бу эшне үзебезнең яшь көчләр, гыйльми көчләр җиң сызганып тотынып киң күләмдә эшкә алып чыгарга кирәк. Безнең киләчәгебез шушы гыйльми вә тарихи материаллар белән шактый нык нигезгә корылачак. Тарихыбызны яхшы белү, тарихи, сәяси ялгышларыбызны төзәтү, бар эшне гыйльми нигезгә корып, заманның иң соңгы фәне сөйләп биргән тарызда нык хәзерләнү белән генә булачак бит.

*С. Вахидинең әлеге истәлек дәфтәре – «кыр» көндәлеге Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана (53 ф., 1 тасв., 63 сакл. бер.). Язмалар татар телендә гарәп графикасында С. Вахиди кулы белән язылганнар.*

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре Ләйлә Гарипова әзерләде*

**Татарстан Гыйльми Үзәк рәисе иптәш С. Атнагуловка[1]**
**С.Г. Вахидидән**
***доклад.***

Шушы 1929 елның ноябрь 2 ендә сезнең телдән биргән рөхсәтегез буенча мин Гыйльми Үзәкнең «кулъязмалар саклана» дип миңа күрсәтелгән бер шкафны карап, тикшереп чыкдым, борынгы әсәрләр табылмады. К.Насыйри әйберләре юк икән. Алматадан килгән хат буенча эзләгән документ соңында, сорашып алынган мәгълүматларга караганда, инде архивка бирелгән булырга кирәк. 1925 елга чаклы бөтен архивлар Татархивка бирелгәннәр икән. Мин барлыгы биш-алты төргәк (бәйләм) кулъязмаларны, ул шкафдагы барлык басма һәм берничаклы аерым кәгазьләрне тикшереп, карап чыктым, нәтиҗәләр болай:

1. Басма китаплар, минем аңлавымча, күбрәк шәех Хәмидинең өендән чыккан, зур әһәмиятләре булмаган, гарәп вә фарсы телендәге дини әсәрләр. Шулар эчендә мөһим – Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар», 1 җилд күренмәде, әмма 2 җилд да бар. Тагы берничаклы әһәмияте зур булмаган басма китаплар бар.

2. Берничә зур төргәкдә Гыйльми Үзәккә төрле вакытда, төрле каләм ияләре тарафындан басылырга тәкъдим ителгән әсәрләрнең кулъязмалары, болар эчендә гаять мөһим әйберләр бар. Болар күбәүләр, бу хәзинәләр, минем фикеремчә, нык тәэмин ителгән чаралар күрү белән сакланырга тиешләр.

Мин тәкъдим итәр идем болай: басылмый калган бөтен язмалар музей янындагы «Кулъязма һәм документлар бүлегенә» бирелеп, шунда саклансыннар иде. Киләчәкдә мәзкүр кулъязма һәм документлар бүлегенең ничек булырга һәм ничек куелырга тиешлеге турында минем бер пректым бар. Анда бу турыда тәфсилле туктадым. Һәрничек безнең яшь язучыларыбызның каләм хезмәтләре инде мотлакан, сакланырга тиеш. Без бит Тукайның оригиналларын табып бетерә алганыбыз юк, Гафур Коләхмәтов әсәрләрен ничек эзләп табарга белгән юк. Болар безгә мондан соң бөтен язучының кулъязма әсәрләрен нык саклаулы урынларда асрауның кирәклеген таләп итәләр. Бу эшкә керешергә инде бик вакыт җитде дип беләм. Бу урын, минемчә, бары музей янындагы «Кулъязма һәм документлар бүлеге» генә була ала.

[1] Сәләх Атнагулов (1893–1938) – сәяси эшлекле, язучы. 1927–1929 елларда Гыйльми Үзәк рәисе.

3. Шагыйрь Гали Чокрыйның басылган һәм басылмаган әсәрләре. Болар байтак зур төргәкдә булып яталар. Монда Гали Чокрыйның гомер буена язган бөтен язмалары бар дип әйтерлек дәрәҗәдә күп язма материаллар бар. Бу чаклы күп язма материаллар булып да, Гали Чокрый турында моңар чикле язылган әсәрләр дә аз, сыек һәм канәгатьләнерлек бер әйбер язылмавына, боларны тикшергәч, мин бик гаҗәпләнәм. Бу материаллар шагыйрь Гали Чокрыйның ничаклы шагыйрь, ничаклы язучы булганлыгы, шулай ук аның идеология ягын да күрсәтүдә бик мөһим урын тотарлар. Бу мөһим материаллар моңар чикле берәү тарафындан тикшерелгәнләрме, юкмы. Ул турыда мин тикшергән матеиаллар арасында бер төрле дә язу-фәлән, гомумән, шкафдагы кульъязмаларның тәртипкә салыну һәм саклanулары мактанырлык түгел. Боларның каталогы яки бу мөһим әйберләрнең, һич булмаса, теркәлеп барыла торган бер документлары булырга тиеш иде. Гали Чокрыйның ике кисәк кульъязмасын аерып, әлеге төргәкнең тышына куйдым, уйлаган идем шул ук вакытда сезгә доклад ясармын һәм аларны сезгә күрсәтермен диеп, сез китеп баргансыз икән. Бу төргәкләр эчендә Г. Чокрыйның тәрҗемәи хәле белән бергә, барлыгы басылган һәм басылмаган кульъязма материаллар 20 дән артык саналадыр.

Кирәк булганда Г. Чокрый турында доклад бирергә мөмкин. Монда эзләп таба алмаган документны әгәр дә Татархивтан эзләп тапсам, сезгә шул турыда язып белдерермен. Мәгәр, Татархивның күчүе белән минем бу эшемә бераз комачаулык итәр дип уйлыйм.

Соңгы сүз, мондан соң безнең язучыларыбызның бөтен кульъязма әсәрләре саклана торган рәсми нык саклык чаралары күрелгән махсус бер мөәссәсә[1] булырга тиеш. Ул мөәссәсә, минечә, музей янындагы «Кульъязма һәм документлар бүлеге» булырга тиеш. Юкса, гади кәгазьләр рәтендән шкафдагы «мөһим кәгазь төргәкләре» ауналу өстендә юкка чыгу ихтималлары бик мөмкин, бу мөһим әсәрләр саклана торган шкаф бик гади, аның өстендәге йозагы да саклык вазыйфасын үтәүдә канагатьләнерлек түгел. Сакчы белән күзәтчелек тәэмин ителмәгән. Болар, һич булмаганда, чуен сандык эчендә Гыйльми Үзәк рәисенең үз бүлмәсендә сакланырга тиеш иде. Әйткән рөхсәтегез миндән әлеге казыну һәм тикшерену

[1] Мөәссәсә – оешма.

эшемдән кечкенә генә булса да хисап бирүне сорый дип белеп, бурычымны үтәү өчен шушы кечкенә докладны сезгә тәкъдим итеп, хөрмәт белән: С. Вахиди (Вахидов).

Казан, 1929 ел, 3 ноябрь, якшәнбе көн.

*53 ф., 4 тасв., 1 сакл. бер.*

*С. Вахидинең С. Атнагуловка хисап-хаты татар телендә гарәп графикасында язылган. С. Вахидинең үзе төзеп калдырган җыентыгына кертелгән.*

## К изучению ярлыков татарских ханов

Ярлыки татарских ханов имеют весьма важное значение как единственный достоверный источник при изучении внутреннего государственного устройства и культурное состояние татарских ханств, а также и финансово-экономического и юридического положения, при чем также их политических связок с другими государствами и при изучении как официального татарского языка, так и историю классов татарского феодализма за то время.

Несмотря на важности этих ценных в научном отношении памятников интерес к их изучению занимает определенное место лишь в начале XIX столетия. До этого времени интересующихся и занимающихся изучением ярлыками татарских ханов а также определенных высказывателей их научного значения не было.

Вообще официальные письменные памятники тюрских народов до указанного времени почему то не было известно ни русским, ни европейским ученым, также не было ни одного ученого, который бы вздумал занятся отысканием изучением и изданием этих важных исторических памятников.

Известный тюрколог того времени проф. В.В. Григорьев в своем ученом труде «Ярлыки Тохтамыша и Сает-Герая» относительно этого вопроса пишет следующее: «С памятниками официальной письменности этого племени столь исторического ученый мир знаком еще менее, или точнее сказать, почти вовсе не знаком. Ни из русских, ни из заграничных ориенталистов до сих пор еще ни кто, сколько мне известно, не вздумал занятся отыскиванием, собиранием и изданием в свет дипломатических, юридических в

другого рода актов, получивших существование в изчезнувших уже и еще бытие ханствах Тюрских»[1].

Дипломатические ярлыки татарских ханов написанные во время политического отношения с другими государствами, а также ярлыки на тарханство, выданные русским митрополитам и другим частным лицам были конечно очень многие, но многие из них бесследно исчезли во время различных войн, пожаров и других причин.

По материалам собранным нами по разосланным по деревням Татреспублики и по материалам, проверенных нами во время работы на истрико-этнографической экспедиции, и во время моих историко-археологичесхих поездок по разным кантонам ТР, стало известным что в последние года многочисленные письменные памятники, исторические памятники, в том числе и ярлыки, изчезли в огне.

Чтобы не было голословным, приведем некоторые фразы:

– В 1928 году, летом, во время историко-археографической поездки по Спасскому кантону[2] куда я был командирован Центральным Музеем Татреспублики для изучения и собирания исторических памятников устных и письменных, стало известным, что в деревне «Иски-Раджаб» лет 50 тому назад существовала богатая библиотека, где хранилось много рукописей на разных восточных языках, среди которых имелись многочисленные письменные памятники Волго-Болгарского и Казанского ханств и другие ценные документы, как ярлыки татарских ханов, так и грамоты русских князей. К сожалению эта библиотека со всеми имеющимися в ней ценнейшими памятниками превратилась в пепел во время большого пожара (в дер. Иски-Раджеб) летом 1880 года.

В 1929 году в Мензелинском кантоне во время моей работы в историко-этнографической научной экспедиции было достоверно известным, что в дер. «Симяк» того же кантона, в 1910 году сгорела большая библиотека, обнимавшая ценные документы и другие исторические памятники. В этой библиотеке (в д. Симяк) находилась весьма ценная рукопись по истории Казанского ханства, открывающая многие освещенные вопросы по истории

[1] Записки Одесского общества Историн Древности т. I, стран. 337 (примечание С. Вахиди).

[2] Об этой моей поездке имеется особая работа ожидающая напечатывания в размере около пяти печатных листов на татарском языке (примечание С. Вахиди).

вышеуказанного ханства, до сих пор неизвестные научному миру, а также имелись многочисленные ярлыки Казанских ханов выданные ими татаро-башкирским тарханам того же края[1].

При чем, как нам известно, по тексту этих ярлыков по вопросу подобно возобновления привелигии на право тарханства для получения официальной справки, старые ярлыки должны быть собираемы и охраняемы в архивах правительственных учреждении столицы татарского ханства. Для доказательства этого факта приводим несколько примеров из текста различных ярлыков татарских ханов. В ярлыке Сахиб-Гирей:

«что они были тарханами прежних наших страших ханов и Темур Кутур хана:

Со времени давно прошедшего Сани хана (т.е. Бату хана сына Чингизхана С.Н.В., от одного к другому переходил ярлык по обычаю истинного тарханства. А в ярлыке Берлебек хана данным митрополиту Алексею, пишется так «Чингис Царь и первые Цари, отцы наши, жаловали церковных людей кои за них молилися, молебники и весь чин поповски так молвя, написаля есмя»[2].

В 3 ярлыке Менгу Темир хана, данным русским митрополитом и всем церковным людям пишется: «И как первые цари их пожаловали, а мы Бог моляси, и их грамот не изыначивая, поточуж жалуем[3] .

В ярлыке Узбек хана, данным митрополиту Петру читаем: «И мы Богу моляся по первом же царей грамотам, грамоты им давали, жалования, а не изчыначивали им в чем. Как то было преж нас, так молвя, и наше слово уставило»[4].

Выше приведенные нами цитаты из текста различных ярлыков татарских ханов, ясно указывает на то, что возобновление привелигии на право тарханства, утверждались ханами лишь на основании документов, которые или представлялись возобновителями своих привелегии на установление верховной власти, или же эти документы были охраняемы с древних времен в архивах правительственных учреждении в столицах татарских ханств.

---

[1] Об этом можно читать мою статью «Историческое изучение Мензелинского кантона, газета «Игинче», № 8 г. Мензелинска № 475, 1929 г. Октября 10 дня (примечание С. Вахиди).

[2] Россия и Азия стран. 255 (примечание С. Вахиди).

[3] Там же, стр. 254 (примечание С. Вахиди).

[4] Там же, стр. 248 (примечание С. Вахиди).

О существовании архивов в столице Золотой Орды в г. Сарае имеются материалы в исторической литературе. Историк М. Худяков в своем труде «Очерки по истории казанского Ханства» относительно существования архивов в г. Сарае пишет следующее: «О существовании архивов в г. Сарае – пишет историк М. Худяков – имеются положительные указания в 1840-х годах при рукописях Терещенко «в одном месте были открыты листы бумаги, на которых находились кусочки восковых печатей и синие шнурки, плетеные серебряно-золотой нитью», в другом месте «найдены были чернильницы и кусочки писанной бумаги украшенные золотом и незабудками», далее были открыты «песочницы, чернильницы, монеты, пережженная бумага и листки целой с выписанными на ней золотыми незабудками и золотыми по краям ободками; в верху одного листка заметны писанные золотом буквы», потом обнаружена перетлевшая бумага, свинцовая печать с изображением на ней тигра», затем «кипы бумаги, исписанной по татарски, наконец описывается находка просто целого архива. К сожалению, эти замечательные находки Терещенко пропали для науки бесследно и рукописи, которые сохранялись невредимо в земле в течении несколько столетий погибли, как только рука человека извлекла их из земли. Проф. Лихачев говорит: «Где находятся все эти остатки, драгоценные для дипломатики сфрагистики, я не мог узнать, да и сомневаюсь – сохранились ли они».

Несколько ярлыков татарских ханов данных русским митрополитом дошли до нас лишь в переводах на древне- русском языке, а подлинники этих ярлыков, которые по всей вероятности были написаны на татарском языке не сохранилась.

Из таких ярлыков нам известно следующее:

I. От Ханбеке Тайдулы митрополиту Феогносту.

2. От него же митрополиту Алексею.

3. От хана Узбека митрополиту Петру.

4. От Менгу Темира русским митрополитам и всем церковным людям вообще.

5. От Вердебикова митрополиту Алексею.

6. От одного хана митрополиту Михаилу.

7. От Эханбеки Тайдуллы митрополиту Ивану.

Ярлыки на тарханство выданные русским митрополитам впервые были изданы Новиковым 1787 году в Москве. В древне Российской. т. 4*. Здесь они издавались все семь ярлыков вместе,

до сих пор остается неизвестным, что откуда добыл Новиков эти ярлыки.

Вторично эти ярлыки издавались в Суздальской летописи Н. Львовым в С. Петербурге 1792 году; но здесь издавалось только шесть ярлыков.

Третий раз ярлыки издавались в свет в 1819 году в «Собрании государственных грамот и Договоров» т. II, Москва, № 2, 7, 9, 10, 11, 12, здесь тоже напечатано только шесть ярлыков.

В 1842 году эти ярлыки издаются в Москве в виде отдельного труда с полными исследованиями проф. Григорьева под названием «О достоверности Ярлыков данных ханами Золотой Орды русскому духовенству».

В 1876 году этот научный труд проф. Григорьева без изменений помещается в в 116–258 стран. сборника «Россия и Азия (С.П.Б.)» по издании этого крупного научного труда проф. Григорьевым, русские ученые не имели возможности достаточной степени воспользоватся этими ярлыками.

В особенности после брошенного Карамзиным сомнения о достоверности этих ярлыков, например, Карамзин пишет: «Истинных или подложных» внимание русских ученых к изучению этих ярлыков еще более уменьшалось, а потому ярлыки эти не обратили на себя ничьего внимания и не один ученый не пользовался ими, как источником для изучения русской истории периода татарского владычества.

В.В. Григорьев в своем вышеуказанном труде всесторонне исследавал эти ярлыки и своими прочными доводами и ясными доказательствами уничтожил не уместное сомнение историка Карамзина.

«Мы думаем, со временем постараемся доказать на деле – пишет проф. Григорьев в своем выше указанном труде – что ярлыки – суть одни из самых замечательных не менее чем договоры Олега и Игоря с восточно-Римскими Императорами, чем договоры великих князей Тверских в Московских с Новым городом, духовные завещения сих последних или какие либо другие акты из древнего периода нашей истории. Они содержат в себе много драгоценных исторических фактов и указании, которые при умении пользоватся ими, и при знании быта, обычаев и установлении монгольских, могут объяснить многое в истории».

Изучение этих тарханных ярлыков, выданных русским митрополитам ханами Золото-Ордынсксго ханства, все еще продолжает-

ся. Здесь можно указать для доказательства этого вопроса, капитального труда М.Д. Приселкова, где он всесторонне исследовал эти ярлыки.

Следовательно, важности этих исторических памятников Золото-Ордынского ханства таким образом признана со стороны позднейших ученых как реальный факт на деле.

Со времени Золото-Ордынского ханства на татарском языке до наших дней сохранились только три такие тарханные ярлыки. Один из этих ярлыков выдан в 1391 году ханом Тохтамышем «Некоему Бек Хаджию»; другой ярлык выдан ханом Тимур-Кутлугом, в 1397 году какому то Мухаммеду. Третий ярлык посланный Тохтамышем в 1392 году польскому короле Ягайло, во время дипломатических сношений с Польским правительством.

По старому обычаю Золото-Ордынских ханов, этот последний дипломатический ярлык, хана Туктамыша, написан уйгурским шрифтом. Из вышеуказанных ярлыков 1-ый (хана Туктамыша) написан арабским шрифтом, а второй ярлык Тимур-Кутлуга арабским и уйгурским шрифтами. Академик Радлов из этого приходит к такому заключенно, что «татарские ханы употребляли только в дипломатических документах уйгурский шрифт, а арабский в документах, которые назначены были для народа.

Относительно распространения уйгурской грамоты в канцеляриях татарских ханов, академик Радлов пишет следующее:

«Так как Чингис-хан лично интересовался распространением уйгурской грамоты, то эта грамота сделалась официальной в канцеляриях ханов и продолжалась в них употребляться даже и в то время, когда эти ханы уже вполне стали тюрскими и даже в тех местах, где ни народ, ни ученые не знали ее».

Ярлыки Токтамыша и Темур-Кутлуга нам доказывают, что ханы Золотой Орды до начала XV века не переставали издавать ярлыки писанные уйгурскими буквами, но тогда уйгурский шрифт не был уже единственным шрифтом, употребительным в ханских канцеляриях; одним уйгурским шрифтом писан только дипломатический документ – письмо Токтамыша-хана к Ягайлу. Подлинник ярлыка Токтамыша находится в руках одного.

В 1851 году эти ярлыки были изданы с полными исследованиями и правильными переводами профессором Березином в своем известном труде «Тарханные Ярлыки Тохтамыша, Тимур-Кутлуга и Саадет-Гирея».

Подлинник ярлыка Тимур-Кутлуга был приобретен в 1813 году чиновником Австрийского Посольства в Константинополе А. Фон-Рабом и был им послан известному ориенталисту Гаммеру. Гаммер по этому поводу обратился к немецкому проф. Казанского Университета ориенталисту Френу. Френ же поручил это дело своему другу и сотруднику-преподавателю тюрского языка в Казанском Гос. Университете Ибрагиму Халфину. Халфин, исследовав в некоторых словах этого ярлыка и писав латынским шрифтом о своем разяснении, что было бы понятно для незнакомого ученого татарским языком Гаммера я послал обратно последнему ученому.

Гаммер при помощи вышеуказанной работы Ибрагима Халфина перевел этот ярлык на немецкий язык в в 1818 году, издал в г. Вияне сборник.

Известный ориенталист Вембер с полным исследованием уйгурский и арабский тексты этого ярлыка в отдельности перевел на немецкий язык. Академик Радлов подробно исследовавший язык этого ярлыка, издал с верным переводом в 3 т. «Записки Восточного отдела Императ. Русского Археологического О-ва». В этом труде очень основательно исследован язык этого ярлыка.

Замечательным последним научным трудом о ярлыке Тимур-Кутлуга является ученая работа академика А.Н. Самойловича. «Несколько поправок к ярлыку Тимуру-Кутлуга» академик Самойлович в этой работе открывает в научном мире, что ярлык Тимур-Кутлуга, сохранившийся до наших дней не есть подлинник, а представляет собою копию сделанный в Константинополе в XV–XVII столетиях одним любителем чигатайской и уйгурской литературы.

По нашему взгляду все молодые научные работники, интересующиеся изучением ярлыков и литературы древне-тюркских народностей, должны быть знакомыми с этим весьма важным трудом А.Н. Самойловича.

Дипломатический ярлык хана Токтамыша к королю Ягайлу был издан в Казани 1850 году князем И.А. Оболенским, как отдельный труд под названием «Ярлык хана Золотой-Орды Тохтамыша к польскому королю Ягайлу».

В этом труде княза Оболенского помещена точная копия ярлыка, перевод ярлыка на русский язык сделанный известным Казем-Беком полный анализ и исследование текста сделанные проф.

Березиным вместе с Бонзаровым. Этот научный труд князя Оболенского представляет один из важных научных исследований по вопросу ярлыков.

Из ярлыков о тарханстве, выданных Крымскими ханами сохранился только один ярлык, выданный в 1523 году ханом Саадет-Гиреем, относительно жалования некоторым лицам прав к тарханство. Этот ярлык был издан в 1844 году вместе с ярлыком Токтамыша выше указанным проф. Григорьевым в «Записках Одесского О-ва Истории и древности». Остальные ярлыки, оставшиеся от Крымских ханов суть дипломатические грамоты. Из числа этих последних ярлык написанные Польским королям и Московским князьям были изданы Академией Наук в 1864 году в Петербурге под названием «Материалы для Истории Крымского Ханства». Тексты ярлыков для этого труда были тщательно переписаны с оригиналов известным Хусеином Фэиз-Хановым, а самый труд вышел в свет под редакцией проф. Вельяминова Зернова в 898 стран, где были помещены 378 ярлыков. Все ярлыки Крымских ханов написаны арабским шрифтом.

Как видно из вышеуказанного труда «Материалы для Истории Крымского ханства» самым старым ярлыком является «Шартнамэ» Мухаммед Герей хана польскому королю, написанный в 1519 году на чегатайском наречии.

Ярлык хана Саадат Герея на тарханство написан по форме ярлыка Тимур-Кутлуга со стороны языка также очень подходит на Золото-Ордынские тарханные ярлыки. Но в зтом ярлыке мы видим слова не встречающиеся в Золото-Ордынских ярлыках, но написаны в ярлыке Сахиб Гирей хана найденным нашими трудами. Из этого можно заключить то, что начиная с середины первой половины XVI века Крымское и Казанское ханство стояли в очень близких отношениях, как со стороны официального так и при ведении канцелярских дел.

Из татарских ученых человеком впервые пользовавшимся ярлыком в введший в свой исторический труд несколько ярлыков был известный историк Ш. Марджани. Историк Марджани поместивший в 1-ом томе своего труда стр. 110 и 116 тарханный ярлык Тимур Кутлуга хана, выданный в 1397 году некоему «Мухаммеду» и дипломатический ярлык хана Туктамыша, написанный в 1392 году польскому королю Ягайлу, пользовался этими ярлыками как историческими документами, заслуживающих

доверия. Но ввиду того, что издание этой книг вышли в свет после смерти их автора Ш. Марджани ярлыков издан со многими опечатками.

Для того чтобы не отвлекаться от нашей темы, мы здесь не будем долго останавливатся о недостатках цитат этих ярлыков, от невнимательной корректуры.

После октябрьской Революции татарские ученые Г. Газиз и Г. Рахим в своем важном большом труде на татарском языке «История татарской литературы», вышедшем 1-ой книгой по истории татарской литературы. I том, древний период, II часть, стран. 59–74 сделали всестороннее исследование ярлыков, дав этому вопросу обширное место в своем труде.

Исследования этих 2-х татарских ученых представляют по нашему мнению самый важный труд на татарском языке по вопросу о ярлыках.

Начиная с истории изучения ярлыков в этом труде освещаются и вопросы о важности ярлыков, о языке ярлыков, о классификации ярлыка или диалекты ярлыков, о результатах, которые можно вывести на основании всего вышеуказанного. В этом труде также приводятся тексты по транскрипции Радлова из ярлыков ханов Тимур Кутлуга и Токтамыша с переложением на теперешний литературный татарский язык. Таким образом, исследования о ярлыках этих 2-х татарских ученых популяризируя ярлыки среди татарской массы открывают широкую возможность просвещенной татарской молодежи пользоваться этими ярлыками.

Со времен Казанского ханства до наших дней сохранился только один ярлык, найденный нашими трудами ярлык хана Сахиб Гирея, о котором имеется специальная моя работа. Кроме этого ярлыка со времен Казанского ханства до наших дней никаких других письменных памятников до сих пор не найдено.

Письменные документы имевшиеся в центре сожжены и уничтожены в 1552 году при взятии Казани, а хранившиеся в деревнях в стороне от центра постепенно уничтожались пожарами и в революционных движениях бывших в различных веках и во время сбора и сожжения татарских книг которые прежде практиковались. Относительно этого в наших руках имеются достоверные материалы, которые нами собраны во время различных поездок и экспедиции, сделанных с целью изучения истории и исторических памятников татарских деревень.

В статье проф. Фирсова относительно научной важности ярлыка хана Сахиб Гирей мы читаем следующие важные слова: «...При взятии Казани русскими в ...году город был сожжен и сокровища татарской культуры, несомненно и изобилии собранные в столице Казанского ханства, погибли в огне. Вот почему история татарской Казани надлежащим образом неизвестна. Думаем, что для периода независимой в политическом отношении Казани не сохранилось никаких вполне прочных татарских источников, на основании которых только и можно было бы нарисовать безпристрастную и правдивую картину внутреннего состояния Казанского царства.

Так думали долго – в течении всего господства Русского правительства над татарами – вплоть до октябрьской революции, когда господство это кончилось, тогда оказалось, что татары во времена этого господства скрывали и берегли для себя некоторые уцелевшие от погрома 1552 г. исторические памятники.

Татарский марксист ученый Г. Ибрагимов в своей статье «Материалы к изучению эпохи татарского феодализма» (журнал «Безнең юл» № 3, 1925 г.) пишет так: «В чем же заключается значение ярлыка хана Сахиб Гирея...

Древнее казанское ханство – это есть эпоха татарского феоделизма. По истории нам это известно. Все сведения, относительно этой эпохи были исчерпаемы из чужих источников, больше всего из русских односторонних летописных сводках, что же касается письменных памятников оставшихся от Казанского ханства на татарском языке не было вовсе. Вот этот ярлык – хана Сахиб Гирея, является единственным письменным памятником, сохранившегося от этой эпохи. Кроме этого ярлыка от Казанского ханства никаких письменных памятников не осталось.

Проф. Фирсов, молой ученый М. Худяков, Габайдуллин и другие ученые, ясно свидетельствуют о правильности и подлинности этого ярлыка. Несколько слов об открытии ярлыков. Распространилось у крестьянского веселения, что у крестьянина Рахматуллы Ахмарова дер. Мамаево, Мамадышского уезда, имеется старая бумага, оставшаяся с древних времен и слылась под названием божья бумага (т.е. священая бумага). Молва дошла до С.Г. Вахидова. Вахиди, после огромной затраты трудов и энергии открыл и приобрел этот ярлык.

Не дешево стоило Вахиди эти труды и не скоро ему удалось открыт и приобрести этот ярлык. Значение ярлыка в научном

отношении велик. Историки марксисты, при исследовании истории татарского народа, по этому ярлыку узнают классовое устройство той эпохи и моменты татарского древнего крепостничества, также о форме правления тогдашнего государства татарского. При чем, по этому же ярлыку ясно узнаем, что хан, о котором националисты все время говорят похвально, эта личность есть не что иное как предводитель и председатель господствующего феодального класса того времени».



Об общественной деятельности проф. Ирзина можно прочитать научную работу известного тюрколога А.Н. Самойловича «Записки коллегии Востоковедов при Азии-Русск. Академии научн. т. 1».

*Ф. 53. Оп. 1. Ед. хр. 22*

**Перевод ярлыка золотоордынского хана Токтамыша**

Начальнику Крымской области Кутлу Буге, районным князьям, народным судьям, законоведцам, настоятелям, старцам, секретарям палат, таможенным чиновникам, чиновникам весовщиков, начальникам (войсковым) букаулов, чиновникам на заставах, всяким старшим ремесленникам и веем: Предъявитель этого ярлыка Бек Хаджи со всем подчиненным ему, племенем хотя и взыскан был нашею милостью, но все подати с надбавками с Суткульцев взимались ежегодно в государственное Казначейство.

От сегоднешнего дня подать именуемую Салыг не налагать, подвод и продовольствия не требовать, платы на казенные амбары и земельный налог не требовать.

Будут ли Суткульцы путешествовать внутри или вне Крыма и на местах остановки, как свободных от начальника области, поборов и кого нибудь подчиненного не требовать. Всем собравшимся вкупе на общее путешествие, не только им зла не причинять, но их защищать и охранять.

Пожалованным призовым тарханным ярлыком Бек Хаджитию вы все оказывайте безпрекословно содействие, – да, таким образом доводится до сведения приказание Тимер Пулата.

Всякие причиняющие им вред, беспокойствие и делающие им раскладку областных подушных – пусть они боятся.

Но если ты, Бек Хаджи, будучи пожалован моей милостью и вопреки пожалования моего будешь нарушать приказания ярлыка и тебе же доброго не будет.

В удостоверение чего пожалован ярлык за алою тамгою.

Писан в степи, в Ор-Тюбе на Дону двадцать четвертого дня месяца Зюлькагида, семьсот восемьдесят четвертого года (Гиджеры), в лето обезъяны (1382 г. н.э.)

Печать:

«во имя всемилостивого и милосердного бога, нет бога кроме единого бога, Мухаммед посланник божий... султан Туктамыш». Эта печать приложена в двух местах.

Слова печати написаны особыми куфическими буквами, очень трудно разбираемыми на арабском языке. При исследовании ярлыков и при переводе их я пользовался известными учеными трудами нижеследующих ученых востоковедов: академика А.Н. Самойловича, академика В. Радлова академика Крачковского, академика Бартольда, профессора С.Е. Малова, проф. И. Березина, проф. В. Григорьева, проф. Купрюли зада Мухаммед Фуада, востоковеда Милиоранского, Вомбрия, историка Мартания и ряд других. Пользовался рукописями:

«Нахджел-фарадис» (XIV в.), – «Очмак Келиди», – «Джем-Жимя Султан», – «Хосру Ширан», – «Мухаббет-намэ», – «Киссаи Юсуф», – «Кабуснамэ», «Джамигут таварих», – «Дастан Несли Чингизхан», – «Описание восточных рукописей и документов, подаренных С.Г. Вахидовым научным организациям Татарии», – «Описание восточных рукописей и документов, принесенных в дар С.Г. Вахидовым в 1934 г. в Академию Наук СССР и хранящихся там же» и ряд других.

С.Г. ВАХИДОВ (Вахиди).

Казань, 10/IV-1936 г.

Адрес исследователя и дарителя ярлыков С.Г. Вахидова:

Казань, ул. Сабанчи, д. № 11, кв. № 2.

*Ф. 53. Оп. 1. Ед. хр. 10*

**Хәзердә ярлыкның**
**төб нөсхәсе кайда саклана**

Гыйльми кыйммәт ягыннан мөһим урын тоткан тарихи хатирәләрне эзләб табу һәм аларны гыйльми тикшереп нәшер итү эше, ничаклы зур көч һәм озак гомер сарыф итүне тели торган авыр эш булса, табылган әһәмиятле тарихи хатирәләрне саклау, алардан киң катлау гыйлем ияләрен файдаландыру эше дә, бер дә шиксез, зур тәдбир[1] һәм гакыл белән эшләүне сорый торган мөһим эшләрдәндер. Табып алынып, гыйлем ияләренә киң вә тулы файдаланырлык уңай бер хәлгә куелмаган, шулай ук күп гасырлар буена саклану чаралары тәэмин ителмәгән хатирәләрнең әһәмиятләре юк дәрәҗәсендәдер.

Ел саен әллә ничаклы, гаять мөһим тарихи хатирәләр төрле сәбәбләрдән юкка чыга баралар. Авылларда җыш булып тора торган ут казалары һәр елны, әллә ничаклы мөһим гыйльми материалларны көлгә әйләндереп, җир йөзендән юк итә бара. Әле шушы соңгы елларда гына, Татарстан җөмһүриятенең мәркәзе Казан шәһәрендә гыйлем өчен гаять мөһим урын тоткан һәм бик күп гыйльми әсәрләрне эченә алган, Мәрҗани көтепханәсенең зур бер өлеше ут казасына очрап юкка чыкканлыгы күз алдында[2]. Безгә җыелган материалларга караганда, мондан ярты гасырлар алда, һәрбер татар авылында дип әйтерлек дәрәҗәдә күп санда, авылларның тарихлары, искедән язылып килгән шәҗәрәләре һәм бик күп аерым кешеләр турындагы төрле документлар күп булганлар. Арча кантоны Кышкар, Мәнгәр, Оры, Ашыт, Әтнә авылларында, Мари өлкәсе Бәрәнге авылында, Мамадыш кантоны Ошма һәм Байлар Сабасында, Чистай кантоны Мөслим авылында, Ыспас кантоны Җанбакты, Ташбилге, Иске Рәҗәб авылларында бик искедән язылып килгән гаять мөһим тарихи хатирәләрнең мондан берничә еллар алда гына юкка чыгулары мәгълүм. 1928 нче елның җәендә, минем тарафдан Ыспас кантонына ясалган тарихи һәм археографически поездка вакытында, шул ук кантон Иске Рәҗәб авылында, мондан ярты гасырлар алда, Болгар ханлыгы заманыннан калган, күп әсәрләрне эченә алган вә күп документлар анда

[1] Тәдбир – эшнең ахырын алдан куреп эшләү.

[2] Бу турыда С.Г. Вахидинең «Мәрҗани көтебханәсе һәм аның соңгы язмышы» мәүзугысындагы (темалы) мәкаләсе // Безнең юл, 6–7 сан, 1929 ел 14–17 битләре каралсын (С. Вахиди искәрмәсе).

саклана торган зур бер көтебханәнең утда янып юкка чыкканлыгы мәгълүм булды. Шулай ук 1929 нче елда, Минзәлә кантонында, тарих һәм этнография гыйльми экспедициясенең тикшерүләре соңында, шул кантонның Симәк авылында гаять мөһим вә кыйммәтле документ һәм хатирәләрне эченә алган зур көтебханәләрнең 1910 нчы елда утда янып юкка чыкканлыгы расланды (бу турыда: Минзәләдә чыга торган «Игенче» гәзите № 475, 1929 ел, 10 октябрь, пәнҗешәмбе, Минзәлә).

Мәзкүр Симәк авылы көтебханәсендә Казан ханлыгы тарихының моңа чаклы гыйлем дөньясына билгеле булмаган яклары, зур бер тарих китабы белән бергә Казан ханларының шул якдагы тарханларга биргән күп санлы ярлыклары да булган.

Бу турыда тагы да ачык һәм кызганычлы факт итеп, Алтын Урда пайтәхете Сарай шәһәренең хәрабәләрен дүрт ел буена тоташдан казып, санап бетергесез күп сандагы җир астында яшереп яткан гаять мөһим тарихи хатирәләрне хәзинә эзләү максады белән актарып чыгарып юк итүче, Министерство Внутренних Делның чиновнигы, полковник Терещенконың хезмәтләрен күрсәтеп була. Терещенко 1843 нче елда Министерство Внутренних Дел тарафындан мәдәни Сарай шәһәренең курганларын, насыпьларын, валларын, каналларын, башка шундый мөһим мадди мәдәният калдыкларын казу, актару һәм андагы җир астына яшерелгән дәүләтләрне актарып чыгару өчен командировать ителә. Терещенко мәдәни Сарай шәһәренең хәрабәсе өстендә, зур бер афәт булып, 1847 нче елга чаклы, 4 ел бер тоташдан казынып, актарынып, әллә ни чаклы курганларны, насыпьларны вә аңар чаклы җир астына яшеренеп калган бик күп гыймарәт[1] калдыкларын, бик күп комнаталарны җимерә, вата. Терещенко дүрт еллык казыну, актарыну һәм Алтын Урда пайтәхте Сарай шәһәренең мәрхәмәтсез дошман кулы белән яндырылганның соңында, җир астына яшерелеп калган бөек Алтын Урда мәмләкәтенең мәркәз шәһәрендәге архивын, андагы документларны, печатьларны вә башка шундый мөһим әсәрләрне таба. Ул, шул ук казынулары чорында, Алтын Урда мәмләкәтенең монетный дворын, андагы акча сугу эшенә караган бөтен коралларын, монетный двор бинасының калдыгын вә аның эчендәге фонтан трубаларын вә бик күп сандагы акчаларын таба. Боларга башка ул бер курганны ка-

[1] Гыймарәт – корылма.

зыганда ат өстенә атланган хәлдә чакма киемендә күмелгән бер гаскәрине таба. Боларга башта ул әллә ничаклы, өстенә татарча сүзләр белән гаять матур итеп язылган һәр төрле металдан эшләнгән савыт-саба һәм кораллар таба. Әйтик, 1847 нче елда, ул ике кадак та сигез мыскал авырлыгында саф алтыннан ясалган «сосуда серебряного блюда формою своею более похожего на сковороду, весом в два фунта 86 золотников на серебряном блюде, была написана татарская замечательная надпись: «биш сум такый егерме Нократ мыскал ярым». Терещенко актарып чыгарган, мәдәни Алтын Урда мәмләкәтенең мәрхәмәтсез дошман кулы белән яндырылган, мәркәз каласының җир эченә яшеренеп калган, гаять күп гыйлем вә фән өчен соң дәрәҗә кыйммәтле, Алтын Урда тарихын гына түгел, хәтта дөнья тарихының кайбер якларын тотыруда, яки карангы якларын ачуда дөрес факт булып төшә торган хатирәләр. Җир йөзенә чыканның соңында эзсез югалалар. Әгәр алар турында саклану чаралары күрелсә иде, мәркәз шәһәрләрдәге иң зур музейларны баета торган мөһим хатирәләр бугенге көндә дә сакланып калган булырлар иде.

Менә шундый кызганыч, фаҗигале, тарихи хәлләрнең барысын да күз алдында тотып, күп еллар хезмәт куеп табкан Сахибгәрәй хан ярлыгының төп нөсхәсен мин үз кулымда асрауны, бердән, аның саклануы өчен куркынычлы табып, икенчедән, ярлыкның төп нөсхәсе белән киң катлау гыйлем ияләренә тулы вә иркен файдалану мөмкин булсын өчен нинди булса да бер гыйльми мөәссәсәгә[1] бүләк тиеш табдым. Ярлыкның төп нөсхәсе белән танышу һәм теләгән халык мөәссәсенә аның белән файдалану мөмкин булсын өчен, мин ярлыкның төп нөсхәсен Татарстан җөмһүриятенең Үзәк музеена үзем куйган мәгълүм шартлар белән бүләк итәргә карар кылдым. Мин бу эшем белән менә мондый бер планны алга сөрдем. Мәзкүр Үзәк музее янында көнчыгыш кулъязма һәм документлар бүлеге нигезләп, Татарстан җөмһүриятенең авыл вә шәһәрләрендә елдан ел төрле сәбәбләрдән юкка чыгып бара торган бөтен язма тарихи хатирәләрне һәм соңгы гасыр, шулай ук безнең замандагы гыйлем ияләренең язма оригиналларын шунда җыеп сакларга, шулай итеп мөһим тарихи вә гыйльми әсәрләрнең югалу вә юкка чыгуларына чик куярга мөмкин булыр дип, уйладым. Шушы фикер вә планымны эшкә ашыру вә икенче ибдәшләр-

[1] Мөәссәсәгә – оешмага.

гә дә гамәли үрнәк булу өчен, Татарстан җөмһүриятенең гыйльми мәркәзенә түбәндәге үтенеч кәгаземне бирдем.

*Кулъязма ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана: 53 фонд, 1 тасв., 18 сак. бер. Гарәп графикасында, татар телендә.*

*Текстны гамәлдәге язуга күчереп, басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәс сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## XI йөз кулъязмасы «Тәҗареб-әл-Өмәм» (906 елда язылган кулъязма)

Эзләнү тарихы

Казанда булган көтебханәләрдә, архив һәм аерым кешеләрнең кулларында саклана торган тарихи һәм гыйльми байлыкларны тикшерү, өйрәнү һәм аларны хисапка алу максады белән үткәрелгән соңгы «гыйльми йөрешләремдә», мин ниндидер бик борынгы кулъязманың азаккы битеннән төшереп алынган зур күләмдәге бер рәсемне табып алырга муаффәкъ булдым[1].

Хуҗасының сөйләвенә караганда, бу рәсем бик кыйммәт бәя торган бер иске кулъязмадан төшереп алынган булган икән. Аның әйтүенчә, Мисыр солтаны бу кулъязманы хуҗасыннан алтын белән бик зур акчага сатып алырга теләгән икән. Ләкин кулъязма хуҗасы әлеге әсәрне бик кадерләп саклаганга күрә түгел, аны бөтенләй сату, хәтта аңардан күчерткеч алдыртырга да күнмәгән икән.

Рәсем хуҗасы бу сүзләрне миңа ышандырып, дөрес сүз итеп сөйләде. Табылган рәсем үзе дә, хуҗаның бу сүзләре рас булырга тиешлеген көчәйтә иде. Рәсемнең шактый искергән һәм саргайган булучылыгы, аның моннан кырык еллар алда төшереп алынган булуын уйларга мөмкинлек бирә иде. Димәк, кырык еллар алда кемдер көнчыгыш кулъязмалары белән кызыксынып, аларның әһәмиятле битләрен рәсемгә төшереп алу белән шөгыльләнгән. Ул кеше моның белән кулъязманың саклану якларын тәэмин итүне дә уйлаган булырга кирәк, гадәттә ул белгечләр тарафыннан шулай эшләнеп килә.

[1] Муаффәкъ булдым – ирештем.

Кем соң мондый гыйльми эшләр белән кызыксынган. Бу кадерле кулъязма кемдә, кайда саклanган. Ә хәзерге көндә бу әсәр дөньяда бармы? Әллә инде бу әсәрдә башка бик күп тарихи әсәр һәм кулъязмалар шикелле бөтенләй югалганмы?

Менә бу сорауларга дөрес һәм тулы җавапны бары киң план белән алып барылган «гыйльми тикшерү йөрешләренең» йомгак нәтиҗәләре китереп чыгарган реаль уңышлары гына әйтеп бирә алачак иде. Моның өчен зур хәзерлек сызганып керешеп, нык кына эшләргә кирәк булачагы күз алдында иде. Бөтен көч һәм тәҗрибәләрне җыйнап, кирәк булган бөтен чара һәм методларны кулланып, мин эшкә керештем. Берсе артыннан икенчесен көтепханәләрне тикшерә, актара башладым. Аерым кешеләрнең көтепханәләрен, кечкенә архивлар, шүрлек, шкаф һәм киштәләр, андагы бөтен язмалар; очырмалар, андагы ящик һәм сандыклардагы бөтен кулъязмалар, барлык басма китаплар, төргәк-кәгазьләр – барысы да минем күздән кичерелә, тикшерелә, үткәрелә бардылар. Очырмалардагы тузан-туфраклар, утын амбарларындагы, подвал һәм кладовойлардагы сырость, пычрак вә салкыннар, бер төрле дә бу эшне дәвам иттерүдән мине туктата алмадылар. Бу эштә мин сорашу юлы белән тел мәгълүматы җыя баруны да читкә куймадым. Шул ук вакытта, рус һәм татар телендә нәшер ителгән борынгы әдәбият аркылы тикшерү һәм эзләнүләрне дә истән чыгармадым. Җәелеп алыр барылган бу тикшерү эшләре мине Болгар, Казан, Алтын Урда дәверләре борынгы язма әдәбиятка тирән әһәмият бирүгә дә мине җитәкләделәр.

Представьте себе, Сайид Габдульминанович, что вот я, Пасынков, пишу роман о борьбе Татар с Московией и падении Казанского царства. Я стремлюсь использовать все наличные материалы русские (о русских и о татарах) и жду от Вас материалов татарских (опять же о татарах и русских). Мне важно разрушить русопятскую, лживую точку зрения на татар. Поэтому я должен привести

в такое сочетанье русский (уже имеющийся) и Ваш материал, чтобы создалась иная категория, новое познавательное качество, изложенное в форме романа. Ясно, что мне нужно помимо ярлыков еще много материалов: мне надо знать, какими законами, гражданскими и военными, управлялось Казанское царство, какое было у татар вооруженье, какое жалованье платили воинам, как разделялись их части и пр. (Книга о Чингисхане, изданная в Белграде несколько лет назад, исчерпывающе сообщает все сведенья о материальном устройстве боевых орд, – книга написана русским калмыком). Важно знать во что одевались, как питались воины, одевалось, чем жило, во что верило населенье гражданское. Каковы были торговые связи внутри и вне страны, производительные силы, кустарные отрасли. Какие были на поле битвы джарахи, операторы, частные врачи и пр. Нужны имена главнейших лиц и их биографии не только царя и его жены (жен), но и министров, придворных, челяди, крепостных. Громадную ценность для романа имеют отдельные эпизодические случаи, имевшее место в истории, а так же – эпизоды, не вполне достоверные, но рассказанные народом – имеющие свою назидательность. Я имею в виду исторический анекдот, который без лжи не живет, но чья тенденция обнаруживает истинные, серьезные чувства народа. Так, например, в явно анекдотическом собрании новелл о Молле Наср-Эддине правды житейской может ни на грошь, но моральные чувства народа там выражены очень сильно и ими можно воспользоваться, этим строем чувствований, пусть изложенных анекдотически – надо только перефразировать истину, в них заложенную. Истории, заключающие в себе может и пародоксальное, но остроумное, – поученье, хадисы, хабары, повесть об алимах и пр. – все это материал ценный, хотя и не официальный. Он имеет сугубую прелесть и особое значенье для воссоздания эпохи, ее воздуха, ее персонажей. Если разгрузить от вранья анекдоты о шуте Петра первого, Балакиреве, можно кое что ценное узнать о придворной жизни, умонастроении, не только шутов и лакеев. В шутках отображается жизнь, как и в поучениях. Словом мне нужны три вещи из времен конца Волжско-Камского цартсва: быт, быт и еще раз быт. Я знаю, что ярлык, Вами открытый, как и иные ярлыки, уже известные в русской литературе, бесценные, безгранично-важные документы, конструирующие пред нами основы законности или дающие варианты примененья закона к жизни. Но любой закон – это производной

от жизни, это нормированье быта народа, а для романа важны не только нормы быта, но и самый быт, при чем быт, разумеется, важней норм – ведь это так понятно. Романист лишь отчасти историограф, во всяком случае он скорее историк нравов людей, чем непосредственно абстрактной истории. В романе ярлык не приводится, но его сведенья воплощаются в картинные эпизоды и действуют уже в преображенном виде. Свои правдивые слагаемые ярлык отдает роману, в нем не оставаясь. Ярлык только сырье и только, частность. Итак, наряду с ярлыком важно знать как жили, попросту, люди тогда, когда законы их не касались, а они жили своим бытом, своими адатами, своим мировоззреньем. И вот важно восстановить быт и мировозренье средневекового татарина, как достаточно воссоздан быт и мировозренье среднеекового руса, московита. Документов о Грозном (Иване) есть много, нужны документы и о последнем царе Казани. Бытовые подробности о Иване Грозном (его характер, поступки, молитвенное изуверное чувство, припадки, культурность, отношенье к холопам, к изобретателю первого на Руси летательного аппарата и пр.) нам известны; дайте, дорогой Сайид Габдульманинович, сведенья о том же в отношении татарского царя. Вы читали подробно (пусть и фальсифицированно) изложенные картины царствования царя, дайте не фальсифицированные, но столь же обильные черты их жизни последнего царя Татарии. Эти черты должны были сохраниться в старинных татарских песнях, сказаньях, легендах, а не только в ярлыках, недостаток которых – при всем несомненном и огромном историческом достоинстве – в том, что они излишне официальны, черствы, лаконичны, опускают многое, жизненно-яркое, преследуют только букву закона, а закон не есть еще вся жизнь, а только корректив жизни. Мы с Вами должны стремиться разрушить представленье о том, что татары были дикари, а русские хоть и грубы, но были рыцари и просветители. Баллод в книге «Волжские помпеи» уже дал урок предметный по архитектуре, доказавши, что татары строили дома лучше – во всяком случае не хуже русских. Дайте же и по утвари, по одежде, по сношению с иными государствами нечто подобное баллодовским изысканьям – подробно и достоверно. Вся беда, что историю собственно России изучали мелкие, и соседние, и крупные историки, а историю Татарии изучают единицы пионеров и застрельщиков, вроде Вас, Сайид Габдульминанович. Вы несете слишком большую ношу на своих пле-

чах. Когда ж я читал перечень сгоревших библиотек, хранилищ истории Татарии, Вами приведенный, у меня на сердце стало очень тяжело, в таких условиях ваш труд просто становится необъятным. И вот мне пришло на ум тревожное: хватит ли у нас с Вами материалов для такого романа, который столь обжорливо и властно требует слишком разнообразных материалов?! Ведь что касается рукописей, которые сотнями Вы передали в научные организации, надо решить – нет ли этим рукописям «братьев», подобно тому, что есть варианты рукописи «Нехжульфарадис». Я сам записал в горах Аварии (Дагестан) песни о мухаджирах, о Зюльфукаре, мече Алия, и пр, и эти песни после я нашел в сборниках, напечатанных в Темир-хан-шуре. Напрасная моя работа! Это значит, что надо прочитать все, напечатанное о татарах по русски, и переводить из собранного Вами то, чего на русском языке нет: я говорю об официальной истории. Иное дело – бытовые записи жизни татар, если они Вами записаны. Они есть сокровищница и сто % надо из них брать и класть в роман, если только это гармонирует и как либо соотнесено с периодом борьбы волжско-камцев с русскими. Бытовой материал представляет собою полную ценность и целиком идет в дело. Рукописи на всех языках, Вами собранные, так или иначе, должны быть обработаны под углом зренья романиста, для совершенно утилитарных целей. Не всякую рукопись можно и надо расшифровать – мерами образного искусства – в романе, вероятно, выпадут из нашего вниманья, поскольку они не относясь к периоду, нами искомое, не дают для него каких либо питательных материалов. Роман вещь предметная и с этим надо считаться. Роман показывает картины, образы, систему образов в действии. Роман показывает конфликт, в данном случае – между культурой, мировоззреньем и материальными выгодами русских и татар, двух государтсв. Все, то, что можно так сказать, пощупать, потрогать рукою, увидеть глазом, представить себе, как на кино-полотне, годно для романа; он не терпит длиннот и отвлеченностей, не конкретных вещей. Императив наш – конфликт исторических фигур, помешанных в историческое время, одетых в какую то одежду, руководимых какими то предметно-ощутимыми страстями. Эти фигуры связаны трагическими, неразрешимыми – кроме крови – интересами. В них должен говорить полным голосом. Недомолвок не может быть, во всяком случае недомолвок конфликтного порядка. Есть ли весь материал для «дуэли» русского начала с татарским

началом. Хватит ли с татарской стороны разработанных данных, которые могли бы положить на обе лопатки руссификаторские, поддельные, но обильные данные. Если все есть – надо биться за овладанье материалом и начать работу над романом. Кто то напишет роман – я или другой, иное дело. (Может быть и я). Если ж материалов хоть и очень много, но они односторонни, б.ч. религиозного, просветительного, канцелярски-управленческого характера и не пустили корни в самую почву татарской жизни, в самый чернозем, то тогда еще рано говорить о романе, и пусть этими ценными данными завладеют историки чистой воды и обработают, как надо. А мы, романисты, подождем. На основе таких данных никакой романист, самый способный и гибкий, обладающий самым сильным воображеньем, истиной вещи не напишет. Тема обмана о войне – есть тема о кризисе отношения двух наций, кризисе, заложенной в очень многосторонних и предметно-широко выраженных интересах. Война – кровавый перечень слишком многих сторон жизни и эти стороны – все – должны быть изображены в романе, как бы мал по размерам он ни был. Ни на минуту не сомневаюсь, что очень многое для построенья романного конфликта (т.е. пересеченья многих интересов той исторической эпохи) у Вас есть. И еще более убежден, что, если б Вам дать средства и помощников, этих данных будет у Вас еще больше. Но меня интересует, Сайид Габдульминанович, что у Вас есть в данное время на руках, хотя бы на русский язык переведенное? Я позволяю себе несколько раз повторять одно и то же, потому что некоторый опыт у меня у самого есть в этом направлении. Я 26 лет в Дагестане собирал и теперь собираю материал о Шамиле. Я жил на его родине и в прошлом году почти полностью год провел в Гунибе, где пал Шамиль. Еще живы столетние старики, знавшие Шамиля. И все же, путем опросов, и большого чтения наличествующей литературы, я не нашел всех пружин конфликта. Только ценный труд Багирова «Три Имама» расчистил мой т. ск. умственный взор, и я нашел эту пружинку. Роман – это не некоторое количество сведений, а живой организм, которому не нужно иметь две головы, но который непременно хочет иметь руки, ноги, внутренности. Все это я пишу с надеждой – а вдруг у Сайида Габдульманинович есть, есть в зародыше и может быть развито? А вдруг он знает, как жили, одевались, ели, пили, веровали и знает, за что боролись татары против русских. Или не все, но почти все есть. Ведь тогда можно было б сесть

и работать совместно. Я ограничусь тем, что выражу уверенность в том, что многое для романа есть в рукописях, которые Вы переписали в Академию, в тех копиях, которые, очевидно, Вы оставили себе. Если у Вас нет копий, то мы посадим здесь переводчика. Я не могу не привести здесь прекрасной мысли, поданной мне К.А. Тенчуриным: Союз писателей Татарии, (а если он не согласится, мы заручимся содействием Союза в Москве) помогает нам в работе, т.е. работа Ваша над переводами должна быть оплачена,что ж касается товарищеских консультаций, Вы мне в них не откажете, не правда ли? Ведь если разобраться в возможной этой работе, надо будет сказать, что она делается не для одного романа, а вообще кладется начало планомерному собиранью и обработке хорошо законфликтованного, сюжетного описанья конца Царства Казанского, то есть будет создана, в самом собирании и обработке соответствующих материалов, вещь с началом и концом. Если побудителем к розыскам этих материалов и является роман, то тем лучше, ибо материалы, уже подготовленные, представят собою ценность высокую и для историков, такими сгруппированными материалами не обладающих. Итак, мы проделаем эту предварительную работу и Союз нам, конечно, поможет. Собранное же нами останется существовать после осуществления моей работы, как ценность на все времена. Как будем работать – вопрос техники. Допустим я буду приезжать в Казань время от времени, пока Вы не переведете материалов. Работать мы должны не спеша. Мы находим, наконец, среду, эпоху и конфликт и тогда приостанавливаем работу, считаем – для романа – завершенной.

Чем мне остается закончить это затянувшееся письмо, заменяющее разговор с Вами, столь мне притягивающий? Я скажу, что Ваш труд, делаемый Вами столько лет, не пропадает и первый памятник ему будет поставлен в том романе, которому готов отдать все силы, опыт и более всего – любовь. Всенародно, в предисловии и иными способами я буду говорить о Вас как о первоисточнике и вдохновителя труда.

Вы пишите о «Нахджел-фарадис»: мне давно хочется, в свободный час, написать для «Литерат. газеты» о том, как работают научные работники в некоторых восточных наших советских республиках (Чечня, Ингушетия, Дагестан) – напишу там о Вас, а так же и о рукописи «Нахджел-фарадис». Важно установить общенье, а освещу я Вашу работу по ходу наших совместных трудов. Я очень

занят, уже не молод, болен, болен переутомленьем. У меня много очередных работ. Работе с Вами я могу посвятить хоть годы, два три года – минимум, иначе не успею сделать ничего. Мною движет желанье получить «новенький материал», ибо у меня самого его много, а движет важная мысль, что великая история общенья татар с русскими, эта насущнейшая история еще не запечатлена, кроме бульварных романов, о которых писал Вам в предыдущем письме. Какую ж бы хотел себе награду если я кое что – с Вашей помощью – сделаю? Радостно мне было б, что б после, когда меня не будет, сказали – вот и этот кое что делал для единенья людей на земле.

Благодарю за Вашу карточку, я ее сохраню. Будет время когда в лицо узнают еще многие. Но для этого надо трудиться и открывать в своей работе новые качества. Давайте попытаемся сделать это оба.

При встрече привет Загидэ Гиреевне и Кариму Алиевичу Тенчириным.

Ваш Л. Пасынков.

Ваши материалы – по первому требованию – вышли в Казани, кроме разумеется в печатной книжке.

Я очень прошу известить меня об истории кряшен (кряшенских татар); хотя бы библиографию и точку зрения на них татар-мусульман, словом все, что найдется.

*Ф. 53. Оп. 4. Ед. хр. 1. Л. 137–138*

## Җәлал Мөхәммәдиев хаты

Мөхтәрәм Сәед Вахиди ибдәш!

Сезгә сәлам белән ибдәшләрчә хат язып, сезнең гыйлем юлындагы хезмәтегезне тәбрик кылам!

1930 – 9 нчы гыйнварда җибәрелмеш анкета белән хатларыгыз безгә килеп табшырылды. Аңладык, гәрчә тулы рәвешдә язарлык бездә мәгълүмат һәм дә бик ачык күрсәтеп торырлык материал булмаса да, икътидарыбызча бу гыйльми хезмәтне кылырга беләк сызганып хәзер торабыз. Тормыш мосагадә кылса: менә мин сезгә китаблар хакында үзем белгәнемне язам: безнең әткәмез Мөхәммәди хәзрәтнең өч кулъязма тарихы бар иде. Аның берсе – сез әйткән «Тәварихы карьяи Бөрбаш вә Мәчкәрә», монысын баларак вакытымда укыдым, шулай булса да хәтеремдә күп сүзләре калган. Менә монысы безнең йортымызда 1916 нчы елда ут казасы булып,

шунда янды булырга кирәк. Безнең ул вакытда күп китап янды, без аны күп эзләдек, таба алмадык (безнең әти 1901 нче елның гыйнварында вафат булган иде). II нчесе – Бөрбашы картларының тәрҗемәи хәлләре, мәчет вә муллалар тарихы да язылган иде. Анысын да баларак вакытымызда бик кызыксынып укый идек. Анысын абзый Гариф мулла яңадан күчереп язган иде. Гариф абзый язганын Гариф абзыйның Мәнсур исемле бер углы частный сәүдәгәрләргә әйбер төрергә саткан. Менә кадерле әсәрләр шулай игътибарсызлык белән югалды. Инде III нчесе – «Әсәре Мөхәммәдия» , асыл нөсхәсендән күчереп, Гариф абзый язган, монысы минем кулымда бар, ләкин бер кешегә укып торырга биргән идем, ул кешедән эзләп алып сезгә җибәрермен. Гариф абзый байтак нәрсәләр язган артдырып. Тагы көйле «Һиҗрәтен-нәби», «Кыйссаи Ибраһим», «Хикәяте Мәрзук» бар иде. Сезгә андый нәрсәләр кирәк булмасдыр, кирәк булса, җибәрелер.

Тагы бер кечкенә рисаләсе бар иде, анысын әтиебезнең 1886 нчы елда Духовный Собраниягә казыйлыкка сайланып, шундан имтинаг кылып[1], Казанга барып күп йөреп, казыйлыкдан хәлас булганына[2] шадланып язган рисаләсе. Монысын Җаркент шәһәренә абзыем Фатих Мөхәммәдиевкә җибәрдем, ул анда.

Менә инде үз кулъязмам хакында язам! Узган ел әтиемнең язган әсәрләрендән файдаланып һәм әтиемнең үз авызындан колагым белән ишеткән сүзләрне җыеп, Бөрбашы авылы тарихын язып, Казанга мәдәният йортына басдырыр өчен дип җибәргән идем. Под расписка[3] алганлар иде, китабым хакында миңа ачык мәгълүмат бирмәделәр. Аларда сакланамы, яки югалдымы, белмим!

Ул китабны Казанда Камил Мотыйгый матбагасында эшләүче Әхәт Садыйковдан сорарга ул тарихны. Минем кулдан алучы шул кеше, ул табып бирергә тиеш. Мин ул китабымны сезгә алырга рөхсәт кылам, яки алып, монда безгә кире кайтарып җибәрсәгез, ахырына тагы өстәсе сүзләр бар иде, дополнить итәргә булыр. Бәлки, мәслихәт булса, басдырсагыз, бу тирәдәге яшьләргә укырга бер әсәр булыр иде. Күңел белән тагы бер нәрсә язарга бик кызыгам. Анысын ничек дип атарга! Картлар әдәбиятымы, яки татар әдәбиятымы? Безнең авыл картлары бигрәк караңгы тормышлы булганлыкларындан, алар

[1] Имтинаг кылып – баш тартып.

[2] Хәлас булганына – котылганына.

[3] Под расписка – бу очракта: под расписку.

хорафат, ырым күк нәрсәләргә бик ышанучылар булганлар. Аларның тормышлары да бик кызык булган, әти авызындан бик күп кызык әкиятләр ишетдем.

Җәлал Мөхәммәдиев.
Бөрбаш. 1930 ел, 2 февраль.

Мөхәтәрәм Вахиди С. ибдәш! Сезгә сәламләр күндерәм һәм дә күп көнгә сәламәтлекегезне теләп калам.

Хатыгызны укып аңладык, безне бу хезмәткә кушуыгызны зур илтифатдан санадык, ләкин өйдән торып кына материал җыеб булмас, йөрергә дә, кулда бер нәрсәдә булмагач, кыенрак булыр күк тия. Үзегез әйткәнчә, без Татарстан туфрагындан тыш вилаятьдә торучы булганлыгыбыздан, эшкә катлашу авыр. Сезгә кирәк булган материалларны теләсәң кайдан эзләр өчен сезнең тарафдан берәр төрле мандат җибәрү мөмкин булмасмы? Мөмкин булса, музейга әгъза итеп кабул итәргә мөмкин булса, җибәрерсез.

Җәлал Мөхәммәдиев. 1930 ел, 3 февраль.
Зялал Мухамадеев.

*Хатны гамәлдәге язуга күчереп, басмага ТР ФА Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## 3. Галиәкбәров хаты

31 нче май, 1929.
Бөгелмә

Хөрмәтле Сәед әфәнде!

Җәнабеңездән доғаңызны үтенеп, гаиләгез белән бәрабәр рәхәт, тыныч, бәхет һәм сәгадәтдә, сәламәт яшәвегезне Җәнабелладан теләп калам.

28 ендә «Комсомолец» исемле пароходка утырып, Казандан кич 9 1/2 да кузгалып китеп (III нче классда) иртә белә 11 сәгатьдә Ульяновскига килеп җитдем. Шул ук минутда вокзалга барып җитүем белә поездга да утырып китдем. Әгәр пароход янә 1/4 сәгать кичексә, бер тәүлеккә Сембердә калган [булыр] идем. Юл минем өчен хозур булды. Ибдәшләр дә бар иде. Килеп җитдем пәнҗешәмбе көн 30 ында, иртә сәгать 5 дә. Бер чибәр генә кешегә

фатиргә урнашып, сәгать 8 дә Шәһидне эзләп тапдым. Тар гына бер бүлмәдә яшиләр икән. Бер сәгатьләп гәбләшеп чәй эчдек. Сезнең хатны табшырдым. Артык юаш кеше булганлыкдан, минем өчен бернәрсә дә эшли алмас дигән фикердәмен. Килгән көнне Исполкомга барырга киңәш бирмәделәр. Сәбәбе – базар көн булуы. Ул көнне вакытларын таба алмассың, диделәр. Бүген иртә белә барып персидәтелне[1] күрдем, кәгазьләрне карады, документларны алып калды һәм «бүген ибдәшләр белә сөйләшеп куярмын, иртәгә килерсез», диде. Эчдә чуашлар такта яралар. Бүгенге төнне ничек уздырырмын да, иртәгә ни җаваб алырмын икән дип, бик эчем поша. Әгәр дә отказ булса ..., ул вакытда миңа, нервный кешегә, начар булачак. Кулда 12 сум акча бар... Андан соң алтын сәгатьне биетергә кала. Шунысы яхшы, монда, хыял кадәре күп булмаса да, арзанчылык. Чибәр бодай оны 7 1/2 сум, бик яхшы крупчатка 12 сум, арыш оны 3 1/2 сум, йомырка 30 тиен. Ак май 55 тиен, ит 30 [...][2]. Мануфактур бик күб, шикәргә кысанлык. Бонда килгәч бик нык ашарга тотындым.

Бу шәһәр үзе шакдай гына югарылыкда, таулы-чокырлы җирдә салынып, җәен-кышын җил, буран гына икән. Тузан да, тузан гына һич йөрер хәл юк. Кырыйлары урман белә чолганып алынган. Хәзер, аш ашагач, иң якын тау башына менеп, бөтен манзараларны карап, алган тәэсиремне язармын. Чөнки бу хатны иртәгә, результат мәгълүм булгач җибәрәм.

1/VI Кичә кич сәгать 6 ларда Шәһид белә шәһәр кырыйларына чыгып карап йөрдек. Бөгелмә шәһәре тау башында утырган булса да, ике ягы янә биек таулар берлә уратылган. Иң биек тау Воскресенски тавы кадәр бер өлеш [...][3] кадәр. Шунда менеп, бөтен як-якны карап утырдык. Шундан, шәһәрнең 3 ягын урман чорнап алганлыгы, шәһәрнең бөтен манзарасы күренә. Шәһәр аяк астында булып күренә. Шәһәр, бер бик сай елга уртада булган хәлдә, икегә бүленгән. Елга шакдай түбәнлекдә, бер якдан икенче якка барыр өчен, бәгъзе урамлардан шакдай биек тау төшеп, тау менәсе бар. Бәгъзе урамларда (мәркәздә) биек дамба ясалып, күпер сугылган. Вокзал мәркәздән 3 чакрым, шәһәрдән 2 чакрым ераклыкда. Бая язарга оныткманмын, Шәһид белә тау башына менгәч, мөселман зиязраты күрдек. Зиярат ая-

[1] Дөресе: председательне.

[2] Бер сүз танылмый.

[3] Бер сүз танылмый.

ныч дәрәҗәдә, биеклекдә булган тауның башында, имән урманлыгында икән. Кереп, карап йөрергә вакытыбыз булмады, кичкә калдык, бәлки иртәгә якшәмбе көн карап кайтырмын. Инде нәтиҗәгә килик: бүген Исполкомга бер бардым, туры килмәде, икенче бардым, кешесе бик күп иде. Бик эчем пошды да, квартирага кайтып, шушы хатны язарга утырдым. Иртә озакламый барам һәм нәтиҗәне сезгә белдерергә ашыгам. Сәед әфәнде! Сез гафу итегез, бу минем сезгә язган хатым хатирә дәфтәренә дә кушылды да, нишлим соң, күңелемдә барын, шадлыгымны һәм кайгымны сезнең белә уртаклашасым килә. Тынычлап кайтсам, равнодушныйрак язарга тырышырмын, әгәр булмаса... Ул вакытда, Сәед әфәнде, сезгә ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә туры килә. Бәлки берәр дәү кешене күреп карый алсагыз[1] дип.

Китдем. Бер Алланың үзенә табшырып. Иншалла, ярты сәгатьдән нәтиҗә мәгълүм булыр. Бардым. Райсоюзга барырга кушып, Галиев исемле кеше белә сөйләшергә кушды. Бардым. Сөйләшдем. Дүшәнбе көн килерсез диде.

3/VI Кичә, якшәмбе көн, Шәһидләр белә Уфаның Хәкимевнеке булган, бер ярым чакырымлык ераклыкдагы урманга, чәй эчәргә бардык. Бик матур урман икән, тимер юл буенда.

4/ VI Райсоюзга бардым. Андан шәһәр потребитель җәмгыяте идарә рәисенә язу биреп җибәрделәр. Анда исә хәзергә урын юк, бәлки дә 15 көн, яки бер ай чамасындан булыр, дип җавабладылар.

Шундан Сөләймановка китдем. Булган вакыйганы сөйләдем. Миңа икенче килсәң, башка җиргә җибәрермен дигән иде. Ул көнне һич бушый алмады.

5/ VI Бүген Сөйләймановка барган идем, 3–4 көнгә авылларга чыгып китде диделәр. Янә Райсоюзга барып, аларга Сөләйманов биргән язуга таянып һәм положениемнең начарлыгын сөйләдем. Анда миңа янә дә 3 көндән килергә кушдылар. Чиска [чистка] бара, шул сәбәбле берәр урын бушар әле дип юатдылар. Тәти сүзләргә җуанып кайтып китдем. Райсоюзның башлыгы Насыйр Габделхаков (Бөгелмәнеке) дигән кеше икән. Анысы Мәскәүдә. Шушы арада кайта диләр.

7/ VI Кич беркая да бармадым. Тургенев әсәрләре укып ятдым. Бүген Аллага табшырып, 6–7 мәртәбә Райсоюзга барсам да, һич берсен тугъры китерә алмадым. Сәбәбе – Насыйр кайткан да,

---

[1] «алсагыз» сүзенең укылышында шөбһә бар.

эшләрне сдавать итәләр булса кирәк. Иртәгә барып күрәм инде. Җитмәсә, алып килгән акча да инде бетә.

9/ VI Кич Сөләйманов кайтмады. Райсоюзга янә барган идем 140 лап курсант килә, аларны эшкә урнаштырасы бар дип сөйләп торды. Сөләйманов бүген якшәмбе көн кайткан булса кирәк. Иртәгә аны тагын барып күреп карыйм. 140 лап курсант хәбәре тагын кәефне җибәрде.

Узган ел 80 пот бодайга Вагыйз Нәүрүзовның бик бай (40–50 потлап) көтебханәсен сатканлар. Сорашдырып караган идем, монда китаблар күренми. Сәед әфәнде! Минем сезгә калдырып киткән китабларны табагын шул мин әйткән 30 тиенләрдән дә кимгә сорасалар, сатмавыгызны үтенәм – үзегездә торып торсын.

Югарыда язганнарымдан үзегез минем хәлемне аңлагансыздыр. Эрәтләп хат яза алмыйм. Эрәтләп укый алмыйм, баш тулы хыял гына. Догаңызны үтенеп, ихтирам илә [...].

Хат язсагыз икән. Һәм киңәшләрегезне көтеб калам.

Адресым: Бугульма, Октябрьская 31 д. З. Галиакберова[1].

*Хат ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана: 53 фонд, 4 тасв., 19 сакл. бер., кәг. 47. Киң буйлы дәфтәр битенә зәңгәр төстәге кара белән язылган*

## Мирза Габдеррахман Зәбири хаты

1929 ел, 15 сентябрь

Мөхәтәрәм әс-Сәед Вахиди бөрадәр!

Ошбу ел беренче сентябрь тарихлы мәктүбегез юлыкды. Тарих тәмам түгел. Язылган кадәрлесе мөсвәддә хәлендә[2] тасхих вә тәнкыйхкә[3] хаҗәт бар. Рәхмәтулла хәзрәт тәрҗемәи хәле дә тәмам түгел. Касыйм вилаяте Яубаш карьясында Нуркәйдән киткән Солтан бине Гали дигән кешедә мәзкүр хәзрәт язган «Гаятел-бәян» намында тыйбб китабы бар дип ишеткән идем. Сораб мәктүб яздым, халән[4] җаваб килмәде. Шул сәбәбле аның тәрҗемәи хәле кичекде. Бу сәнә җәй фасылындан тарих тәмам булуы өмид иде, ләкин

[1] Адрес кирилл хәрефләре белән язылган.

[2] Мөсвәддә хәлендә – каралама хәлендә.

[3] Тасхих вә танкыйхкә – дөресләү һәм төзүтүгә.

[4] Халән – хәзер дә.

зараибе сәкыйлә[1] кул-аякны баглаганлыктан, форсат булмады. Кыш фасылында аның илә иштигалем[2] юк. Шаяд, киләчәк җәйдә вәгъдәгә вафа идәрем[3]. Иван Грозный заманында бер җыелышын хәбәр биргән идеңез. Ул каю тарихда: руслар тарихындамы, яки мөселманнар тарихындамы? Бер форсат булганда шундан[4] бәян итсәңез иде. Рәхмәтулла хәзрәт китабында шәгердләрендән килгән мәктүбләр бар. Аларны[5] язганда ихтыяҗ булачак. Шул сәбәбдән хәзергә кичекде.

Мирза Габдеррахман Зәбири.

*Хат ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана: 53 фонд, 4 тасв., 19 сакл. бер., кәг. 47. Киң буйлы дәфтәр битенә кара төстәге кара белән язылган*

## Исмәгыйль Рәхмәтуллин хатлары

Хөрмәтле Сәедмөхәммәд Вахидига

1929 ел, 8 сентябрь тарихлы, Татарстан җөмһүриятенең «Үзәк Музее» исемендән Троицкидагы Рәсүлев исеменә җибәргән «Анкета»ңызны (ул эшләрне үзе башкарырга форсаты булмадыгындан) безгә табшырды. Мин Троицки нахиясе, Иске Әмин карьясында мөхибел гыйлем[6] Исмәгыйль бине Динмөхәммәд Рәхмәтуллин дигән бер затмын. Түбәндәге нәрсәләрне җибәрүеңезне үтенәм.

1 – тарих һәм этнография гыйльми экспедициясенең эшләре илә танышу өчен 24 сентябрьдә чыккан 217 номерлы «Кызыл Татарстан» гәзитәсендән бер данә.

2 – авылларда йөргәндә бәгъзе бер тарихи нәрсәләрне, яки иске язма китабларны сорап, яки сатып алырга тугъры килгәндә, үземә түгел, бәлки Үзәк музейга икәнлеген белдергән вә минем дә, сезнең бер агентыңыз икәнемне аңлаткан бер шәһадәтнамә, яки нинди дә булса бер галәмәт җибәрүеңезне үтенәм. Чөнки андый тарихи нәрсәләр күбрәк авылның мулла-монтагай вә кулак катла-

---

[1] Зараибе сәкыйлә – авыр вазифалар.

[2] Иштигалем – шөгыльләнүем.

[3] Вафа идәрем – сүздә торырмын.

[4] Чыганакта «сәндән» .

[5] Чыганакта «алазны».

[6] Мөхибел гыйлем – гыйлем сөюче.

мында була. Авылдан авылга йөреп байлар, муллалар арасында йөрү сәяси җәһәтдән хәтәр.

3 – хәзер дә бер тарихи җәя вә бәгъзе бер китаплар табдым. Җыйган нәрсәләрем хакында озын бер хат язарым.

Адресым:

*П/О Уйский Троицкого округа. Урал. обл. Пос. Аминевской. Исмагилу Рахматуллину*[1].

Тәкрар сәлам вә хөрмәт илә беренче белешеңез: Исмәгыйль Рәхмәтуллин.

*1930 ел. 1 гыйнвар.*

**Татарстан С.С.Р. җөмһүрияте «Үзәк музее»ндагы шәрекъ кулъязма шәгъбәсендә мөдир, Сәед ибдәш Вахидигә**

Сезнең бу сәнә 9 январь 228 номерлы белдермәңез һәм дә 217 номерлы «Кызыл Татарстан» гәзитәсе сәламәт килеп, 29 гыйнвар көнне кулга тиде. Язылган мәгълүматны һәммәсен дә аңладык. Фәкать «Кызыл Татарстан» дагы мәкаләнең 4 – баганасындагы «тарихи әсәр, кулъязма һәм документларны җыю һәм өйрәнү өчен, безнең кулыбызда махсус кулланма булып, без шуның буенча гыйльми тикшерү алып бардык» җөмләсендәге «махсус кулланма» да җибәрелгән булса, бигүк яхшы булыр иде.

Мин сезгә әллә никадәр кулъязма, кыйссалар, шәҗәрәләр табып җибәрергә вәгъдә итмәсәм дә (табылса, болар да җибәрелер) утырган урыным – Уралның шәркы, Азиянең Йаурупага капкасы булып, тарихи җәһәтдән: башкорд сугышлары, кыргыз вә башкорд басмачылыгы, казак (казачи сословие[2]) төзелү, аларның тузгыннары, халыкның «казачи булмаймыз» дип, илләрен ташлап күчеп китүләре, алар урнына рус казакларының килеп утырулары (чөнки мин үзем дә казачи), рус-кытай сугышларындан калган Мача (Варна[3]) янындагы Кәшәнә (Курган) һәм дә Пугач явы хакында табылган кадәр дөрест мәгълүмат җыярга вәгъдә итәм. Научный сотрудник итеп алу – сезнең эш. Минем хезмәтем сезне кәнагатьләндерсә, алырсыз. Мин дә кабул идәрем.

---

[1] Адрес кирилл хәрефләре белән язылган.

[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[3] Варна – Чиләбе өлкәсенең шул исемдәге район үзәге.

Фәкать үткән елгы кебек «гыйльми экспедиция» һәйәтләре[1] быел да йөрсә, мәзкүр һәйәтләрнең берсенә безне дә прикрипит[2] итсәңез, мин дә бер сылтау илә, сезнең мәшһүр, бай музейны күрер идем. Һәйәт илә бергә эшләп бераз эшкә практика[3] ягындан өйрәнер вә беркадәр мәгълүмат алыр, шулай идеп сезгә дә файдалы бер хезмәтче булыр идем.

Бу хат илә «кыргыз вә башкорд басмачылыгы» хакында ышанычлы кешеләрдән мәгълүмат җибәреп, кыска идеп язып җибәрдем. Менә шуның йитешмәгән йирләрен безгә тәнбиһ (критика[4]) итеңез.

Мин дә хаталарымны төзәтерем. Янә озакламый үз авылымызның тарихын, гореф вә гадәт, җырларын язарым.

Дустлык сәламе илә: Исмәгыйль Рәхмәтуллин.

*6 февраль, 1930 ел.*

*Карьяи Әмин*[5]*. Троицки нахиясе*[6]

Хөрмәтле Сәед ибдәш Вахидигә

Бер кульязма китап табдым. 300 бит калынлыгында булыр. Китабның башына: «Һаза шәрхе китабе Гөлстан әл-мөсәмма би-Шәмгые Руми»[7] дип язылган. Я Руми төрек, я Руми фарсы телендә күп хикәяләр илә әхлак фәнендә язылган бер рисаләгә охшый. Үзе 1786 елда Троиски нахиясе[8], Әмин авылының Зәйнелгабидин бине Габделгаффар тарафыннан язылган. Яхшы катыргыда, калын кәгазьдә, чиста язылган. Лаек булса, музейга җибәрергә булыр. Ләкин хуҗасы бераз хак өмид итә. Андан башка да кулъязма, дини вәгазь китаплары сколь хош[9] табыла. Фәкать кыйсса китаплары табылганы юк. Шулай да 1839 елда Казан...[10] нам табгыханәсендә хәзинәлекдән, Казан өязе Яңа Кишет авылының Рәхмәтулла Әмирхан угълы-

---

[1] Һәйәтләре – делегацияләре.

[2] Дөресе: прикрепить.

[3] Чыганакта кирилл хәфреләре белән язылган.

[4] Чыганакта кирилл хәфреләре белән язылган.

[5] Карьяи Әмин – Әмин авылы.

[6] Троицки нахиясе – Троиөк өлкәсе.

[7] Бу – «Гөлестан» китабының Шәмгые Руми дип аталган шәрхе.

[8] Нахиясе – өлкәсе.

[9] Дөресе: сколько хочешь. Кирилл хәрефләре белән язылган.

[10] Биредә язылган сүзләр укылмый.

ның харижәте илә басылган бер данә «Йосыф Зөләйха» кыйссасын табдым. Кулъязма булсын, ташбилге басма булса да, нәкъ борынгы имля, борынгы инша илә язылган тепичный лигиндарный[1] татарның борынгы абыстайлары тарафыннан балаларга егълап-егълап укытыла торган дәрес китабы. Теләсәгез, җибәрергә мөмкин.

Тәкрар сәлам вә хөрмәт илә: Исмәгыйль

*9 февраль*

Хөрмәтле «Сәед» ага Вахидигә

Байтак вакыт узды инде, сезгә хат язарга тугъры килмәй торды. Сәбәбен сәламәт күрешкәндә сөйләрем. Һәм дә сездән дә, гыйнвар хатындан да башка хат ала алганым юк. Шулай да түбәндәге мәгълүматларга мохтаҗ булдыгымдан, шу хатны язарга булдым.

I – авыл тарихы хакында, Пугачның Троицкины алуы хакында, Мача янындагы кисанә[2] хакында беркадәр туплаган мәгълүматларым вакыт илә җибәререм.

II – безем авылның утырган урыны «Уй» суының буенда «Пугач»ның[3] таптап киткән йире булдыгыннан, озын-озын ташлар, каберстанлар, убалар[4] күренәләр. Боларны казып карарга мәсарифга[5] акча кирәк булачак. Мәсәлән: күбдән түгел авылдан 7–8 чакрым йирдә, өй урыны кебек урында, таш ихата бар (йир астында). Ике ишек урынында, ишек яңагы урынында, ике озын таш утыртылган. Бераз карагач, ибдәшләрем «юкга тир түгәргә без шайтан колы түгел бит» дип, ташлап кайтдылар.

III – табылган нәрсәләрнең бәһасен тәгаен итәр өчен музейның берәр каталогы юкмы? Хәзер дә: бер җәя, уклар илә янә бер сөякдән ясалган Чынгыз хан пичәте, сугышдан калган көбә (кием), бер кисәк чакма ташы илә атыла торган борынгы мылтык кебек нәрсәләр табдым. Ләкин болар бәрабәренә азмы-күбме акча биреп алырга тугъры килә. Нинди нәрсәне, ни бәһане алырга мөмкин

[1] Дөресе: типичный, легендарный. Бу сүзләр чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.

[2] Кәшәнә булса кирәк.

[3] «Пугач»ның – Емельян Пугачёвның (1742–1775).

[4] Убалар – калкулыклар.

[5] Мәсърафга – чыгымга.

икәнлеге хакында кулланма бер каталог булмагач, бәгъзе бер нәрсәләрне алуда хәзергә имтинаг идәм[1].

Андан кала җыйналган әйберләрне почта илә җибәримме, яки җәй эчендә үзем барырга тугъры килсә, үзем илә алып барыргамы? Чөнки нәрсәләрне ящик илә закубривать[2] итеп почтага салсам, әгәр доплатное итсәм, сезгә двойной[3] расход булыр дим. Әгәр үз ягымдан акча түләсәм, җибәргән нәрсәләрем музейга кабул иделмәсә, кабат кайтып килсә, үземә артык мәсариф булыр дим. Бу хакда тулы мәгълүмат язып җибәрүеңезне үтенәм.

IV – Казандагы мәшһүр татар композиторы Солтан Габәшигә бездән шифаһи[4] сәлам сөйләңез. Юл тугъры килеп Казанга барсам, 4–5 көй нотага салдырырга мөмкин булыр иде. Бу көйләр татар көйләре арасында әлегә кадәр күрелмәгән: «Җәйләү», «Ватан», «Дезиртир», «Сандугач», «Исхак түрә» кебек озын көйләр иде. Үзенә хат язып хәбәрләшү өчен, аның адресын белмәдегемдән, артык булса да, бу сүзне сезгә яздым. Тугъры килгән бер урында сөйләрсез. Булмаса, торыр.

Хәзергә кардәшлек сәламе илә кустың[5]: Исмәгыйль Рәхмәтуллин.

9 апрель 1930 ел.

Адресым:

П/О Уйское. Троицкаго окр. Урал. обл.

Пос. Аминевское И. Рахматуллину[6].

О-во краеведения[7] җәмгыяте төзү өчен, аның уставы, кулланма руковод.[8] булырлык татар яки рус телендә чыккан китаблары булса, безгә берәр данә җибәреңез әле.

Хөрмәтле Сәедмөхәммәд ага Вахидига

Сезгә бондан элек бер-ике хат языб, берничә сөальләргә җавап сораган идем. Ни сәбәбдер? Җавап ала алмадым. Шулай да сезгә доплатный идеп берничә әсәрләр җибәрәм. Кулъязма бер данә

---

[1] Имтинаг идәм – тыелам.

[2] Дөресе: закупоривать.

[3] Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.

[4] Шифаһи – телдән.

[5] Кустың – дустың.

[6] Адрес кирилл хәрефләре белән язылган.

[7] Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.

[8] Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.

«Мөхәммәдия» илә, бер данә «Кыйссаи Йосыф вә Зөләйха» (мәнзум түгел, мәнсүр[1])ны табдым. Ләкин бушка бирмәйләр. Кулымда акчам булмадыгындан, сездән хәбәр алынгач югалтмаска, кешегә бирмәскә вәгъдәләрен алдым.

Сезгә хәзер җибәргән нәрсәләрем:

1 – фарсы телендә бер нәзым китабы.

2 – фарсы телендә бер мәҗмәгъ, бәгъзе бер пәйгамбәрләр хәлен сөйләгәндән соң, имам Фәхреддин Разый хәлен сөйләсә кирәк.

3 – кыз сайлап алу хакында борынгы әһле гыйрфанның[2] тәүсыялары[3]. Һәм дә ахыры бер тыйбб китабы. Минем менә шу  формага сызган китабның ахырындагы урынларны караңыз.

4 – янә бер мәҗмәгъ – гарәбиел – гыйбарә, әллә нинди тылсымлар белән алдан хәбәр белдерә торган бер китабка охшай.

5 – адәм вә җенләрнең яратылуы хакында язылган бер хыялый әсәр.

6 – бер мәктүбдән копия.

7 – мәшһүр мөхәррир Габделкаюм Насыйриның иң беренче ташбасмада басдырган Русия харитасы.

8 – мал мәтрүкате[4] бүлү кәгазе – раздельная акт[5]

Бу почтада шу кадәр нәрсәләр җибәрдем. Янә табкан нәрсәләрем: бер җәя, 6 ук, бер Чыңгызхан печате, бер сугыш киеме кисәге (үрмә). Бер «Йосыф вә Зөләйха» кыйссасы. Бер «Мөхәммәдия» китабы. Янә үз авылымызның кыскача тарихы (язылып бетмәгән әле).

Сездән үземне гыйльми экспедициягә чакырырлар әле дип, бик көткән идем, булмады. Шулай да, бер форсат булганда Казанга барып, музейны күреп, танышып, кирәк нәрсәләрне белеп, ныклап бер азлап карарга дәрт бар әле.

Сездән полный программа[6] сорадым, җибәрмәдеңез. Хат язып, берничә сөальгә җавап сорадым, җавап бирмәдеңез. Үзем барып кайтырга уйладым инде.

Хәзергә хушыңыз.

---

[1] Мәнзум түгел, мәнсүр – тезмә түгел, чәчмә.

[2] Әһле гыйрфанның – гыйлем әһелләренең.

[3] Тәүсыялары – киңәшләре.

[4] Мәтрүкәте – мирасы.

[5] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[6] Кирилл хәрефләре белән язылган.

1930 ел, 9 июль, кустыгыз: Исмәгыйль Рәхмәтулин.

П./о. Уйское.Троицкого окр. Урал обл. Пос. Аминевское. Исмагилу Рахматуллину.

Хөрмәтле Сәедмөхәммәд ага

Сәламләрен улсын. Мин хәзергә сәламәт. Сезгә бундан элек бер посылка илә хат язып, сездән үземнең өмид иткән нәрсәләремне сораган идем. Ләкин үземдән тулы адрес бармый, миңа хат да, нәрсәләр дә җибәрмәңез дигән идем.

Имди мөмкин булса, түбәндәге адрес илә миңа, әгәр минем сотрудник[1] итсәңез, удостоверен.[2] һәм дә тулы программа, һәм дә мөмкин булса, миңа азрак акча җибәрүеңезне үтенәм. Бәлки, юл төшсә, үзем дә барып кайтырга уйлыйм. Ләкин кыш бараеммы? Җәй бараеммы? дип уйланам. Хушыңыз: Исмәгыйль.

Г. Челябинск. Пушкинская п. № 3. Н. Сагитову. И. Рахматуллину.

*Хатлар ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана: 53 фонд, 4 тасв., 19 сакл. бер., кәг-р. 68, 69, 70, 74, 75. Гарәп графикасында, татар телендә. Хатларның авторы Исмәгыйль Динмөхәммәд улы Рәхмәтуллин (1891 – ?)*

*Хатлар һәм текстларны гамәлдәге язуга күчереп, басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәс сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## Г. Алпаров хаты

Сәед абзый!

Саулыкны белдергәннән соң, сезнең дә саулыкны теләп калдык.

Мин Казанда чакта сез үзегездә татар матбугат спискасы җыентыгы барлыгын һәм кирәк табылганда ул җыентыкның күчермәсен – копиясен язып биреп укучы гыйлем әһелләрен файдаландырмакчы булганыгызны миңа сөйләгән идегез. Мин дә үз

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[2] Тулысы: удостоверение. Кирилл хәрефләре белән язылган.

нәүбәтемдә андый эшнең бик кирәкле, бик вакытлы икәнен белдергән идем.

Әнә шул матбугат тезмәсе безнең Ленин китапханәсендәге татар бүлеме өчен бик кирәк табыла. Шул әйбер- материалның сездә барлыгын мин эш башындагы иптәшләргә әйттем. Инде эш сездә тукталып калды. мин бу хатны шуның өчен ярым рәсми итеп идарә исемендән язам. Сез шул татар телендә чыккан матбугат тезмәсен безгә эшләп бирсәгез иде. Әгәр шул эшне башкарып бирергә риза булсагыз, безгә алдан шартларын белдерсәгез иде.

Кай чакларда өлгертеп бирә алырсыз, ул тезмәнең тулы булуын ничек тәртип итәрсез, урта чама белән күпмегә төшәр һәм башка шартлар. Әлбәттә, соңыннан үпкәләш булмасын өчен алдан кул сугышып куярга кирәк, эшкә җитди карау шуны кирәксенә.

Безнең өчен бүгеннән иң кирәк булганы китаплар тезмәсе, вакытлы матбугат мәсьәләсе ул алдагы эш, анысы хакында киләчәктә сүз ачылыр.

Язганда кирәкле булган графалар, минемчә, шулар:

Китапның язучысы (тәрҗемә булганда тәрҗемәчесе дә), китап исеме, нашире, басылган каласы һәм басылган елы. Башкалары, пожалуй, кирәк булмас.

Миңа шулар турында карашыгызны белдереп, түбәндәге адрес белән хәбәр итсәгез, яхшы булыр иде.

Шуның белән бергә үз хәлегезне дә кыска гына язып белдерсәгез, без шадмән булыр идек, кайда эшлисез, укытудамы, язу-сызудамы. Кайсы берәүләр конституциядагы «право на труд» дигән канунны җиңелгә санап, укыту эшендән чыгарырга булашып йөргән […][1] барлыгындан Казанда чагымда хәбәр алган идем, шуның өчен сорыйм.

Хәзердә сәлам дип адресым:

Москва, Центр. Библиотека им. Ленина, отдел национальностей, Алпарову. 1937, 17 март. Алпар.

*Г. Алпаровның С. Вахидигә хаты (53 ф., 4 тасв., 1 сакл. бер.) Татар телендә латин графикасында кара төстәге кара белән бик пөхтә, матур язылган*

[1] […] – танылмый.

## Сабирҗан Шакирҗан хаты

(Хатның сәламләү сүзләре язылган өлеше ертылган)

Сәламдән соң сүзем бу: «Кызыл Татарстан»ның 132 ендә Татарстан гаҗәебханәсенең көтебханә хозурында иске кулъязмалар кабул ителә дип бер сүз күренде. Минем үземдә әллә ничә еллар саклап йөргән берничә кулъязмаларым бар иде. 1) Шәркый Төркестан Яркәнт шәһәредә Мөхәммәд Баһадир Газихан хан тарафындан [...][1] дигән каһарманга яздырылып бирелгән ярлыг. Һиҗри 7 белән бер мең бер йөз йитмеш икедә язылган. Димәк 171 ел була. Ярлыг уйгур шивәсендә, хатты тәгъликъ белән калын кытай кәгазенә puталлап, бик чырайлык кылып язылган. Уртасында хөкүмәтнең кызыл мөһерләре бар. Моңа үз тарафымдан язылган изахым[2] да бар. Бу әсәр хәзергә минем кулымда. Сезгә фотограф рәсемен йибәрергә мөмкин. 2) Миндә бик кызык бер шәҗәрә бар. Чыңгыз хан һәм Аксак тимер тугрысында ишетелмәгән легендалар бар. Сезнең язган әдәбият тарихыңызда бер әсәр генә табылмады дигән сүзеңезне күргән идем. Менә инде дә шул әсәр миндә бар. Бу әсәр Чагатай шивәсендә язылган. Сезнең күрмәгән бер китабыңыз шул дип беләм. 3) Кашкар шәһәрендә язылган 328 еллык бер коръән һәм 300 еллык бер фикъһ китабы бар. 4) «Җиде байның җиде кызы – җидесе дә бер манер. Хәзрәткә барып әйткәч, хәер бирде бер талир» хикәясе бар бәете белән. 5) «Кутадгу белек»нең кулъязмасы табылып тора. Менә ибдәш, монда шундый әсәрләрне хили[3] генә тапканым буладыр. Әгәр дә мин шул нәрсәләрне йибәрсәм, миңа шулар өчен берәр нәрсә бирә алырсызмы, чөнки ул әсәрләрне табуда минем тарафдан аздыр-күбдер чыгымларым булды. Янә миндә ун мең юл казакъ халык әдәбияты һәм 4 мең юл уйгур халык әдәбияты да бар. Бер җавап көтәм. Адресым: гор. Алма-Ата, угол Советской и Киргизской. Сабирзяну Шакирзянову.

26 ел, 12 июль. Алма-Ата.

Сабирҗан Шакирҗан.

*С. Вахидигә Сабирҗан Шакирҗан хаты*
*(53 ф., 4 тасв., 19 сакл. бер., 21а кәг.)*
*Татар телендә гарәп графикасында көрән кара белән язылган*

---

[1] [...] – танылмый.

[2] Изахым – аңлатмам.

[3] Хили – байтак.

**Хәлилрахман Лотфи хаты**

13 нче март 1927 ел.

Фазыл мөхтәрәм Сәид хәзрәт!

Ихтирам илә барчаңызга сәлам күндереп, үзебезнең сәламәтлегемезне белдерәм. Җәнаб хак сезләрне һәм сәламәт әйләсен. Безнең әтрафда «грипп» дигән бер чир сәяхәт итә, барымызга да беркадәр кунак булып китде. Сезнең мәктүбеңезне алганга бераз вакыт булса да, шундый сәбәпләр аркылы җавап яза алмый тордым. Быел көз бик җүеш, һәрбер эш үз вакытындан кичегү сәбәпле, безнең мишәр ягында көзге мәҗлес каз бәйрәме дип йөртелә торган мәҗлесләр дә кышка калды. бу мәҗлесләр бик вак һәм бик аз доходлы булса да, муллалар шундан (отлучка) булырга ярамый. Көненә 7–8, хәтта 10 йортка кереп-чыгып үткәрәсен, аның өстенә быел халык бераз икмәкгә туйганлыкдан, өйләнү, кыз бирү, туй ясаулар да ялганып китеп, бу ел кышдан бер якга да брылырга бушап булмады. Казанга барып, сезнең кебек әхбабларны да зиярәт итеп булмады. Тормыша сез зарланган авыр шәраят артыгы белән бездә дә мәүҗүд[1]. Ләкин авылның садә тормышына ияләнеп китдек, артык зур мәсариф[2] белән тормыймыз, икмәк, ит, май кебек иң кирәкле нәрсәләрне сатып алмыйбыз, үзебезнең хуҗалыкдан хасыйл була. Кием-салымда да зур тәкәллефләр эшләмибез, шуның өчен хәзергә артык рухны төшермичә тыныч (тәгъбир дөрест булса) рәхәт үткәрәбез.

Сезнең тарихи сөальләреңезгә эшкә яраса вә ярамаса да үзем белгән бәгъзе бер җавапларны языйм. Безнең Буа вә Сембер әтрафында Сембер һәм Буа шәһәрләрен кертмәгәндә, таш мәсҗед барлыгы ишетелми. Безнең мишәрстанда агач мәсҗедләр бик күп, хәтта кирәгендән берничә өлеш артык дияргә була. Күплеге нисбәтендә вак, хәтта бәгъзе авылларда аның югары сузылган манарасы гына мәсҗед икәнен белдереп тора торган 9-10 аршинлы гади өйләрдән бер дә аермасыз мәсҗедләр бар, һәр авылның беренче мәсҗеде иң иске игътибар ителә, ләкин берничә мәртәбә тәгъмир ителгән[3] яки бөтенләй яңадан салынган. Үзебезнең Кече Чынлы авылындагы беренче мәсҗедне тикшерсәк, 2–3 кат яңартып тәгъмир ителгәнен беләләр, картлар телендә сөйләнә. Ләкин башлап салынган тарихын белүче юк вә һич төрле документлары да сакланмаган. Кече Чынлы

---

[1] Мәүҗүд – бар.

[2] Мәсариф – акча, чыгым.

[3] Тәгъмир ителгән – яңарылган.

авылына башлап 37 кеше килеп утырганын вә ул утыру мондан 250 еллар мөкаддәм булуын белдерә торган шәҗәрә вә язмалар бар, әмма мәсҗеднең кайчан башлап салынганын белүче юк. Һәрхәлдә, шул 250 елдан әүвәл түгел, аз булса да шундан соң икәне билгеле. Менә шул 250 ел вакыт эчендә Кече Чынлыда 9 данә мәсҗед салынган. Бу ел безнең авылдан аерылып күчеп утыручы (поселок) ларына бер мәсҗед салалар, аның белән ун була. Менә мишәрдә диннең никадәр куәтле икәнен шундан үлчәрсез. Башка авылларның утыру тарихын әйтә алмыйм, фәкать бездән 7 чакрым Зур Чынлы (5 мәсҗедле)ның утыруы бездән әүвәл диләр. Бездән 20 чакрым Иске Чокал авылы бар. Ул да Чынлыдан әүвәл утыруы сөйләнә.

Безнең тирәдә зуррак мәдрәсә тоткан фәкать ике кешене беләм. Берсе Буа якынында Норлат авылында Фәхретдин бине Мостай, заманында яхшы зур мәдрәсә тотып дәрес әйткән, байтак имам вә мөәзинләр чыккан. Урынында хәзер имам углы мирза Әкрәм Мостаев, икенчесе Иске Шәйморза авылында Әбүбәкер бине Яһүдә Габдеррәшидов. Бу адәм Мисырдан кайтып казыйлык вә кыйраәткә осталык белән шөһрәт тоткан заманында күп адәмләргә кыйраәт өйрәткән, зур мәдрәсә тоткан. Фәкать мәдрәсәсендә дә гыйлем кыйраәтдән башка голүм белән шөһрәте юк килүче талиб дә, фәкать кыйраәт өчен килгәнләр урынында хәзер мәхдүми Мөхәммәд Габдеррәшидов имам. Бу сөйләнгән затлар һәр икесе Мәрҗани шәкердләре булганлар. Мәрҗани рисаләсендә кыскача тәрҗемәи хәлләре бар, карарсын. Язган китаплардан тарихе мәгълүм булган иске китаплар барлыгын белмим. Кыяфәте белән искелекне күрсәткән, әмма язу тарихы мәгълүм түгел язма Хөласа, Кодури кебек фикъһ китаплары вә соңрак заманда язылган кульязмалар картрак, әмма муллаларда бар, ләкин аларның сезгә әһәмияте юкдыр.

Болгар-Казан ханлыклары вакытындан калган кабер ташлары барлыгын бу тирәдә ишеткәнем юк. Башкача сезгә материал булуы мәэмүл булган[1] хәбәрләр таба алмадым. Хөрмәт илә Чынлы авылында 2нче мәхәллә имамы Хәлилрахман Лотфи.

9 нчы рамазан, 1345.

*С. Вахидигә Хәлилрахман Лотфи хаты (53 ф., 4 тасв., 19 сакл. бер.). Татар телендә гарәп графикасында зәңгәр кара белән язылган*

[1] Мәэмүл булган – мөмкин булган.

**Сабирҗан бине Габделбәдиг-әл-Касыйм хаты**

Мөхтәрәм Сәид әфәнде хәзрәтләре.

Әссәламәгаләйкүм вә рәхмәтуллаһу вә бәрәкәтүһ.

Тараф фәкыйрьләре илә бер карт мөәррих тапдым. Мәзкүр зат Пошалым башының Галиәхмәт Галиәкбәр углы нам затдыр. Галиәхмәтнең углы Фазлиәхмәт исемле, Казанда ямшик йөртәдер. Фатиры Алат шаһы йортындадыр, углы Фазлиәхмәткә әйтеп куйсагыз, килгәндә мине күрсен дисәңез, барып күрешергә җиңелрәк булыр. Мин үзем дә аңа әйтдем, сез Казанга барганда Сәид хәзрәтне күреңез, ул сезнең бу сүзләреңезне сорашып, тарих китабына язар, дидем. Ярар, озакламый Казанга барасым бар, иншааллаһ, мин ул хәзрәтне күрермен, диде. Шактый мөһим хәбәрләре бар, Әзәк иле, Иябашы авыллары һәм дә Пошалым авыллары, Казанбаш авылларының тарихларына тәгаллекъле, яхшы гына хәбәрләр сөйләде, үзем язып алып сезгә бирергә дә уйладым, ләкин бердән мин мөәррих түгел, сания, башның бер дә эшләми торган вакыты, төрле якдан хәсрәт кайгы, фәкыйрь вә ма шөбһә, җыен рух төшергеч нәрсәләр бер башка җыелгач, ничек язарга кирәк, мәхәлләнең лөзүмләре кушылгач, тагын да баш бөтенләй катып каладыр. Мәзкүр Галиәхмәт мәхәлләмезгә килде дә, шунда бу сүзләрне сөйләде, аның атасы йөз егерме яшь яшәп вафат булган, Галиәхмәт шул атасындан ишетеп калган хәбәрләр дип сөйләде.

5 гыйнвар 1929 ел.

Мулла Сабирҗан бине Габделбәдиг-әл-Касыйм

*С. Вахидигә Мулла Сабирҗан бине Габделбәдиг-әл-Касыйм хаты (53 ф., 4 тасв., 19 сакл. бер.). Хат татар телендә гарәп графикасында кара төстәге кара белән язылган.*
*Хат астына С. Вахиди карандаш белән «мәзкүр бабай С. Вахиди янына килә алмады» дип язып куйган*

**Мөхәммәднур Нугай хаты**

3 март, 1929 сәнә.

Юкары Кодаш.

Шәһри Казанда дарелфөнүн хозурында тарих тикшерүче Сәидмөхәммәд Вахиди җәнабләренә

Сезнең 1928 ел 27 октябрь тарихлы бер тарихи анкетаңызны юлыкдым, янә 1929 ел 1 нче гыйнвар тарихлы бәнем үз исемемә җибәрмеш анкета юллы мәктүбеңезне дә юлыкыб, һәр икәвесен

укып мәфһүмен аңлагандан соң, бәгъзеләренә түбәндәге җавабларны язмак булдым.

Сез һәр ике мәктүбеңездә дә Гали вә Гариф Чокрыйлар хакында вә башка тарихлар хакында киң мәгълүмат сорыйсыз. Барчасына җаваб язарга мөмкин.

1. Гали Чокрыйның бу көндә хәятдә нинди якынлары бар дигән сөальгә җавап: Буа кантоны Югары Тәтешле волосте Иске Чокыр авылында Гали Чокрыйның тугма углы Ахунҗан хәзрәт халән[1] саг-исән. Гали Чокрыйның үз урыныда имам иде. Бу көнләрдә истифадә кылмыш иде. Янә 2. Юкары Тәтешле волосте Яңа Чокыр авылында Гали Чокрыйның углы Зарифҗан хәзрәтнең углы Фатихҗан мәхдүм атасы Зарифҗан хәзрәт урынында имам иде. 3. Бөре кантоны Кызылъяр волосте Акбулат авылының сабак имам Шаһидәүләт Әхмәдовның әһалисе Гали Чокрыйның сәлби кызы Мәрьям абыстай. 4 нче: Бөре кантоны Кызылъяр волосте Күрдем авылында Гали Чокрый углының углы Мөхәммәдәхнәф бине Гарифулла Чокрый Гарифулла Чокрыйның әһлиясе Нуриәсма абыстай саг вә исән.

II. Гали Чокрыйның үзендән соң калган әсәр каләмиясе бармы?

Җавап: Гали Чокрыйның үз гомерендә язган барча тәхрирәт каләмиясе мәзкүр Күрдем авылында ахун Гарифулла хәзрәтдә сакланып килә иде. 1925 ел июль числосында ут казасына очраб, күбесе тәләф булды[2]. Хәзер дә Гали Чокрыйның бәгъзе кулъязмаларын табарга мөмкин. 1925 ел июнь числосында ут казасынннан элек, Казанда тарих җәмгыятенә кирәк дия, Кәрим кушуы буенча Иске Казанчы авылының Салих Миндияров Гарифулла хәзрәтнең әһлиясе Әсма абыстайдан күп кенә кулъязмаларын алып киткән иделәр. Бу көнгә кадәр хәбәрдар дәгелмез (Әсма абыстайга соңра кайтару шарты илә алганлар иде). Гали Рәхимгә тапшырылган булырга кирәк.

III. Гали Чокрыйның бәлки тарихи мәүзугда язган әшгарьләре, тарихи әсәр каләмияләре дә булгандыр дигән сөальгә җавап: Гали Чокрыйның кулъязмаларындан Гарифулла Күрдеминең язмалары арасында «Тарих Боһрия»исемле бер кисәк языла башлаган вә Гарифулла Күрдеми гамь итә алмаган бер тарих нөсхәсе бар, ошбу кәгазьнең теге ягына бераз башлангычны вә бераз мөндәриҗәсене

[1] Халән – хәзерге вакытта.

[2] Тәләф булды – юкка чыкты.

күчерәмен. Янә: 1926 ел, 1 нче гыйнвар тарихлы мәктүбеңездәге бәгъзе бер сөальләргә түбәндә җавап язармын.

I. Гали Чокрыйның бәгъзе бер кульязмаларын табарга мөмкин.

II. Гали Чокрый вә Гариф Чокрыйларның тәрҗемәи хәлләре бер кемсә тарафындан да язылмаган. Мин үзем һәр икесенең тәрҗемәи хәлләрен язарга ниятем бар. Гариф Чокрыйның тәрҗемәи хәлен бераз яза да башлаганмын. Тәмам итүгә муафыйк була аламмы? Юкмы?

Вә башка сорамыш сөальләрнең башкасына җавар язарга мөмкин.

1929 ел милади 3 март. 1347 һиҗри 21 рамазан.

Югары Кодаш авылында: Мөхәммәднур бине Шаһимәрдан Нугаев.

Гарифулла бине Гали Чокрыйның «Башкорт ыруы» исемле тарихындан күчермә:

«Үз сүзем»

Кечкенә вакытымда мәрхүм атамның хәтер дәфтәр урынында язылган бер иске китап читендән күчереп алганмын. Болай: «1850 елларда шәкерд вакытымда казакъ чыгып, казакълар бәндин нәсел-нәсәбемне сорагандан бән ошбу исемләрне мөрәттәбән итеб йөрдем: бәнем адым Мөхәммәдгали, атам Габдессалих, аның атасы Габдулла, аның атасы Шәриф, аның атасы Көек би, аның атасы Күчүкән, аның атасы Бәрак, аның атасы Исәнхан, аның атасы Дәүләтбай, аның атасы Дәүләтъяр, аның атасы Кодайяр, аның атасы Кодай колый, аның атасы Дүрмән би, аның атасы Колмән би, аның атасы Чулман би, аның атасы Абдал би, аның атасы Карахан як Карагазиз исемле дигәч, Һу! Куй! Куй! Инде бусы төбдә нугай агасы, казакъ-башкорт тамырымыздан имәс! Әгәр нугай булса, атаһыны да әйтә белмәйде гуй! Нугайга әһел ыруы белән канда диб, ни-ник диб хубладылар. Нәслемезне Урал аръягы, иртыш буйларындан килгәнен сөйләб биргәч, соңында тәмам мәҗлесдә булган казакълар бәне бертугандан артык хушлаб, мулдәкә дип балаларын укытырга алып калдылар.

Бәнем бу язуымны көнләрдә бер көн атам күреп, янә тәхсин һәм догалар кылып, күргән саен нәсел-ыруымызны югарыдагы бабаларымызга йиткәнче төпченә торган иде. Яшем 6–7 чамаларында, язу-каләм тотарга белер-белмәс чагымдыр. Кыш көне мәдрәсәмездә укып, җәй көне атам бәне язу яздырыр иде. Үзенең тәэлифатларындан берсе «Тәварихе Боһария» исемле китабыны

күчереп алып, Казанга укырга киткән елымда китапчыларга биреп басдырмакчы булган идем. Ул вакытда мәрхүм Шиһаб хәзрәтнең «Мөстафадел-әхбар», Яңа Бистә Хөсәен хәзрәтнең «Казан тарихы», Каюм Насыйриның тарихлары чыгып, бән дә шулардан караштырып, җәй көне әткәмә «Тәварихе Боһария»сенең бәгъзе урынларын артдырырга, бәгъзеләрен киметергә дип алып кайтып бирдем дә, шул еллар солдатка китеп бардым. Анда җәй көне лагерьга чыкгач, берничә төнләр иркенләнгәндәй булып, әткәмнең «Тәварихе Болһария»сене почта белән соратып алдырдым. Атам байтак кына чорнау ясап, чуп-чубар итеп йибәргән. Аны янәдән акга күчереп җибәрдем, 4–5 еллар йөреп кайтып керсәм, бәне акга күчергәнне янә төзәтәм дип, нөсхә вә шәкъләр ясаштырып бетергән. Алай булса да дөрестләп бетерә алмаган. Урынына исемләргә дә кыймаган ахры, «Тәварихе Боһария»сене (Колгариф) дип бәңа багышлаган булса да, бән янәдән «Башкорт ыруы» дип исем кушдым. Асыл нөсхәдә Гарифулла бине Гали Чокрый да дип имза иткән.

Башкорт ыруның мөндәриҗәсе: Ыру=ыруг=яки ру= һәм руг =җорд=йорт) (Урал тавы, Җаек, мишәрләр, Венгрия, болгра, татар, алтай башкортлары, башкорт ханлыклары, нугай, Әгерҗе-Буа татарлары, гол, монгол, Финляндия), ор-өй, йорт, түбә, кала, ил, авыл, тура, кантон, башкорт ханлыклары, башкорт чирүе, башкорт акчаларының сурәте, башкорт ханларының таҗ-түбәтәйләре. Мондан башкасы бик күп.

Тарихның соңында нәсел вә нәсәбләре кайсы елда кайсы баба булган, аның угыллары кемләр идекен язып киткән. Асылындан дөрест күчердем: Юкары Кодаш авылында: Мөхәммәднур Нугай.

*С. Вахидигә Мөхәммәднур Нугай хаты (53 ф., 4 тасв., 19 сакл. бер., 42 кәг.). Татар телендә гарәп графикасында зәңгәр кара белән язылган*

## Хафиз Гали хаты

Сәидмөхәммәд Вахидовка!

Сезнең җибәргән анкетагыз буенча түбәндә язып бераз мәгълүмат бирмәк булам.

Татар җөмһүрияте Спас кантоны Базарлы Матак волосте Ямбакты авылының шәрык ягында авылдан чыгуга уң якда һәм суң якда ике зиярәтлек бар. Уң яктагысында иске бер таш бар, 5–6 га ватылган. Бу ташны Ямбакты картның кабере өстенә куелган таш диләр.

Суң якдагы зиярәтлекдә янә дүрт таш бар – икесе хәзерге көндә сәламәт, икесе ватылган. Бу ташларны Ямбакты картның янына күрешергә килгән вакытда вафат булган Галламә Дувани һәм шәех Хөсрәви исемендәге мосафир картларның зиярәте диләр. Ватылмаган ике ташның берсе калкытып, берсе казып язылган язу вә бик оста рәвешдә эшләнгән. Берсе яхшы укырлык хәлдә, язылу рәвеше шушылай: Әл-Хәкимулла әл-Галиәкбәр, дип, җирдән хәзер дә ташның биеклеге 2 аршин чамасында, җиргә керүе, ташның күләменә караганда, янә 2 аршин гөман итеlә, киңлеге биш чирек, калынлыгы ярты аршин.

Ямбакты үзе 3 мәхәлләле авыл. Беренче мәхәлләсе рәсмияткә кергәнче мәсҗеде 2 йөз ел я өч йөз ел булган диләр, гаир рәсми рәвешдә яшәгән. 2 нче мәхәллә мәсҗеде 1860 нчы елда гына салынган, 3 нче мәхәллә мәсҗеде 1878 нче елда салынып, бу мәсҗедне шул ук Ямбакты авылының Мөхәммәдгали, Гобәйдулла вә Мөхәммәдкәрим Шәрифовлар. Араларындан берсе өчен наемщик җаллаган булганлар да, шуларның наемщиклары солдатка алынмый калгач, үз араларындагы шартлары буенча наемщик акчасы югарыдагы мәзкүр 3 карендәшкә кайткач, ягъни кайтарылып бирелгәч, шул ук 3 кардәш үзара килешеп, шуңа мәсҗедне салганлар.

Янә Ямбакты авылы шул ук Ямбакты картның исеме буенча Ямбакты дип аталган. Ямбакты үзе бер чокыр урынга корылган. Ул вакытда тирә-ягы калын урман белән капланган булган. Моны 92 яшьлек атабыз Гали мулланың әйтүенә караганда, Ямбакты карт Болгардан русларның талау вә җәберләренә түзә алмыйча качып, русларның җәберендән яшеренер өчен урман уртасында бер чокырлы урынга килеп утырырга мәҗбүр булган. Руслар бу авылны Ямбухтин дип атыйлар. Гали мулланың сүзенә караганда, имеш Ямбакты картны син шул чокырга кадал дип әйткәнләр имеш. Янә шул ук карт мулланың сүзенә караганда, урман Болгардан башланып, Ямбакты аша узып, Балыклы Күл авылы аркылы Биләр дигән рус авылына барып тоташкан булган. Урман эчендән тар гына бер сукмак ясап, русларның җәберендән яшеренеп, Болгардан Ямбактыга, Ямбактыдан Яңа Балыклы Күлгә, андан Ташбилге, андан Биләр дигән авылга йөртә булганлар. Яңа Балыклы Күлдә һәм Гарәми исемендә бер хан булган. Бу хакда Яңа Балыклы Күл имамы бабамыз Равил хәзрәтдән күчереп яздым. Ул мәрхүм хәзерге көндә 125/27 яшь чамасында булыр иде. Ул әйтә иде: Балыклы Күлнең Матакка таба ягындагы чокырла-

ры авылдан 3 чакрым чамасында булыр, бу чокырлары Гарәми ханның крепосте булган. Руслар бу крепостьне яндырып-талап бетергәнләр диядер иде.

Янә 92 яшьлек атабыз хәтерендә сәламәт. Ул әйтә: Казанда Каюм Насыйрилар гасырында Гали дигән бер мәшһүр кеше булган. Ул үзе бик фәкыйрь булган. Фәкыйрь булуына карамасдан, яхшы гына матбугат дусты булган. Сатып алырга акчасы булмаганлыкдан, гәзит алучыларның ишек төпләренә барып, укылган гәзитләрне сорап, җыеп кайтып укый торган булган. Үзенең яхшы гына язылган әсәрләре дә булса кирәк. Шуның архивын Казанда тикшереп тапсагыз икән.

Югарыда зикер иткән Галләмә Дувани, Шәех Хөсрәви үзләре Болгарның яхшы голямәләрендән булганлар. Болар Болгарда вакытда Ямбакты карт белән бергә торганлар. Болгар руслар тарафындан кысрыкланган соңында Ямбакты бабай Ямбактыга күчкәч, болар да хаҗ нияте белән юлга чыгып, Ямбакты карт белән күрешергә килгән җирләрендә вафат булганлар. Аларның бер Ямбакты карт белән генә күрешү максуд булмаган, андан Балыклы Күл Гарәми хан белән һәм күрешү булган, ләкин максудларына наил була алмаганлар. Бу картларны 92 яшьлек Гали мулла үзендән карт булган кешеләрдән һәм ишетеп, Болгарның бик зур галимләрендән булган диеп сөйли, янә әйтә, Ямбакты карт үзенең кызын Ташбилге картның углына биргән дә, шул Ташбилге карт Ямбактыга кунак булып килгәндә мәзкүр Галламә Дувани вә шәех Хөсравиларның зиярәтенә кереп зиярәт итә булган. Шул ике картның күмелгән зиярәтен хәзерге көндә дә Ямбакты халкы Ташбилге өсте диләр.

Янә шул ук Гали мулланың сөйләвенә караганда, Ямбактының үзенә махсус яшел юан кәгазьдә язма тарихы һәм булган. Озынлыгы 4 вершок, иңе ике вершок ярым, калынлыгы 1 вершок чамасында. Бу тарих китабы китапчы Вәли Мөхәммәд Тәрҗеманида булырга кирәк, ди. Анарда булуның сәбәбе – Гали мулланың мөэзиненең углы Мөбарәкша Вәли Тәрҗеманида бер заман мөгаллимлек итде. Шул мөгаллимлек иткән заманда Вәли Тәрҗеманига бирдем диеп җавап биргән. Ул тарих шушы мөгаллим атасы Шафигъ мөэзиндә саклана булган. Шафигъ мөэзин үз вафаты соңында углы Мөбарәкшага калган булган. Шул чакда Спас затоны мөгаллиме Фоад Тәрҗемани бездән сорап язган иде. Без аңар каршы бераз мәгълүмат яздык,

бәлки шул Ямбакты тарихы китабы атасы Вәли Тәрҗеманидан аның кулына күчеп, шуның белән чагыштыру түгел микән.

Спас кантоны Ямбакты авылының Хафиз Гали.

*С. Вахидигә Хафиз Гали хаты (53 ф., 4 тасв., 19 сакл. бер., 98 кәг). Татар телендә гарәп графикасында кара төстәге кара белән язылган. Хат текстларын басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре Ләйлә Гарипова әзерләде*

**Татарстан Үзәк музее**
**Шәрекъ кульязмалар бүлеге мөдиренә**

Сезнең кульязмалар җыю турындагы анкетагызны алдык. Андагы сорауларга берәмләп җавап бирмичә генә гомуми рәвештә җавап язуны тиеш таптык.

Өлкәне өйрәнү, тарихи хатирәләрне җыю өстендә кызыксынып эшләүче иптәшләр бар. Алар кулында шактый кыйммәтле материаллар бар. Җөмләдән, мин үзем ул эш өстендә 18 елдан бирле эшләп киләм. Мин тарихи әһәмияте булган күп кенә материаллар җыйнадым. Ләкин аларны яну, югалудан саклау өчен чаралар таба алмадым. Ахырында, Бөгелмәдә татар клубы катында Шәрекъ музее исемендә бер нәрсә оештырып шунда сакларга мөмкин булуны уйлап, барлык нәрсәмне шунда бүләк иттем. Хәзер аннан җилләр исә, кая киткәнен белүче дә юк. Анда Гәбдрәхмән волостендәге Мачкара елгасы башыннан табылган айбалта (Чыңгыз гаскәре коралы) бар иде. Һәм Тымытык волосте Урсай авылында кантон булып торган[1] Нугайбәкнең 18 уклы, көмеш белән бизәлгән садагы[2], ау карчыгасы бәйләре бар иде. Екатерина II нең Урманай һәм Уразай дигән башкорт атамаларына карата язылган манифесты, Уразай һәм Урманай картның Чалпы авылына (Бөгелмә кантоны) биргән җир мөгаһәдәсе[3] бар иде. Алар, тагы шуның кебек кыйммәтле башка материаллар хәзер юклар. Озынлап язуның әһәмияте булса, мин анда тапшырган нәрсәләрнең барын да язармын.

Аннан башка минем кулымда тагын байтак нәрсә бар. Идел буеның беренче шагыйре саналган Мәүла Колыйның 1858 елда

---

[1] Кантон булып торган – туктап торган мәгънәсендә.

[2] Садагы – җәя һәм ук савыты.

[3] Мөгаһәдәсе – договоры, килешүе.

Вильдан мулла каләме белән күчерелгән китабы, Исмәгыйль сәяхәтнамәсенең башкорт болалары[1] чорында ук [...] ясауда гаепләнеп асылган Сәлимулла каләме белән язылган нөсхәседер.

1815 елда «Мөршидәи Хәмидә»[2] имзасы белән чыгарылган бер мәрсиясенең Мәүла Гыйрфан каләме белән язылганы очраса, Наполеонны Мәскәүдән куган башкорт, типтәр полкларының «Француз сугышы бәете» кебек тарихи зур кыйммәте булган нәрсәләр бар.

Аларны Үзәк музейга тапшырудан кире тормыйм, бары аларны әзерләү, табып кулга төшерү юлында азмы-күпме мәшәкатьләр йөкләргә туры килгән, моннан соң да туры киләчәк.

Менә шуларның мәшәкатьләре һәм чыгымнары өчен Үзәк музей билгеле бер микъдарда акчалата ярдәм итсә, һәм шундый материаллар җыю өчен махсус мандат бирсә, мин Татарстан Үзәк музее сотрудницы булып эшләргә һәм байтак кына тарихи легендалар, материаллар җыеп бирергә өстемә алам.

1929 ел. 8 декабрь. Ф.Туйкә

Бөгелмә. Ленин урамы. 131 йорт. Ф.Туйкә

*Хат 1930 елның 9 апрелендә С. Вахидигә үзенчәлекле шагыйрь, талантлы прозаик һәм драматург, тарихчы, фольклорчы, мәгърифәтче педагог Фазыл Туйкин (1887–1938) тарафыннан юлланган*
*Хат шакмаклы кәгазьгә зәңгәр төстәге кара белән язылган.*
*Гарәп графикасында, татар телендә.*
*Күләме 1 кәгазь, 2 биттән гыйбарәт*

**Татарстан җөмһүриятенең Үзәк музеена**
**С.Г. Вахиди иптәшкә**

Музей идарәсенен 1929 ел 23 сентябрендә тараткан анкетасына җавап язган идем. Минем җавапларыма каршы музей идарәсенең [19]30 ел 9 гыйнварендә 232 сан белән җибәргән мөрәҗәгатен мин бары 27 мартта гына алдым. Шунлыктан бу хатымны соңлап язган өчен мине гафу итегез!

1. Хәзерге көндә минем үз кулымда булган тарихи материаллар, бары язма әсәрләр генә. Шулар өстенә халыкның әдәби

---

[1] Болалары – фетнәләре, кузгалышлары.

[2] Бу мәрсиянең дөрес исеме: «Мәрсияи Хәмидә зәүҗәте Габдерәхим Болгари» .

фольклоры һәм тарихи гореф-гадәтләре, шаманизм хорафәтләре, кайбер тарихи вакыйгалар. Аларның содержаниеләрен киләчәктә язармын. Хәзергә үрнәк өчен кулымда булган материаллардан Үзәк музейга дүрт кисәк нәрсә җибәрдем:

1) Сали ага каләме белән язылган «Исмәгыйль сәяхәте»н эченә алган I санлы җыентык.

2) Мулла Гыйрфан каләме белән язылган «Мөршидәи Хәмидә»мәрсиясен эченә алган II санлы җыентык.

3) «Мәүла Колый»ны язучы Вильдан мулла каләме белән язылган III санлы җыентык.

4) «Француз сугышы бәете» 1858 елгы язманың копиясе.

Боларның кайчан кайдан табылулары, кайчан кем тарафыннан язылулары һәм эчләрендәге материалларның содержаниеләре, һәркайсы җыентыкның үз янына информация рәвешендә язылып теркәлгән.

Болар барысы да татар тарихы һәм татар әдәбияты тарихы өчен артык кыймматле материаллар. Музей идарәсе аларны үзе өчен әһәмиятле санаса, билгеле миңа бераз хак түләр. Кирәксез санаса, кайтарып бирер, югалтмас. Мин боларга ышанып калап.

2. Бөгелмә музеенда булып та, таралган тарихи әйберләр һәм коллекцияләре турында мәгълүмат җыям, тәмам итү белән язармын.

3. Бөгелмә кантонының тарихи урыннарын һәм тарихларын тикшерү дә дәвам итәм. Аларны системалы рәвештә язуны җәйге ял вакытына калдырырга мәҗбүрмен. Алар һәм анда табылган әйберләр турында язармын. Революция тарихына бәйле булган «Солдат вакыйгалары» Кама елгасы буеннан табылган мамонт сөякләре, Мачкара елгасы башыннан табылган асигәй-айбалталар[1], Ул мәсьәләләр өстендә эшләүне сорыйлар әле. Мин ул юлда эшләп материаллар җыеп ятам. Һәм байтак кына нәрсәләр ачылып баралар.

4. Мин Үзәк музейның вәкиле булып эшләргә каршы түгел. Теләсәгез, сезнең өчен кирәкле кеше саналсам, түләрсез.

Җәйге ял чорында урыннарга чыгып йөреп тикшерергә, кайбер тарихи материаллар өчен ияләренә дә акча түләргә кирәк була. Мин май, июнь айларында буш торам. Менә шул чакларымнан файдаланырга теләсәгез, бераз акча җибәрә алырсыз. Җилкәмдә 8 кешелек гаиләм булганлыктан, үз кесәмнән бер тиен дә тартырга

[1] Асигәй – секира (айбалта – борынгы корал).

теләмим. Ул чакта мин бар тапкан материалларны системага салып, төзеп музейга илтеп бирә алырмын.

5. Башка кантоннарда мондый эшләр белән кызыксынучыны хәзергә күрсәтә алмыйм. Ул исәпкә төшкәнем юк иде әле. Сорашып тапсам, күрсәтермен. Уфадан Әхәд Вильдановны күрсәтергә була. Башкорт тарихына бәйле материаллардан аның кулында байтак нәрсә бар иде. Ләкин күп еллардан күргәнем юк, адресын белмим. Ул Башкортстанны өйрәнү җәмгыятендә эшли булырга кирәк.

1930 ел. 9 апрель, Ф.Туйкә.
Бөгелмә, Ленин урамы, 131 йорт

*Хафиз Гали хаты Хат 1930 елның 9 апрелендә С. Вахидигә үзенчәлекле шагыйрь, талантлы прозаик һәм драматург, тарихчы, фольклорчы, мәгърифәтче педагог Фазыл Туйкин (1887–1938) тарафыннан язылган. Хат шакмаклы кәгазьгә зәңгәр төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 1 кәгазь, 2 биттән гыйбарәт.*

*Текстларны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Эльмера Галимҗанова әзерләде*

# СӘЕТ ВАХИДИ ТАБЫШЛАРЫ

## Сәхибгәрәй хан ярлыгы

### Ярлыкның хәзерге татарчасы

Әс-солтан әл-Гази Сәхибгәрәй (сүзем).

Әмирләргә, хәкимләргә, олы сәидләргә, ислам казыйларына, мөхтәрәм хуҗаларга, вәкаләт ияләренә, урынлардагы мәэмүрләргә, илчеләргә, бакчачы һәм көймәчеләргә, урам башлыкларына, тоткавыл вә тамгачыларга, барча ханлыкга һәм Казан ханлыгының барча өлкәләренә вә барча мәмләкәтләргә (алар бәла вә әфәтләргә тыныч булган иделәр) бу нишан (аларга) җиткәч, минем сүзем шушы: бу Мөхәммәд улы шәех Әхмәт, дәхи шәех Әхмәтнең улы Әбдал, дәхи Сәед Әхмәт энесе Мөхәммәднең улы Муса, Сәед улы Якуб энесе Буланыс, дәхи энесе Нурсәид, шушы җиде кеше безгә килеб баш ордылар. Борынгы хан агаларымыздан тархан булыб килгән кешеләр икән. Без дәхи мәрхәмәт кылыб, бу сөйләнгән кешеләрне Тәңре Тәгалә ризасы вә Мөхәммәд пәйгамбәрнең шәфәгате өчен тархан кылдык. Мондан соң бу сөйләнгән кешеләргә юлларында, өйләрендә, сәфәр чыкканда вә өйдә торган чакларында (кыскасы, һәрвакытта) аларның кешеләренә, җирләренә, йөк һәм хайванларына һич якынлык белән катышмасынлар, кагылмасынлар, ясак-клан, салыг мөсәмма салмасынлар. Кулыш, култыка, баҗ һәм хәреҗ-хәраҗәт алмасынлар. Мал вә милекләренә акча һәм җир-суларына кул озайтмасынлар. Өйләренә көчләп илче кунак кундырмасынлар. Авыл салымы, җир түләме, морҗа салымы алмасынлар. Азык-төлек вә хайван азыгы сорамасынлар. Һичбер якдан (аларга) кимчелек вә зарар тиермәсенләр. Буш чакларында тыныч торыб, кич-иртә, көндез һәм төндә безгә вә безнең нәселебезгә дога вә алкыш кылсынлар. Һичбер төрле көчләр кысынкылык вә зәхмәт, борчу тиермәсенләр. Бәс шулай (боерганның соңында) дия торыб, бу ярлыкны тыңламыйча, көчләү, кысынкылык, зәхмәт вә борчу тиергән кешеләрнең үзләренә яхшы булмас дип, ал нишанлы ярлык бирелде. Тарих тугыз йөздә, егерме тугызда мөбарәк сәфәр аеның унөченче көне иде.

**Ярлыкның русча тәрҗемәсе**

(Могущественного) воителя Сахиб-Гирея (слово) эмирам, хакимам, великим сеидам, кадиям (народным судьям), почетным лицам, уполномоченным лицам, чиновникам на местах, посланникам, садовым чиновникам, судовым чиновникам, полицейским чиновникам, чиновникам на заставах, таможенным чиновникам, всему населению, вообще всем Казанским областям и всем государствам, да будут они хранимы от бедствий и несчастий.

Когда до них дойдет этот приказ, слово мое таково: этот шейх-Ахмед, сын Мухаммеда, потом сын шейх Ахмеда Абдал, потом Сейид-Ахмед, его брата Мухаммеда сын Муса, Якуб сын Сейида, его брат Буланс, его брат Нур-Сейид – эти семь человек, пришедши к нам, били челом, что они были тарханами прежних наших старших ханах; мы вновь, пожаловав упомянутых лиц во имя великого Бога и ради пророка Мухаммеда, сделали их тарханами.

К названным лицам на дорогах, в жилищах, в пути, дома во всякое время, когда они – сидят и когда встают, к их крестьянам, поместьям, возам и скоту не смеют пусть прикоснуться злые намерения и не вмешиваются злые поступки и действия ни одного человека. Ясак, оброк, подать, именуемую «салыг» не взимать. Подать кулыш-култыка, таможенную пошлину, баж, харадж и хараджат не требовать.

К имуществу, собственности, деньгам, водам, землям никто рук пусть не протягивает. В дом их насильно посланников – гостей не ставить. Деревенскую подать, земельный налог, налог с трубы (с них) не собирать. Продовольствия, фуража не требовать. Ни с каких сторон вреда и притеснения (им) не причинять.

Пребывая в спокойствии, вечером, утром, днем и ночью они воссылали бы нам и нашим потомкам молитвы и добрые пожелания. А всякого рода насилия, – беды, вред, беспокойства (им) не причинять. Если же кто, не слушая повелений ярлыка, причинит насилие, беды, вред, беспокойство, то им хорошо не будет. В удостоверение чего пожалован ярлык с алой печатью.

Дата девятьсот двадцать девятого (929) года гиджри в 13 день священного месяца Сафара.

Печать: Во имя всемилостивого милосердного Бога, нет Бога кроме единого Бога., Мухаммед посланник божий.

Могущественный султан, знаменитый для мира и веры великий завоеватель Сахиб-Герей, герой хан пусть Бог вечно хранит его государство, возвеличит его царствование.

*53 ф., 1 тасв., 8 сакл. бер.*

## Элгәреге Спас кантоны Коры Көрнәле авылының (имамы) Нәбиулла Гайнулла углының 1929 елда язган шигырьләре

**Коръән кәрим**

Коръән өнди гадаләткә, нәфес өнди заляләткә,
Коръән юлына кергәнләр төшмәячәк һәлакәткә.
Коръән өнди яхшылыкга, нәфес өнди шакшылыкга,
Коръән юлына кергәнләр чыгар бер көн яктылыкга.
Коръән сөяр хаклыкны, ул телидер пакълекне,
Дәхи аның бер максуды – тели күңелнең сафлыкны.
Ак-пакъ һәм саф күңел белән укысаң син коръәнне,
Һич хатасыз кылачаксың ул Коръәндә кушканны.
Ихлас, Коръән сүзе бик тәмле, укучысы бик ямьле.
Ихлас белән укылса гәр, төшә тәнең вә җаның мәйле.
Коръән укысаң – агара синең каралган күңелең.
Бераз укымышың да булып, әгәр дә булса синең белмәк.
Белмәгәнне белдерәм дип бер ходамыз дәшәдер.

**Фәкыйрьлекнең зарары**

Бу фәкыйрьлек яман нәрсә икәндер, мин белмәдем.
Мондин начар, мондин яманны һич дә мин күрмәдем.
Гыйбадәтдә ләззәт булмый, дөньәгәр тар булса,
Рухың тәмам төшә икән кайгы-хәсрәтең булса,
Фәкыйрьлекдән сакланыгыз дип әйтәмен сезләргә
Чөнки аның ачылыгы килгән иде безләргә.
Түшәгеңә күрә генә аяк сузу кирәкдер.
Икътисад белән торучы бу дөньяда сирәктер.
Бу фәкыйрьлекнең килүе икътисад юклыгындан
Хак Тәгаләне зикердән күңелемнең бушлыгындан.
Фәкыйрь булсаң синдән качар бөтен ага-энеләр,

Үзләре тук булган өчен синең хәлне белмиләр.
Дәхи бер кабих сыйфат бар – ялкаулыкдыр элгәре
Ялкауларны тикшереп карап тормыш сез күрегез
Бу фәкыйрьлекнең килүе әнә шул ялкаулыкдан.
Бәхет дәүләтнең килүе синең күңелең саулыкдан.
Сакларга бик кирәк икән бу күңелнең саулыгын,
Саклап бик нык тотар өчен тазарак иш баулыгын.
Рухыңны һич төшермә дөньяда яшим дисәң.
Фәкыйрьлекнең яманлыгын син тәкъкылалсаң.
Бу фәкыйрьлекдән дә яман дөньяда һич нәрсә юк.
Киләчәк көнендә кайгырт, булсаң әгәр бүген тук.
Алдагы көнне кайгырту бигрәк дә кирәк икән,
Бүген сиңа күбме кирәк, иртәгә дә шулай икән.

*Нәбиулла Гайнулла улының шигырьләр дәфтәре 10 биттән тора (Ф. 53. 5 тасв. 26 сакл. бер). Татар телендә гарәп графикасында кара, кызыл, зәңгәрсу кара белән язылган. Биредә аның шулай ук «Хакыйкать», «Игътикад» исемендәге шигырьләре белән танышырырга мөмкин.*

*Текстларны басмага ТР ФА Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Л. Гарипова әзерләде*

**Зөлхәбирә бәете**

Тәкъдир илә каләм язды бән фәкыйрьнең газиз башына
Түзмәенчә нә чарадыр бер алланың эшенә.
Мостафа мулла атлар җигә кара дуга катырып,
Мостафа мулла йөри икән түрә кияүләрен чакырып.
Зөлхәбирә йыглаб һай әйтәдер: «Түкдең, әткәм, күздән яшем» дип,
Мостафа мулла һай итебдер, Хода сиңа шулай язган дип.
Мостафа мулла атларының җөгәнләрен җиздән ясаган
Әткәсе аның шулай дигәч, Зөлхәбирә йыглый башлаган.
Мостафа хатыны һай, йыглай, Зөлхәбирә кара кашым, дип.
Зөлхәбирә әнкәсенә һай итәдер, вәйран булды газиз башым, дип,
Күб җиһанларга фаш булды Зөлхәбирә дигән атларым.
Тәмамлана унике, һай, яшем бән, вәйран булды газиз башларым.
Сибәләп ягмур, һай, яуганда, уйсуларгы сулар тулды ла.
Зөлхәбирәнең йыглай-йыглай, гөл тик нурлы йөзе сылу ла

Мостафа мулла ишек алларында кычкырыша кытай казлары
Зөлхәбирәнең, һай, кашына җыелышды авыл кызлары.
Зөлхәбирә салават, һай, әйтәдер, бәхил булыңыз бездин, кызлардин
Зөлхәбирә өзелеп һай итәдер, кая әткәм бәнем киемем дип.
Зөлхәбирә әнкәсенә һай итәдер, гыйбрәт итеңез бездин кызлар дип,
Зөлхәбирә тилмереб һай йыглыйдыр, калды туган-үскән йирем дип.
Әнкәсе өзелеп, һай, йыглыйдыр, Зөлхәбирә әйткән сүзенә
Әнкәсе йөзен куеп йыглай Зөлхәбирә синең йөзеңә.
Мостафа мулла йөгереп чыкды түрәләргә атлар җигим дип,
Зөлхәбирә әнкәсенә һай итәдер, газиз әнкәм, бәхил улыңыз, дип.
Мостафа мулла өендән тугыз түрә чыкды тезелеп,
Зөлхәбирә, һай, киткәндә әнкәсе калды өзелеп,
Мостафа мулла, һай, өендән тукыз түрә чыкды җырлашып,
Зөлхәбирәнең туганлары карап калды тилмереп, йыглашып.
Тукыз түрәнең арасында Зөлхәбирә утырып барадыр,
Зөлхәбирә, һай, киттең, дип, әнкәсе йыглап каладыр,
Исправникның атларының тезгенләре аның җизләрдән
Күп кешеләргә гыйбрәт булды гариб мескен безләрдин.
Тукыз түрәнең, һай, атлары, берсе – кара, берсе – аладыр,
Зөлхәбирәне яклап бакган тилмереп үк йыглап барадыр.
Ак күгәрченләр гөрләп очар Мостафа мулла өенең түрендән
Мөлдерәп-мөлдерәп яшьләр ага Зөлхәбирә синең күзләрдин.
Зөлхәбирә йыглап, һай, барадыр туган-үскән йирем кала дип,
Зөлхәбирә әткәсенә, һай, әйтәдер, кяферләргә бәне сатдың дип.
Мостафа мулла өенең чарлаклары тоташ пыяла,
Зөлхәбирәнең әнкәсе йыглый торгач булды дивана.
Мостафа мулла ак чалмасын өйгә кертеп куйды ла,
Җан тик күргән, һай, баласын кяферләргә тоткын кылды ла,
Башымдагы яулыгым җилләр генә исеп алды ла
Үз әткәм үз баласын җана торган утка салды ла.
Мостафа мулла намаз укый, тәкбирләрен әйтми калдырган
Исправник кызын алгач, указларын кулындин алдырган.
Мостафа мулланың, һай, казлары йөзеп бара каршы тулкынга,
Бән фәкыйрь бичарасын Хода салды үзе тоткынга.
Мостафа мулла, һай, хатыны су саладыр комганга
Мостафа мулла йөзе кара, үз башын салды зинданга.
Ак Иделләрнең, һай, буенда Зөлхәбирә керләр юды ла.

Газиз этләм карта уйнап кяферләргә тоткын кылды ла.
Мостафа мулла ындырында тукыз кибән түрендә
Мостафа мулла кызының, һай, тукыз гына түрә туенда.
Зөлхәбирә күлмәк тектергән, итәгенә тасма тотдырган,
Мостафа мулла – йөзе кара, карта уйнап кызын оттырган.
Зөлхәбирә тилмерә, һай, йыглыйдыр, исправник кяфер өендә.
Кызыл аяклы күк күгәрчен ля-илаһә иллаһ дип очадыр.
Озын сачле исправник Зөлхәбирә, диде, кочадыр,
Чүлмәк дә чиләк, һай, каймакга күмәч кенә баскан бар микән,
Күмәч дә ашап, чәйләр эчеб кызын саткан бар микән.
Зөлхәбирә күлмәк, һай, тектергән, изүенә ука чиктергән,
Зөлхәбирә чиркәүгә кергәчдин ислам динен шунда бетергән.
Мостафа мулла, һай, капкасы ачылмай тора җабылып,
Зөлхәбирә тилмереб йыглайдыр туган-үскән йирен сагынып.
Озын сачле исправник Зөлхәбирә матур янында,
Зөлхәбирә буылып, һай, йыглайдыр чиркәү генә ишек алдында.
Зөлхәбирә диндән, һай, чыгыпдыр чиркәүгә генә кергән чагында
Зөлхәбирә чиркәүгә кергәндә очып китде иман нурлары
Кыйкак да кыйкак казлар оча канатларын талдырып.
Зөлхәбирә чиркәүгә кергәндер ислам гына динен калдырып.
Исправник кәгазь тоткандыр, кире генә якдан сызгандыр.
Зөлхәбирәнең хак динен исправник тилмертеп бозгандыр.
Исправник, һай, кергәндер Зөлхәбирә сылу куенына,
Зөлхәбирә пычак салгандыр исправникның муенына.
Сандугач сайрый башлыйдыр төн уртасы дигән вакытда,
Зөлхәбирә чыгып качкандыр төн уртасы дигән вакытда.
Зөлхәбирә качып бара торгач, йитде ике Идел катына,
Зөлхәбирә күбрәк йыглай торгач, йитде исправник башына.
Унике кеше төшкәндер Зөлхәбирә йөргән эзләргә,
Төн урталары, һай, йиткәндә, Зөлхәбирә чыгып качды ла.
Унике кеше җөри торгач, Зөлхәбирәне тапды ла.

*«Зөлхәбирә бәете» зәңгәр кара белән татар телендә*
*гарәп шрифтендә язылган*
*(53 Ф., 5 тасв., 30 сакл. бер.)*

**Татарские легенды**
**о прошлом Камско-Волжского края**

(записанные С.Г. Вахидовым)

Устные предания о городе Булгар

У пророка Ноя было три сына и один из них по имени Яфет.

У Яфета было три сына: Гази, Турк и Алп. Сыновья Яфета выросли красивыми, крепкими и здоровыми. Через некоторое время их начал подстрекать шайтан и они поссорились между собою. Ссора их продолжалась долгое время. Затем дело приняло большие размеры.

Между братьями Газием и Турком началась война. Гази был побеждён Турком...

После этой войны старший и младший брат не могли жить вместе.

Турк, хотя и был победителем, после такой вражды, предпочёл удалиться подальше. Он отправился в далёкую страну и поселился около большой реки в холодной стране. Эта река в те времена не имела ещё названия.

Алп был человек храбрый, если он серьёзно возмётся в дело мог опрокинуть горы поменьше и одной рукой поднять лошадей и коров. Местность, где они поселились была болотистая и покрыта дремучими лесами. Поэтому когда Алп странствовал в ненастную погоду его лапоть наполнялся сырой землёй, а в хорошую – пылью и мешал Алпу во время ходьбы. Алп время от времени останавливался и стряхивал с лапоти пыль и грязь. От последних образовались на ровных местах около дорог кругленькие холмики.

Говорят, что те горки, которые встречаются по большой дороге из села Биктемир в Матаки, образовались от той земли, которая выпала из лаптей Алпа.

Однажды этот богатырь Алп охотился. Тогда леса были большие и простирались на бесконечно большие расстояния. Долго он охотился и наконец заблудился в этом дремучем лесу, но не мог вернуться к своему брату Турку.

После долгого скитания по лесам он вышел к берегу одной реки. На том берегу жили люди, знавшие язык Алпов, но люди совершенно другой породы.

Так как они понимали друг друга, эти люди стали разговаривать между собою. Понятно, что когда Алп не мог вернуться к своему брату Турку, начал жить вместе с этими людьми. Алп, наконец,

совершенно свыкся с этими людьми. Он выбрал из их среды одну девицу и женился на ней. Алп, таким образом, считался местным жителем и начал жить.

Алп имел двух сыновей, но никак не мог придумать им имени, потому что тогда те люди жили тем, что им было известно.

Это случилось в тёплые летние дни, люди жили в кочевьях в войлочных кибитках. Вдруг изменилась погода: небо покрылось тучами, похолодало…

Один из детей Алпа начал рыдать от холода. Дети эти плакали, болтая руками. Алпу грустно стало от их плача и он стал их убаюкивать и качать люльку, пел разные колыбельные песни, а дети всё не успокаивались, не переставали плакать; плакали они, болтая руками.

Плач детей наводил Алпа на одну мысль: «Эти дети не напрасно плачут, это уже слишком! В этом плаче что-нибудь-то кроется!»

Долго он думал об этом и вспомнил, что а может быть они плачут потому, что они не имеют имени, после наречения имени они перестанут плакать. Он решил дать своим детям имя.

Посоветовался со своей женой и так как плача они болтали руками, нарекли им имя «Булгар».

Таким образом «Алп – батыр» имел сына по имени «Булгар». Затем сократили звук «у» и стали произносить «Блгар». Это новое имя очень понравилось самому Алпу и его жене. Они решили и второго сына именем похожим на «Булгар». Муж с женой долго думали об этом, долго советовались, проводили над этим вопросом много времени и, наконец, решили дать ему имя «Буртас». Слово «буртас» также было сокращено и стали говорить только «Бртас».

Сыновья Алпа выросли такими же богатырями, как он сам. Сыновья его стали жить вместе с родителями. Когда они выросли и возмужали, построили в разных местах два города и жили там.

Город построенный первым сыном стал славиться под названием «Булгар». Тысячелетиями там жили многие славные ханы. А тот «Булгар», что расположен около Волги и от которого в настоящее время остались одни жалкие развалины, рассказывают, был и тем городом Булгар, основанный первым сыном Алпа.

Также и другой город, основанный Буртасом по имени второго сына Алп – богатыря стал также славится как и первый город.

Поколение населения этих двух городов сильно размножилось и после многих лет образовали два народа из одного и того же рода: это и были родственными народами Булгар и Буртас. Сначала оба эти народа говорили на одном и том же языке, прошли годы и языки их отдалились немного. Сын Алпа долго смотрел на реку Волгу. Она в летний жаркий день своим дрожанием и зыбью напомнила Булгару «ит – тиле» – «собачий язык» и поэтому он назвал её «Иттиле». А так как произносить это было трудно, то стали говорить только «Итиль», а потом уж превратился в «Идель».

*Отдел рукописей и редких книг Научной библиотеки им. Н.И. Лобачевского*

**Кыргыз һәм дә башкорд басмалыгы хакында**[1]

(риваять)

Урал (Җаек), Уй суларының җөнүбе шәркый ягы кыргыз, әмма шимале, гарби яклары башкорд йирләре булган. Бу ике таифә[2] халык һәр икесе мал асраучылык илә көн күреп, һәр икесе җәнгавер халык[3] булдыгындан, бер-берсенең малын – җылкысын, кыз вә киленчәкләрне басып – әйдәп алып китү – җегетлекдән саналган. Күбрәк вакыт кыргызлар башкордларга һөҗүм идеп, башкордлар мөдафәга[4] юлын тотканлар. Кыргызларның кинәт һөҗүмендән йөдәгән башкордлар, кыргызлар килеп басмасын өчен сима (каен агачыны дуга формасында бөгеп, бер-беренә махсус формада бәйләп кую) тотканлар. Шул симаны һәр көн иртә илә барлап торганлар. Әгәр сима бозылса, ул көн хатын-кыз бала-чагалар куналка (кич җыеылып куну) га җыелганлар. Һәм дә Олы тау, Кош тау, Кара агач түбә, Йелекледәй вә башка зур тауларның башларында басмачы кыргызлар чакма чагып бер-берсе илә ут белән хәбәрләшкәнләр.

[1] Түбәндә китерелгән ике язма И. Рәхмәтуллин хатлары арасыннан чыкты. Гарәп графикасында татар телендә. Кайсы вакытта язылып һәм кайсы хаты белән килгәне төгәл мәгълүм түгел.

[2] Таифә – төркем.

[3] Җәнгавер халык – сугышчан халык.

[4] Мөдафәга – каршы тору.

Көндез караганда сима бозылса һәм дә шул көнне төнен тау башларында чакма уты күренсә, ул төнне, мотлакан[1], баскынлык булган. Ул төнне ир-җегетләр йокламасдан, яхшы атларга менеп, кыргызлар әйдәп барган малны алып калыр өчен «орыш» кылганлар. Орышда корал: мылтык, ук-садак, корык, найза, хәнҗәр, бау (кыл аркан) илә булган. Мәзкүр[2] кораллар илә орышып, әсир төшкәнләрен бау илә бәйләп алганлар.

Орышда яуны Таң аткан (Варна районы Редут авылының шәркы шималендә бер кечкенә көтерле елга суның исеме) га кадәр куганлар. Әгәр кыргызлар әйдәп алган малларын таң атып яктырганга кадәр, Таң аткан елгасын ашырып алып китсәләр, мал кыргызныкы, әгәр Таң аткан елгасын ашыра алмасалар, кыргызлар малны ташлап үзләре кача торган булганлар. Ул вакыт мал башкордларныкы булган. Шуңар күрә дә ул елганың исемен «Таң аткан» куйганлар. Хәзер дә шул исем илә йөри.

Соңра малы таланган халык Барымтага барганлар.

(Барымтаны икенче вакыт язармын)

## Гөлбикә кыйссасы

(вакыйгъ[3])

Кыргыз-башкорд басмалыгында бер мал гына түгел, хатын-кызлар да зур роль уйнаганлар. Күбрәк, кыргызларның горефенчә, калым малы түләп алырга хәле җитмәгәне, ярлыбатрак, сазаган (күб яшәгән) егетләре килеп, башкордларның яшь киленләрен, яки тугъры килсә кызларын басып алып киткәнләр. Гадәттә малны төнен бассалар, кыз-хатынны көпәкөндез, җиләк, чия җыеп йөргән вакытларында басып алып киткәнләр. (Хәзерге көндә дә хатын-кызлар җиләк, чия җыйган вакытларында, «әнә каскы[4] килә, әнә каскы килә», диб берберен куркытып, йөгереп китүләр бар). Шул кыргыз качаклары тарафындан басылып алып кителгән хатын-кызлар җөмләсендән мәшһүррәге Гөлбикә апай.

---

[1] Мотлакан – һичшиксез.

[2] Мәзкүр – алды искә алынган.

[3] Вакыйгъ – булга хәл.

[4] Каскы – качкын.

Гөлбикә апай яшь килен вакытында өендәге эш-көшдән бушангач, чия җыерга дип челек – каен агачлар арасына китә. Чия җыеп йөргәндә, уйламасдан өзәнге тавышы чылдырап, бер касак кыргыз килеп, Гөлбикә апаны бауга салып алып, авызына (кычкырмасын өчен) чүпрәк тыга да, челекгә алып кереп китә. Гөлбикә апаның ибдәшләре йөгереп авылга кайтып хәбәр бирсәләр дә, файда чыкмый. Кыргыз үз иленә алып кайткач, Гөлбикә апаны бауда асрый. Кич куенына ала. Гөлбикә апа күп еллар шулай газап чигеп гомерен уздыра. Бер көн куй көтәргә дип чыкган йирендән качып китә дә, артындан кыргызы куып җитеп, тотып алып кайтып, аяк табанын буена пычак илә ярып, җәрәхәтенә тоз сала. Җәрәхәт бозылып янә күп еллар Гөлбикә апа аксап йөреп көнләрен газап илә уздыра. Янә кыргыз өйдә юк вакытда Гөлбикә апа бераз эремчек (творог[1]) алып, янә туган үскән иленә качып китә. Янә артындан кугын чыга. Кугын килгәнен сизеп, Гөлбикә апа Мүкле күлнең мүге астына кереп югала. 3 нче көн кыргыз киткәч, Мүкле күлдән чыгып, Җидегән йолдызындагы Тимер казык йолдызын уң иңбашына тотып, көндезләрен ятып ял итеп, төнләрен китеп, илгә килә.

*Хатлар һәм текстларны гамәлдәге язуга күчереп, басмага ТР ФА Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәс сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.

*Саид Вахиди*
*(Вахидов Саид Габдулманнанович)*
*31.05.1887–5.01.1938*





*Тезисы доклада.*
*Автограф С. Вахиди.*
*ЦПиМН ИЯЛИ*
*им. Г. Ибрагимова АН РТ.*
*Ф. 53. Оп. 1. Ед. хр. 27*



*С. Вахиди. Первая страница статьи «Каюм Насыйриның яңа табылган документ һәм кульъязмалары» («Недавно найденные документы и рукописи Каюма Насыри») Ф. 53. Оп. 1. Ед. хр. 24*



*Письмо академика И. Крачковского. Ф. 53. Оп. 1. Ед. хр. 1*

*Письмо академика*
*А. Самойловича.*
*Ф. 53. Оп. 1. Ед. хр. 1*





*Письмо*
*Галимджана Баруди.*
*Ф. 53. Оп. 1. Ед. хр. 68*



*Ярлык хана Сахиб-Гирея. 1523 г. Из фондов Национального музея Республики Татарстан*

*Письмо Габдельбари Габбасовича, имама г. Петропавловска, кадию Габдельджаббару в д. Кушер. 1850 г. Документ из коллекции С. Вахиди. Ф. 53. Оп. 1. Ед. хр. 65*





*Свидетельство о заключении брака. Документ из коллекции С. Вахиди. Ф. 53. Оп. 1. Ед. хр. 8*



*Документ о разделе имущества с личной печатью С. Вахиди. Из коллекции С. Вахиди. Ф. 53. Оп. 1. Ед. хр. 13*



*Сертификаты об образовании из коллекции С. Вахиди.*
*Ф. 53. Оп. 2. Ед. хр. 1*



*Фотографии намогильных камней из коллекции С. Вахиди. Ф. 53. Оп. 1. Ед. хр. 71*







*С. Вахиди (первый слева) среди коллег. Ф. 53. Оп. 4. Ед. хр. 22*



*Первая страница воспоминаний «Түнтәр авылы тарихы» («История деревни Тюнтар»). Ф. 53. Оп. 1. Ед. хр. 46*

## СОДЕРЖАНИЕ


КЕРЕШ СҮЗ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5

СӘЕТ ВАХИДИНЕҢ ТОРМЫШ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ЮЛЫ . . . . 7

Автобиография историка и археографа Татарии Сейида Габдульминановича ВАХИДОВА . . . . . . . . . . . . . . . . . 8

Мәгариф эшләре хакында мәҗлес . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24

Мәрҗани көтебханәсе һәм аның соңгы язмышы . . . . . . . . 26

С. Вахиди тарафыннан төзелгән анкета . . . . . . . . . . . . . . . . 36

Сәед Габделманнан углы Вахидинең хатирә дәфтәрендән бер кисәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41

Спас кантоны авылларына оештырылган 1928 елгы экспедиция материалларыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73

С. Вахидинең 1934 елда Әтнә районына оештырылган археографик экспедиция турында истәлекләре . . . . . . . . . . . . . 93

Татарстан Гыйльми Үзәк рәисе ипдәш С. Атнагуловка С.Г. Вахидидән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104

К изучению ярлыков татарских ханов . . . . . . . . . . . . . . . . . 106

Перевод ярлыка золотоордынского хана Токтамыша . . . . . 116

Хәзердә ярлыкның төб нөсхәсе кайда саклана . . . . . . . . . . 118

XI йөз кульъязмасы «Тәҗареб-әл-Өмәм» (906 елда язылган кульъязма) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121

Гибнут исторические памятники . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129

Рукопись XIV века «Нахджел-фарадис» . . . . . . . . . . . . . . . 130

Беспризорные памятники старины . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131

Председателю Татцика тов. Байчурину от научного работника, историка и археографа Вахидова Саида Габдулминановича Докладная записка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132

В Казанский горсоветчлена Комиссии по охране памятников старины революции и искусства при Казгорсовете С.Г. Вахидова Докладная записка . . . . . . . . . 140

Хәзрәткә кем корреспондентлык билеты биргән . . . . . . . . . 144

Докладная записка научного работника историка-археографа Татарии С.Г. Вахидова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146

СӘЕТ ВАХИДИ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ: АРХИВ ҺӘМ ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТ ЯЗМАЛАРЫ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

Нахождение важных исторических документов древнего Казанского Ханства . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175

Открытие С.Г. Вахидова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176

Историческая ценность . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177

О ярлыке Сахиб-Гирей хана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
Ценное пожертвование в музей Татреспублики . . . . . . . . . 180
Официальная благодарность академцентра ТНКП, объявленная С.Г. Вахидову в газете «Кызыл Татарстан» от 15/02.25 г. За № 37 (1207) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Татар феодализмын өйрәнүгә зур материал . . . . . . . . . . . . 182
Гыйльми үзәкнең рәхмәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Гыйльми җыелыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Уртак җыелыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183
Отзыв о докладе С.Г. Вахидова «О ярлыке Сахиб-Гирей хана» в объединенном заседании О-ва татароведения и О-ва Истории, Археологии и Этнографии при Гос. Университете имени Ленина . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183
Отзыв известного тюрколога профессора А. Самойловича о научном труде С.Г. Вахидова «О ярлыке Сахиб-Гирей хана» 184
Отзыв профессора Н.Н. Фирсова о научном труде С.Г. Вахидова Исследование ярлыка Сахиб-Гирея Хана . . . . . . 184
Отзыв проф. Н.Н. Фирсова о научном труде С.Г. Вахидова татарские легенды о прошлом Волжско-Камского края. Казань 1925 г. Казань в легендах . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
Ценная находка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189
Отзыв профессора Московского Университета Ильи Николаевича Бороздина о научно-исследовательской работе С.Г. Вахидова (Вахиди), 30 июля 1929 г. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
Минзәлә кантонын тарихи яктан өйрәнү . . . . . . . . . . . . . . . . 191
Каюм Насыйриның яңа табылган документ һәм кульязмалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Тарих материалларын җыйнау юлында . . . . . . . . . . . . . . . 194
Археологическая экспедиция Академии наук . . . . . . . . . . . 194
Рукописи прошлого . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
«Кабуснамэ» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 196
Коллекции восточных рукописей . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 196
Памятники Золотой Орды . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 197
Рукописи Золотой Орды . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 197
Археографическая экспедиция академии наук . . . . . . . . . . 198
Официальная благодарность Академии Наук Союза Советских Социалистических Республик от 15/VI-1934 г. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 199
Академия Наук СССР от 16 июня 1934 г. № 62-71 . . . . . . 199
ВЫПИСКА из протокола № 5 заседания дирекции Института Востоковедения Академии Наук СССР . . . . . . . . . 200

Институт Востоковедения Академии Наук СССР
28 апреля 1934 г. № VIII-19 . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201
Академия Наук СССР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201
Хәлил Латыйпов истәлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201
Бакый Урманче истәлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204
СӘЕТ ВАХИДИ ФОНДЫНДА ХАТЛАР . . . . . . . . . . . . 205
Глубокоуважаемому Академику Крачковскому . . . . . . . . . . 206
Глубокоуважаемому Академику Крачковскому . . . . . . . . . . 207
Глубокоуважаемый Алексей Максимович . . . . . . . . . . . . . . 209
Уважаемый Феликс Яковлевич . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 210
В. Зәбировка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 212
В Институт литературы им. М. Горького . . . . . . . . . . . . . . 213
Глубокоуважаемый тов. Алпаров . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 220
Сәет Вахидигә килгән хатлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 221
В.Г. Ян-Янчевецкий хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 221
А.Н. Самойлович хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 222
Л. Пасынков хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 222
Җәлал Мөхәммәдиев хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 229
З. Галиәкбәров хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 231
Мирза Габдеррахман Зәбири хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . 234
Исмәгыйль Рәхмәтуллин хатлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 235
Г. Алпаров хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 241
Сабирҗан Шакирҗан хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 243
Хәлилрахман Лотфи хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 244
Сабирҗан бине Габделбәдиг-әл-Касыйм хаты . . . . . . . . . . 246
Мөхәммәднур Нугай хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 246
Хафиз Гали хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 249
Татарстан Үзәк музее Шәрекъ кульъязмалар бүлеге
мөдиренә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 252
Татарстан җөмһүриятенең Үзәк музеена
С.Г. Вахиди иптәшкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 253
СӘЕТ ВАХИДИ ТАБЫШЛАРЫ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 256
Сәхибгәрәй хан ярлыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 256
Элгәреге Спас кантоны Коры Көрнәле авылының
(имамы) Нәбиулла Гайнулла углының
1929 елда язган шигырьләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 258
Татарские легенды о прошлом Камско-Волжского края 262
Кыргыз һәм дә башкорд басмалыгы хакында . . . . . . . . . . . 264
Гөлбикә кыйссасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 265

**ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ**
**поиски и открытия**

Выпуск 4

Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*

Дизайн обложки *А.А. Булатова*

Подписано в печать: 16.10.2017 г.
Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная, печать офсетная
Усл.-печ. л. 16,3. Уч-изд. л.12,4. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20

**Духовное наследие: поиски и открытия**
Серия сборников

Серия продолжает традицию публикации малоизвестных письменных источников; изучения произведений, составляющих основу духовного наследия татарского народа; знакомства читателей с новейшими исследованиями в изучении татарских текстов.
Издание охватывает вопросы археографии, палеографии, кодикологии, текстологии, эпиграфики и др.




*Первый выпуск посвящен жизни и творчеству Г. Тукая в честь 130-летия со дня рождения поэта.*
*В сборнике сделана попытка осветить, интерпретировать материалы, помогающие понять личность Тукая, расширить научный взгляд на его творчество.*




*Второй выпуск посвящен жизни и творчеству писателя, публициста и общественного деятеля Ф. Амирхана. В сборнике впервые опубликованы ранее не издававшиеся на кириллице публицистические статьи писателя, введены в научный оборот письма выдающихся деятелей татарской культуры и науки начала XX века, адресованные Фатиху Амирхану, их воспоминания. Особого внимания заслуживает уникальный дневник К. Сагиди, зафиксировавший последние дни и часы жизни классика.*




*Третий выпуск серии посвящен жизни и творчеству классика татарской литературы, общественного и государственного деятеля Галимджана Гирфановича Ибрагимова (1887–1938).*

*В сборнике представлены художественные тексты писателя, его публицистика, доклады; воспоминания современников об Г. Ибрагимове, рецензии на его произведения и труды; архивные документы, связанные с надзором над писателем и его арестом.*

*Тексты впервые предлагаются вниманию читателей в переложении на кириллический алфавит.*